МИРАС

ЧЫН

ФӘННИ-ПОПУЛЯР,
ӘДӘБИ-НӘФИС ЖУРНАЛ

№12 / декабрь 2013



ТАРИХИ, ӘДӘБИ, МӘДӘНИ МИРАС, ТӘНКЫЙДИ ФИКЕР, ЗАМАН ӘДӘБИЯТЫ, ЯҢАЧА КАРАШ

А.Эшкинин фотосы

12 +

Журнал «ТАТМЕДИА» ААҖ тарафыннан гамәлгә куелды.
2012 елның май аеннан чыга.

Баш мөхәррир —
Илфак Мирза улы ИБРАҺИМОВ
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары — җаваплы сәркатип —
Рамил ХАННАНОВ
(843) 222-09-83 (17-93)

Редакция советы:
Марсель Әхмәтҗанов
Разил Вәлиев
Резеда Ганиева
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Дания Заһидуллина
Илдус Заһидуллин
Данил Ибраһимов
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Данил Мостафин
Рөстәм Мөхәммәдиев
Рафыйк Мөхәммәтшин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Индус Таһиров
Рамил Ханнанов
Рафаил Хәкимов
Әнвәр Хуҗиәхмәтов

Бүлек мөхәррирләре:
Илдус ЗАҺИДУЛЛИН
Ленар ГОБӘЙДУЛЛИН
Алия МӨБАРӘКШИНА
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы —
Диләрә НӘҮРҮЗОВА
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректор —
Дания ФӘЙЗУЛЛИНА
(843) 222-09-83 (17-90)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

Заказ №С-2598
Тираж — 2000 данә.
Формат 70 х 108 1/16
Басарга кул куелды: 02.12.2013
Журнал айга бер тапкыр чыга.
Бәясе ирекле

МИРАС
ЧЫН
ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ЖУРНАЛ
№12 (24) / декабрь 2013

Эчтәлек

ТАРИХ

4 **XVII-XVIII гасырларда Көньяк Урал төбәгендә яшәгән татарлар тарихыннан.** *Гаяз Сәмигулов*
10 **Башкортстан төбәге иҗтимагый-тарихи һәм әдәби тормышында абызлар (XVIII гасыр).** *Раиф Әмиров*
16 **Мәгърифәтче Шаһбазгәрәй Әхмәрев.** *Альта Мәхмүтова*
27 **Тукта, бер үткән гомерне...** *Сибгат Хәким*
28 **Габдрәшит Ибраһимның «Әл-Җиһад» газетасында басылган мәкаләләре.** *Себастьян Цвиклински*
37 **«Ханым вә туташлар дикъкатенә...»** («Сөембикә» журналына 100 ел) *Чулпан Мөслихова*
43 **«Әй, кыйммәтле ана!»** (Сөембикә журналында мәгърифәтче Фатыймаи-Фәридә турында мәкаләләр). *Чулпан Мөслихова*
48 **Кырым һәм Идел-Урал татарлары арасындагы бәйләнешләр.** *Филүсә Арслан*

ӘДӘБИЯТ

56 **Кутадгу билик (Котайткыч белем).** *Йосыф Баласагуни*
65 **Хатлар булып калган хатирәләр.** *Рөстәм Төхфәтуллин*
69 **Рәшид Рәшидов.** *Айдар Хәлим*
82 **Шундый татар тюркологы бар...** (Марсель Бакировка 80 яшь) *Әнвәр Шәрипов*
91 **Бер әсәрнең язылу тарихы** (Аяз Гыйләҗевнең «Кылдан нәзек, кылычтан үткен» романы турында). *Миләүшә Хәбетдинова*
100 **Олуг шәһәрдә кунакта.** *Рухия Ахунҗанова*
108 **Җирсү.** *Фәридә Хәсәнова*
114 **Тукай энциклопедиясенә.** *Заһир Шәйхелисламов*

116 **2013 елга «Чын мирас» журналының библиографиясе**

120 **Яңа китаплар.** *Алия Мөбарәкшина*

Безнең журналга
54132 ИНДЕКСЫ
буенча Татарстанның һәм
70275 ИНДЕКСЫ
буенча Россия төбәкләренең
һәр элемтә бүлегендә язылырга
мөмкин.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-49398 нче таныклык белән теркәлде.

Мәкалә авторларының фикере редакция хезмәткәрләренең фикере белән туры килмәскә дә мөмкин.
Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә.
Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.

Тышлыкның 1 нче битендә — Мөселман айларның исемнәре. Шамаил. М.Хуҗасәидов. XX гасыр башы. «Казань — Kazan: 1005-2005» (СПб., 2005) китабыннан.

Бу санда авторларның архивларыннан фоторәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

«Истинное наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

Хөрмәтле укучыларыбыз!
Журналыбызның 11 нче санында (2013 ел, 66-79 битләр) басылып чыккан «Гаяз Исхакый хатлары» материалының авторын «Г.Исхакый премиясе лауреаты Лена Гайнанова» дип уку шарт. Кереш мәкалә һәм хат текстлары басмага аның тарафыннан әзерләнде, фотолар да аның архивыннан. Техник сәбәпләр аркасында хөрмәтле авторыбызның исеме төшеп калганлыктан, Лена ханымнан һәм укучыларыбыздан гафу үтенәбез!

Редакция



Тарих

Сүтәләр өч ташлы тегермәнне.
Стенадан, калын түшәмнән
Беркемнең дә кулы кагылмаган,
Соңгы ачлык узгач түшәлгән
Онта коела, күксеп беткән онта,
Яшел мүкләр үскән чарыкны
Күчерәләр, кузгаталар бергә
Тегермәне белән тарихны…

Сибгат Хәким

XVII-XVIII ГАСЫРЛАРДА КӨНЬЯК УРАЛ ТӨБӘГЕНДӘ ЯШӘГӘН ТАТАРЛАР ТАРИХЫННАН

ГАЯЗ СӘМИГУЛОВ,
тарих фәннәре кандидаты, Көньяк Урал дәүләт университеты доценты (Чиләбе шәһәре)

ИДЕЛ БУЕНА 922 ЕЛДА ГАРӘП ИЛЧЕЛЕГЕ КИЛГӘНЧЕ ҮК, БОЛГАРЛАР ИСЛАМ ДИНЕ БЕЛӘН ТАНЫШ БУЛА. ЭТНОС БУЛАРАК БОЛГАРЛАР ХӘЗӘР ДӘҮЛӘТЕНДӘ ИҢ ЭРЕ КАБИЛӘ БЕРЛӘШМӘЛӘРЕНЕҢ БЕРСЕН ТӘШКИЛ ИТКӘН. ШУҢА ДА КАРАМАСТАН, ХӘЗӘР КАГАНАТЫНЫҢ РӘСМИ ДИНЕ ИУДАИЗМ БУЛЫП, ХӘЗӘР ҖӘМГЫЯТЕНЕҢ ЮГАРЫ ДАИРӘ ВӘКИЛЛӘРЕ, ШУЛ ИСӘПТӘН КАГАН ҮЗЕ ДӘ ЯҺҮД ДИНЕН ТОТКАН. БУ ЗУР ДӘҮЛӘТТӘ ХРИСТИАННАР ДА, МӨСЕЛМАННАР ДА КҮП БУЛГАН. БОЛГАРЛАР, КАГЫЙДӘ БУЕНЧА, ИСЛАМ ДИНЕ ТАРАФДАРЛАРЫННАН САНАЛГАН.

Көньяк Урал төбәгендә яшәгән төркиләрнең XVI-XVII гасырларга караган тарихы әлегә бик начар өйрәнелгән. Шул сәбәпле, без еш кына тарихи белемнәр белән түгел, ә образлар белән эш итәбез, ә бу исә — үткәнне мифлаштыру дигән сүз.

XVII-XVIII гасырларда булган тарихи процессларны документлар нигезендә өйрәнү башкорт тарихы өчен дә бик мөһим мәсьәлә. Гыйльми эзләнүләрнең ышанычлы юлларыннан берсе — тарихи язма чыганаклар белән чагыштырмача яхшы тәэмин ителгән соңрак чордан башлап, борынгырак гасырларга таба «бару». Көньяк Урал төбәгендә яшәгән татарлар тарихын яктыртканда, мин нәкъ менә шушы юлны сайладым. Тикшерү объекты итеп хәзерге Чиләбе өлкәсенең төньяк-көнбатыш төбәгендә (Кунашак районы) һәм Курган өлкәсенең көньягында (Сафакүл районы) XVII гасыр азагы — XVIII йөздә татарларның аерым төркемнәре туплану барышы алынды. Әлеге мәкалә элек төрле темаларга багышланган басма хезмәтләребезнең гомумиләштерелгән варианты булып тора. Текст укырга җиңел булмас дип уйлыйм. Чөнки күп кенә тарихи күренешләрне һәм вакыйгаларны гомуми планда яктырттык, ә аерым вак, ләкин мөһим мәсьәләләргә махсус тукталмадык. Әйтик, вотчиналы җирбиләү характеры, вотчинниклар белән башка игенчеләрнең мөнәсәбәтләре, башкорт восстаниеләре турында мәгълүматлар тезислар рәвешендә генә бирелде.

XVIII гасырда Көньяк Уралдагы этник процессларны этнослар арасындагы аралашу дип түгел, ә төрле этносословиеләргә караган төркемнәрнең аралашуы итеп ка-

рау мөһим. Безнең бу фикеребез фәндә яңалык түгел. Урал буенда һәм Урал артында көн күргән татарларның төрле сословиегә караган булулары турында, мәсәлән, Д.Исхаков язды [1]. Монда мәсьәлә шуннан гыйбарәт: аның тасвирлавында сословие төркемнәре «тигез» этник төстә бирелә, икенче төрле әйткәндә, фәкать бертөрле этник төркемнәрдән торган сословиеләр турында гына язылa. Минемчә, бу чынбарлыкка туры килми: сословиеләр үзләренең характерлары буенча этник группалардан өстен, алар төрле этник төркемнәрне берләштерә. Ягъни билгеле бер сословиегә кергән кешеләр бер-берсеннән төрле хокуклар (өстенлекләр) һәм үти торган бурычлары белән аерыла. Хәзерге заман кешесе күзлегеннән «мещеряк» — революциягә кадәр «мишәр» сүзенең язылышы, әмма XVII гасырда, бигрәк тә XVIII йөздә Көньяк Уралда «йомышлы мещеряк» сүзе нәкъ менә этносословие төркеменә карата кулланылган.

«Ясаклы татарлар», «йомышлы мещеряклар», «йомышлы татарлар» төшенчәләре, нигездә, сословиене белдергән терминнар булып тора, чөнки сүз аларга гына хас теге яки бу хокукларга һәм бурычларга ия булган төркемнәр турында бара. XVIII гасырда мондый группаларның составын моноэтник дип санау принципта дөрес түгел. Һичшиксез, мондый берәмлекнең һәрберсендә нинди дә булса төп этнос вәкилләре булып, алар күпчелекне — «нигезне» тәшкил иткән. Мондый «нигез» компонентының бер этник вәкилләрдән генә торуы — шулай ук шартлы күренеш. Чөнки күпчелекне тәшкил иткән этник төркемнән тыш, сословиегә башка этник төркем вәкилләре дә керә алган һәм кергән.

Беренче карашка «йомышлы мещеряк», «йомышлы татар» терминнары бер-берсен алмаштыра торган, синоним сүзләр кебек, чөнки икесе дә йомышлы сословие вәкилләрен аңлата. Ләкин архив документларында кайбер очракларда бу ике терминны һәрьюлы аерым мәгънә салып кулланганнар. Мин дә шулай эшләдем. Кайбер очракларда әчкен йомышлы татарлары үзләре кистереп «без мещеряк түгел», дип белдергән. Мәкаләбездә «татар» һәм «мещеряклар» терминнарын аерым төркемнәрне билгеләү өчен куллану тарихи чынагакларда аларны төрлечә аерымлаудан килеп чыкты. Документлар теленә ияреп язу бүгенге стереотиплардан котылырга да ярдәм итә. Бик мөһим искәрмә: без өйрәнгән төбәктә типтәрләр булмаган диярлек. Типтәрләр төньяктарак — Красноуфимски өязендә һәм көнбатыштарак, аннары көньяктарак — Троицки, Верхнеуральски өязләрендә шактый күп яшәгән. Ә Исет провинциясенең көнчыгышында алар булмаган.

Татарлар XVII гасыр азагы — XVIII йөз башында Көньяк Уралда күпчелек очракта башкорт волостьларында көн күргән. Төрле төркемнәрнең тормыш рәвеше бер-берсеннән күпмедер аерылган булырга да мөмкин. Җирдән файдалану хокукы ике юнәлештә формалашкан: 1) вотчинниклар белән читтән килгән кешеләр арасындагы традицион мөнәсәбәтләр; 2) җиргә хокук мәсьәләсе дәүләт тарафыннан көйләнү.

Беренче юнәлешнең барлыкка килү вакытын ачыклау кыен. Ул Октябрь инкыйлабына кадәр һәм инкыйлаб белән бәйле дәүләти һәм иҗтимагый үзгәрешләргә кадәр үк яшәгән. Икенче юнәлеш XVI гасырның соңгы өч дистәсендә (Көньяк Урал Россия империясенә кергән чорда) формалаша башлый.

Көньяк Урал өчен аерым кешеләрне, гаиләләрне яки аерым төркемнәрне вотчина җирләренә «кертү» («припуск») гадәти күренеш саналган. «Кертү»нең («припуск») характеры төрлечә булган. Кайбер очракларда ул телдән килешү нигезендә тормышка ашырылган (мәсәлән, Каратабын волостендагы айлин кабиләсе башкортлары яки Салзаут (Сальют) һәм Мякотин волостьлары бушкурт һәм катайлы башкорт кабиләләре кебек). Кешеләрне, язма килешү төзеп, алдан шартлар куймыйча һәм акча алмыйча, киләчәктә вотчинниклар белән тигез дәрәҗәдә ясак түләү һәм барлык дәүләт алдындагы бурычларны үтәү шарты белән «кертү» («припуск») дә кулланылган. Моның

бәрабәренә күченеп килгән халык башкалар белән тигез дәрәҗәдә барлык вотчина җирләреннән файдалану хокукы алган. «Кертү»нең («припуск») тагын язма килешү төзеп һәм бер тапкыр түләү алып, соңыннан, алдагы очрактагы кебек, ясак түләү һәм дәүләт алдындагы бурычларны тигез итеп үтәү шарты формасы да булган. Әйтик, сартлар (үзбәкләр) белән Мякотин волосте башкортлары шулай килешкәннәр: сартлар башта 100 сум түләгән, аннан соң вотчинниклар хокукларыннан файдаланган һәм, башкортлар кебек ясак түләп, башка дәүләт алдындагы бурычларны үтәгән. Күченеп килүчеләр фәкать вотчинниклар арендага бирә торган күлләрдән килгән табышны бүлешүдә генә катнаша алмаганнар.

Әле тагын телдән килешү нигезендә оброк җыю шарты белән «кертү» («припуск») дә булган: һәр күченеп килгән хуҗалыктан сөрүлек, печәнлек һәм көтүлек җирләреннән файдалану хокукы өчен билгеле бер күләмдә акча алынган. Мондый очракларда алар файдаланасы җирләрнең чикләре, гадәттә, төгәл билгеләнмәгән. 1740 еллардан инде оброк җыю шарты белән «кертү»дә («припуск») чикләр төгәл билгеләнә башлаган — әлеге җир биләмәләреннән вотчинниклар үзләре файдаланмаган. Мәсәлән, шундый килешүне 1744 елда Мякотин волосте башкортлары белән Төбәк авылы йомышлы мещеряклары төзегән (бу хакта әле алда әйтелер). Соңгы ике вариант, нигездә, «чит», ягъни ерактан күченеп килгән кешеләргә карата кулланылган. Ә күрше төбәкләрдән яки янәшәдәге волостьлардан килгән төрки кабилә вәкилләре бу җирләрдә бернинди махсус шартлар үтәмичә көн күргән.

Башкорт җирләре, башка «инородец»ларның вотчина җирләре кебек үк, Россия кануны яклавында булган. 1649 елгы Собор уложениесенең XVII бүлегендәге 43 маддәсендә болай дип әйтелгән: «А в городех у князей, и у мурз, и у татар, и у мордвы, и у чюваши, и у черемисы, и у вотяков, и у башкирцов, бояром, и окольничим, и думным людем, и стольником, и стряпчим, и дворяном московским, и из городов дворяном, и детем боярским, и всяких чинов русским людем, поместных и всяких земель не покупати и не меняти и в заклад и здачею и в наем на многия годы не имати. А будет которые московские и из городов дворяне и дети боярские, и всяких чинов люди учнут в городех у князей, и у мурз, и у татар, и у мордвы, и у всяких ясачных людей земли имати з дачею, или покупати, или в заклад, или в наем на многия лета имати, или меняти, и у тех всяких чинов людей те татарския поместныя и ясачныя земли имати на государя, да им же за то от государя бытии в опале» [2]. Ягъни вотчина җирләрен сатып алу яки озак вакытка арендага алу тыелган. Башкорт җирләренә карата бу тәртип шактый сакланган, ләкин 1736 елның 11 февралендә император Анна Иоанновна баш күтәрүдә, восстаниедә катнашкан башкортларның җирләрен офицерларга, дворяннарга һәм мещерякларга сату турында указга кул куйган [3]. Шушы указ башкорт җирләренең актив рәвештә шәхси милеккә әверелә башлавына яки завод хуҗалары һ.б. кешеләр тарафыннан озак вакытка арендага алынуга юл ача. Көньяк Уралда әлеге указдан соң дәүләт тарафыннан җир биләүне, шул исәптән кайбер җирләрне төрки халыкларның аерым группалары булган татарлар файдасына да, башкортлар файдасына да тарату көчәя.

XVII гасырның уртасыннан башлап 1770 елларга кадәр Көньяк Урал иҗтимагый тормышының аерылгысыз өлеше булып җирле халыкларның восстаниеләре, хакимияткә каршы баш күтәрүләр тора. Бу темага махсус тукталмыйбыз, ул мәкаләнең максаты түгел. Халык баш күтәрүләре турында китаплардан укып белергә мөмкин [4]. Шулай да иҗтимагый торышка кыскача гына бәя биреп китү кызыклы булыр. Беренче зур восстание 1662 елда була, аны традиция буенча башкорт восстаниесе диләр, чынлыкта баш күтәрүдә күп халык вәкилләре, җирле халыклар да, күченеп килгәннәр дә — башкорт, вогул, мари, чуваш, мещеряк, татарлар катнаша. Әмма восстаниенең төп көче булып баш күтәрүне туктатырга

теләмәгән «килгән татарлар» — Көньяк һәм Урта Урал аръягында яшәүчеләрнең нәсел дәвамчылары тора. Алар, Себер ханлыгы тар-мар ителгәннән соң, Себернең көньягына, Күчем хан янына күченә һәм аның белән була. Хан һәлак булганнан соң, язмышларын аның уллары-варислары — «Кучумович»лар белән бәйлиләр. Шулай итеп, яшәгән җирләреннән сырян нәсел ыруының күпчелеге, табын [5], мякотин [6] ыруларының бер өлеше күченеп китә. XVII гасыр башына караган документлар аларның «Кучумович»лар лагерендагыларның нигезен тәшкил итүе хакына сөйли [7]. XVII гасыр уртасында «Кучумович»ларның яки «хан улларының» исемнәре күбрәк калмыкларга бәйле рәвештә телгә алына. Беренче вакытта Күчем хан улларының, соңрак оныкларының төп союзниклары Урал арты төбәге далаларында ул заманның зур көче — калмыклар була. Бу хәл Себер ханының «олыс кешеләре» нәсел дәвамчыларын — сырян, табын һәм мякотин ыруы дәвамчыларын канәгатьләндерми. Себер ханлыгын торгызу барып чыкмый, алга таба каршылык күрсәтүнең нәтиҗәсе күренми, шул сәбәпле көрәшне дәвам итү елдан-ел мәгънәсен җуя бара.

1650-1660 еллар чикләрендә бу ыру вәкилләре яки аларның зур өлеше, «Кучумович»лар лагерен калдырып, элек яшәгән Исет елгасы буена һәм аңа койган елгалар тирәсенә кайтып урнашалар [8]. Биредә аларның җирләре руслар һәм күченеп килгән башка халык вәкилләре тарафыннан биләнгәнлеген күрәләр. Документларда туган җирләренә кире кайткан кешеләрне «выезжые татары» [9] яки «выходцы» [10] дип атаганнар, ягъни даладан чыгып, «Кучумович»лардан яки калмыклардан китеп, элекке яшәгән җирләренә кайтучылар [11]. Кайтучыларның барысы да заманында Күчем ханга ияреп киткән ыру вәкилләре түгел, аларның бер өлеше далага шактый соңрак киткән була. Ләкин Исет елгасы буена һәм аның югары агымындагы кушылдыклары тирәсенә килеп урнашучыларның күпчелеген шул ыруларның варислары тәшкил иткән. Документлардан күренгәнчә, күпләп күченү 1661 ел азагы — 1662 ел башына туры килә [12]. Күченүчеләрнең төп өлеше даладан 1661 елның көзендә кузгала һәм кышны Далматов монастыре янында уздыра [13]. Күченүчеләр башлаган восстаниенең беренче этабында җитәкче булып Сары Мәргән тора [14]. Кайбер документларда Сары Мәргән «уфимский изменник», дип аталган [15]. Кайтучылар өчен баш күтәрү — югалткан җирләре өчен көрәш ул. 1662 елда бу якларда башланган беренче массакүләм баш күтәрү канкойгыч булуы һәм озакка сузылуы белән аерылып тора. Ул, бер көчәеп, бер сүрелеп, 1669 елга кадәр дәвам итә. Исет елгасы буендагы рус торак пунктларының күбесе — Далматов монастыре, Царёво Городище, Барневс бистәләре, Катай кирмәне, Невьян Покров монастыре, Чусов, Белослуд, Усть-Эрбет, Мурзин һәм Кыргын бистәләре — 1662 елда яндырыла [16]. Авторлар восстаниенең тәмамлану вакытын төрлечә — 1664, 1667, 1669 еллар, дип билгелиләр. Шушы беренче массакүләм баш күтәрүдән соң, восстаниеләр 15-18 ел саен кабатланып тора.

Һәр яңа буын сугыш кырында чыныгу ала. Ләкин һәрбер восстание башкасыннан аерылып тора: кайбер баш күтәрүләр барышында, Идел буеннан башлап Көнбатыш Себергә кадәр барлык рус булмаган халыклар, кулларына корал тотып, хакимияткә каршы сугыш хәрәкәтләре башлыйлар, икенчеләрендә чувашлар, марилар, мещеряклар һәм татарлар хакимиятне яклап чыга һәм, образлы итеп әйткәндә, башкортларга каршы яктагы баррикадада була. Әлбәттә, бу — вакыйгаларны бик гадиләштереп бәян итү. Чынлыкта бер якта да бердәмлек булмаган. Башкортларның бер өлеше (гадәттә, шактый зур өлеше) әлеге көрәштә катнашмый, башка җирле халык вәкилләре дә капма-каршы лагерьларда торырга мөмкин була.

Восстаниеләр «вольница» исеме белән билгеле күренеш китереп чыгара. Әлеге исем белән баш күтәрүчеләргә каршы хакимият туплаган, рус крестьяннарыннан торган отрядлар атап йөртелә. Бу

отрядларга баш күтәрүчеләрдән зыян күргән бистә кешеләре яки үзләре теләп язылучылар кергән. Отрядлар, тупланганнан соң, чын баш күтәрүчеләрне эзләп җәфаланмаган: теләсә кайсы төркиләр (һ.б. халыклар да) яшәгән торак пунктларына һөҗүм иткән. Үч алудан тыш, аларның кылган гамәлләренә мәгънә биреп торган мотив — табыш алу: авылларда нәрсәне кулга төшергәннәр, барысын да үзара бүлгәннәр. Бик еш кына алар кулына сугыш хәрәкәтләренә бернинди катнашы булмаган кешеләр эләккән, бу Россия хакимиятенә һәм русларга каршы булучыларның саны артуга китергән.

Хакимият тарафыннан мондый отрядлар төзүнең төп сәбәбе булып регуляр армиядә гаскәриләрнең азсанлыгы, хакимиятнең сугыш хәрәкәтләре барган зур территорияләрне контрольдә тота алмавы торган.

Көньяк Урал төбәгендәге иң серле төрки халык вәкилләре — «эчкен татарлары». Аларның Көньяк Уралда беренче яшәгән урыннары — Исетнең кушылдыгы булган Эчкен елгасы. Әлеге елга исеменнән атамалары килеп чыккан да инде. XVIII гасырның уртасында аларның бер өлеше Әлмән (Могильное) исемле күл буенда (бүгенге Курган өлкәсе Әлмән районы җирләре) көн күргән (бер группасының биредә яшәгәнлеге XVIII гасыр азагы картасында теркәлгән [17]). Аларның һ.б. югарыда сөйләнгән татарлар төркемнәренең тарихы аз билгеле. «История Курганской области» исемле китапта XIX гасыр азагында Әлмән авылында гомер иткән Рамазан Таипов кулъязмасының кыскача эчтәлеге урнаштырылган. Кулъязмада эчкен татарларының килеп чыгышы шактый мифлаштырылган: аларның Урал артына килеп урнашулары XVI гасырда булды, дип язылган [18]. Моңа өстәп, хәзер чынбарлыкка туры килми торган шактый күп версияләр булуын әйтеп китү мәслихәт. Имеш, татарлар Исет буенда инде XV гасыр башында ук яши башлаган... Сүз бара торган вакыйгалар турында без академик П.С.Паллас язмаларыннан беләбез, ул аларны 1770-1771 елларда Көньяк Урал тирәли төрле маршрутлар буйлап йөргәндә теркәгән, шул исәптән эчкен татарларының килеп чыгышы турында Әлмәнкүл (Могильный) һәм Эчкен (Исет елгасы буенда) авылларында ишеткән мәгълүматны да керткән. Исет елгасы буенда ул болай дип язган: «Напротиву того дорога предлежала мне по левой стороне Исети по степи чрез село Масленское, деревню Ичкину над ручьём такого же имени, от коего наречены и прочия деревушки оселённыя Татарами, происходящими из поколения Казанских и здесь во первых поселившихся в развалившийся Мехонский острог» [19]. Хәзерге телгә күчерсәк, башта татарлар Мехон кирмәненә (острог) урнашкан булып чыга. Бу — бик мөмкин хәл. Мехон кирмәне 1658-1659 елларда, руслар Исет буена урнаша башлаган вакытта төзелә. Урал артындагы рус бистәләрендә яшәгән рус крестьяннары Исет елгасы буендагы беренче кирмәннәргә (острог) күчәргә ашкынмаган, беренче вакытта күченгән халыкның шактый өлешен татарлар, марилар һәм чувашлар тәшкил иткән [20]. Кирмәннәргә күченгән татарларның бер өлеше руслашкан, ләкин барысы да һәм күпчелек өлеше түгел. Моны раслау өчен, Тубыл төбәге дворянины Иван Полозовның 1695 елгы мәхкәмә материалларын китерергә мөмкин. Катай кирмәне тасвирламасында нәсел тамырлары татар белән бәйле фәкать ике генә рус кешесе язылган [21]. Аның берсе — Мурзин улы Осип Трофимов, Алатырь морзаларының нәсел дәвамчысы [22]. Ә 1660 елның сентябрендә Катай кирмәне приказчигы Панкратий Перхуров 1657-1660 елларда «пахотный крестьяннар» итеп кирмәнгә 5 рус крестьян гаиләсе, 36 татар һәм мари гаиләләре алынды, дип рапорт бирә [23]. Димәк, рус булмаган халыкларның күпчелеге Катай кирмәне карамагына бирелгән җирләргә авыллап-авыллап килеп урнашкан.

Эчкен татарларына әйләнеп кайтып, тагын шунысын әйтеп китү мәслихәт: аларның тарихына бәйле архив чыганаклары әлегә бик аз табылды. Мин мәкаләмдә фәнни әйләнешкә генеалогияне өйрәнүчеләр тарафыннан кертелгән

һәм үзем архивларда тапкан материалларны анализларга тырышырмын.

Стольник Лев Поскочин тарафыннан төзелгән Тубыл өязе җан исәбен алу кенәгәсендә («Переписная книга Тобольского уезда») Эчкен авылында яшәүчеләр дип төрле товарлар җитештерү белән шөгыльләнүче, Казан ягыннан һ.б. шәһәрләрдән килгән татарлар күрсәтелгән («промышленные татаровя казанцы и иных городов») [24]. Авылда 1667-1668 — 1679-1680 елларда барлыгы Казан, Сембер, Кадом һәм Зөя өязләреннән килгән оброк түләүче 7 татар гаиләсе теркәлгән, аларның күпчелеге (4 гаилә) 1670-1671 елларда күченеп килгән [25]. Җан исәбен алу кенәгәсенең Механ бистәсе һәм якын-тирәдәге авыллар буенча йомгаклау өлешендә Эчкен авылы кешеләре «эчкен татарлары» дип аталган [26]. Ләкин чынбарлыкның күпкә катлаулы булуы ачыкланды. Эчкен авылы 1677-1678 елларда Тубыл йомышлы татарларына — «Аптышка Сәйдәшев»кә һәм аның туганнарына («Чемейк с Бакитком с Кушаметком с Тюлячком») бирелгән булып чыкты [27]. Шул ук Поскочинның җан исәбен алу кенәгәсендә Эчкен авылының җир биләмәләре чикләре һәм авылда Сәйдәшевнең кешеләре («дворовые люди» (холопы)) теркәлгән. Биредә Сәйдәшев сатып алган калмыклар калмык кызларына өйләнеп яши, дип күрсәтелгән [28]. Эчкен елгасының яр буйларыннан тыш, бертуган Сәйдәшевләргә, балык тоту өчен һәм колмак җыю өчен, Кара елгадан Юршамыш елгасына кадәр түбән агымдагы кушылдыклар андагы барлык башка елгалар һәм тамакларны, күлләрне кертеп бирелгән, диелгән [29].

Искәрмәләр һәм әдәбият

1. Исхаков Д.М. Этнографические группы волго-уральских татар: опыт системного анализа // Этнотерриториальные группы татар Поволжья и Урала и вопросы их формирования. — Казань: Изд-во ПИК «Дом печати», 2002. — С.75-96, 110-130.
2. ПСЗ-I (Полное собрание законов). Т.I. №1.
3. ПСЗ-I. Т.IX. №6890.
4. История Башкортостана с древнейших времён до 60-х гг. XIX в. — Уфа, 1996; Акманов И.Г. Башкирия в составе Российского государства в XVII — первой половине XVIII вв. — Свердловск, 1991; Акманов И.Г. Башкирские восстания. — Уфа, 1993; Устюгов Н.В. Башкирское восстание 1662-1664 гг. // Исторические записки. — Т.24. — М., 1947. — С.30-110.
5. Пузанов В.Д. Военно-политические факторы колонизации Приисетья. — Шадринск: ПО «Исеть», 2001. — С.8.
6. Миллер Г.Ф. История Сибири. Изд. 2-е дополненное / Ред.кол. Батьянова Е.П., Вайнштейн С.И. и др. — Т.II. — М.: Издательская фирма «Восточная литература» РАН, 2000. — С.196.
7. Материалы по истории Башкирской АССР / Отв.ред. А.Чулошников. — Часть I. — М., Л.: Изд-во Академии наук СССР, 1936. — С.150; Миллер Г.Ф. Указ.соч. — Т.II. — С.194-196.
8. Материалы по истории Башкирской АССР. — Ч.I. — С.92-93.
9. Шишонко В. Пермская летопись, 1263-1882 гг. Третий период, 1645-1676 гг. — Пермь, 1884. — С.685, 692-693.
10. Там же. — С.688; Миллер Г.Ф. Указ.соч. — Т.III. — С.438-439; Материалы по истории… — С.59, 161-162.
11. Миллер Г.Ф. Указ.соч. — Т.III. — С.439.
12. Миллер Г.Ф. Указ.соч. — С.438-439; Шишонко В. Указ.соч. — С.685, 692-693.
13. Шишонко В. Указ.соч. — С.685.
14. Шишонко В. Указ.соч. — С.685, 693.
15. Материалы по истории… — С.159.
16. Материалы по истории Башкирской АССР. — Ч.I. — С.195-196, №63.
17. ЧӨБДА (Чиләбе өлкәсенең берләштерелгән дәүләт архивы). И-87 нче ф. 1 нче тасв. 1015 нче эш.
18. История Курганской области. — Т.V. — Курган: Курганское областное общество краеведов, 1999. — С.287-289.
19. Паллас П.С. Путешествие по разным местам Российского государства. — Т.II. Кн.I. — СПб: При Императорской Академии наук, 1786. — С.471.
20. Самигулов Г.Х. От Далматова монастыря до Чебаркульской крепости / Ред. Таиров А.Д. — Челябинск: Южно-Уральский государственный университет, 2011. — С.30-35.
21. РДБАА (Россия Дәүләт борынгы актлар архивы). 214 нче ф. 5 нче тасв. 1444 нче кит. Б.73.
22. Шунда ук.
23. ДАИ (Китап: «Дополнения к актам историческим»), Т.IV: 1655-1664; 1851. — С.224, №84.
24. РДБАА. 214 нче ф. 5 нче тасв. 261 нче эш. Б.1062.
25. Шунда ук. — Б.1062-1063.
26. Шунда ук. — Б.1065.
27. ПКДА (Пермь краеның дәүләт архивы). 297 нче ф. 1 нче тасв. 1030 нчы эш. Б.4.
28. Шунда ук. — Б.3.
29. Шунда ук.

Дәвамы алдагы санда

Русчадан ***Илдус Заһидуллин***
тәрҗемәсе ■

БАШКОРТСТАН ТӨБӘГЕ ИҖТИМАГЫЙ-ТАРИХИ ҺӘМ ӘДӘБИ ТОРМЫШЫНДА АБЫЗЛАР (XVIII ГАСЫР)

РАИФ ӘМИРОВ,
филология фәннәре докторы, М.Акмулла исемендәге Башкортстан дәүләт педагогия университеты профессоры (Уфа шәһәре)



ХАЛЫКЛАР ЯШӘЕШЕ СУГЫШ КЫРЫНДА ХӘЛ ИТЕЛГӘН ЗАМАННАРДА (БАШКОРТСТАН ТӨБӘГЕНДӘ XVII-XVIII ГАСЫРЛАР, 200 ЕЛГА ЯКЫН ДӘВЕР, КОЛОНИАЛЬ ИЗҮГӘ КАРШЫ ХАЛЫК МАССАЛАРЫ ЧЫГЫШЛАРЫ БЕЛӘН БИЛГЕЛӘНӘ), БЕРЕНЧЕ КАРАШКА, БУ ХӘЛЛӘРГӘ БӨТЕНЛӘЙ КАГЫЛЫШЫ БУЛМАГАН ФАКТЛАР, КҮРЕНЕШЛӘР ҺӘМ ХӘТТА КӨНКҮРЕШ ПРЕДМЕТЛАРЫ СӘЯСИ, ИДЕОЛОГИК ЭЧТӘЛЕК БЕЛӘН БАЛКЫЙ БАШЛЫЙ.

Ак ат, ат сыртына капланган ябма, кындагы яки ялтыраган үткен кылыч, тамгалы яки яшел агач таяк, шулай ук символик мәгънәгә ия төсле тукыма кисәге, ук тулы садак — һәммәсе мөһим вакыйгалар хакында сөйли торган билгегә әйләнә, көрәшкә чакыруны яки баш күтәрүгә әзер булуны белдереп килә.

Мондый иҗтимагый, публицистик күренеш белән янәшә кичекмәстән хәрәкәт итәргә өндәгән сүз-хәбәр калка: ул «вәгазь», «әңгәмә», «әкият», «каяндыр ишеткән гайбәт» формасын ала. Әлеге һәм башка жанрлардагы публицистиканың авторлары булып җыручылар һәм чичәннәр артыннан абызлар күтәрелә, алар башкорт түнтәрелешләрен идеологик яктан әзерләүдә һәм оештыруда әйтеп бетергесез зур роль уйный. Әйтик, 1663 елгы түнтәрелешкә бәйле документларда Бакай абыз исеме еш телгә алына. Гомумән алганда, абызлар институты XVII гасыр ахыры — XVIII йөз башына оешып җитә.

Тарихи әдәбиятта (Ш.Мәрҗани, В.В.Вельяминов-Зернов, Н.В.Устюгов, А.Н.Усманов һ.б.) хәзерге вакытка кадәр абыз (укый-яза белүче) сүзенең функциональ мәгънәсенә тиешле дәрәҗәдә игътибар ителмәде, аның этимологиясе гарәп сүзе «хафиз»га (Коръәнне яттан белүче) бәйләп каралды. Әмма бу сүзнең тарихын, килеп чыгышын дикъкать белән карасак, төрки халыклар ислам динен кабул иткәнче үк, борынгы төрки телдә яшәп килгәнлеген ачыкларбыз. Аның туган-тумачалыкны белдерә торган термин буларак кулланылышта йөрүе дә шул хакта сөйли. Мәгълүм ки, сүзнең аеруча борынгы мәгънәви үсентеләре нәкъ менә көнкүрештә сакланып кала (татар телендә — абый, абзый; башкорт телендә — абый, олы яшьтәге ир; абышка — хатынның иренә, кайбер сөйләшләрдә икенче тапкыр өйләнгән ир-атка мөрәҗәгать итү формасы).

«Аба», «абыз» сүзләре төрки телләрдә бик борынгы дәверләрдән кулланылып килә һәм тамырлары белән борынгы һинд телендәге бгава (әфәнде, нурландыручы; бгавати — бүлеп бирүче, өлеш чыгаручы), авеста телендәге Аллаһ, Илаһ сүзләренә барып тоташа [1]. Бу сүзнең «Казах совет энциклопедиясе»ндәге аңлатмасы да ышандырырлык: «Абыз — мәҗүси халыклар тарафыннан җырчыга яки муллага тагылган тәхәллүс. Шаман ышанулары системасында абыз мулла дигәнне аңлата» (Абай). «Абызны (казахча) «күпне белүче» дип шәрехләп, авторлар түбәндәге мисалларны китерә: «Җанибәк батыр, үз балаларын белемгә өйрәтү өчен, абыз эзләп тапты» (И.Алтынсарин). М.Ауэзовның «Энлик-кебек» трагедиясендә абыз — халыкның уй-фикерен, гыйлемен чагылдыручы тип [2]. Кыскасы, абыз — халык акылын үзенә туплаган, дини һәм дөньяви белемгә ия шәхес; үзенең белемнәрен дөньяви мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлткән гыйлем иясе.

Ә дин белгеченең, тарих елъязмачысының эшчәнлеге борын-борыннан аерым игътибар үзәгендә торган. Чөнки традицияләрне дәвам итү һәм саклау шөгылен сайлаган шәхес — мизгелнең мәңгелек белән кушылган ноктасында, мәңгелек исә (шул ук традициядә, язмаларда беркетелеп), вакытлыча булса да, мизгел чикләренә төшеп урнаша. Бу бигрәк тә китап күбәйтүнең бердәнбер чарасы кульязма күчерү булган дәверләр өчен хас.

Абызлар эшчәнлегендә сәяси, агитацион-пропагандистлык эшенең мөстәкыйль төргә әверелү билгеләре аермачык чагылыш таба. Марксизм-ленинизм тәгълиматына нигез салучылар, сәяси эшчәнлектә ике момент булуны искәртеп, «һәрбер җәмгыятьнең асыл табигатеннән килеп чыга торган гомуми эшләрне башкару һәм хөкүмәт белән халык массалары капма-каршылыгыннан барлыкка килгән үзенчәлекле функцияләр үтәү» турында сүз алып баралар [3].

Абызлар институты үз вәкилләрен патша администрациясенә дә урнаштыра: хакимият органнарында алар тылмачлар, күчереп язучылар булып киткәннәр, дипломатик вазифалар башкарганнар, түнтәрелеш вакытларында хакимият һәм баш күтәрүчеләр арасында элемтәче, арадашчы ролен үтәгәннәр.

Бер үк вакытта абызлар арасыннан халык массаларының демократик уйфикерләрен уртаклашкан шәхесләр дә чыккан. Алар актив рәвештә җәмәгать эшләрендә катнашкан. Бу адымга аларны кеше тормышның барлык якларын көйләргә омтылган ислам дине дә, патша хөкүмәтенең төбәкне башка дингә юнәлтеп колонизацияләү хәрәкәте дә этәргәндер. Мондый шартларда «мулла» («гыйлемле кеше») һәм «абыз» төшенчәләре бик еш синоним буларак кулланылган. Үзләренең вөждан мәхкамәсе турындагы вәгазьләре һәм бигрәк тә халык массаларының ихтыяҗларын яклаулары белән алар патша администрациясе карарларын тормышка ашыручыларга әйләнеп барган старшиналарның эш-гамәлләренә каршы чыккан.

1662-1664 еллардагы халык түнтәрелешендә актив җитәкчеләрнең берсе, Юрматы олысыннан абыз Актай Дусмөхәмбәтов әдәби яктан талантлы, язма һәм телдән сөйләмнең бөтен нечкәлекләрен белгән кеше була.

Ул язган «1663 елның 16 ноябрендә Уфа воеводасы А.М.Волконскийга Нogай даругасы башкортлары хаты»нда киң кулланылган экспрессив стилистик алымнар, риторик градацияләр халык массаларының кәеф-халәтен ачык күрсәтә. «Бездән — ясерләрдән (әсирләрдән) — ни телиләр? Бездән нинди рәхим-шәфкать көтәләр? Без падишаһыбыздан үзебез рәхимшәфкать көтәбез», — дип башлана баш күтәрүчеләрне буйсындыру өчен киң кулланылган алымга — әманәтчетоткыннар алуга — протест йөзеннән төзелгән юллама.

Воевода Волконский белән сөйләшкәндә, Актай абыз гамәлләре түнтәрелешне китереп чыгаруга сәбәп булган

талаучыларның кыяфәтен тасвирлый. Бу — башкорт вотчиналарына хуҗа булган һәм явыз эшләр кылган, һәрчак башкортларга бәйләнгән һәм аларны саткан Никита Анечков, ә Иван Павлов, Иван Кулаков, аларга бурычка акча биреп, көч кулланып, яхшы айгырларын, юрга атларын, кондызларын, чүпрәк-чапракларын тартып алган, балаларын кыерсыткан, өс-киемнәрен салдырып, эчке күлмәктән калдырган» [4].

Башкорт түнтәрелешләренең җитәкчеләре һәм идеологлары булып киткән абызларга Яңарыш чорының күренекле вәкиле Ф.Энгельсның бәяләмәсе туры килә: «Алар барысы да заманның әһәмиятле вакыйгалары эчендә кайныйлар, гамәлләре белән көрәштә катнашалар, теге яки бу фирка ягына чыгалар һәм кылыч урынына кем сүз, кем каләм, ә кемдер икесе белән дә көрәшә» [5]. Күрәбез, Ф.Энгельс сүз һәм каләмне кылычка тиңли. Бу гаҗәп тә түгел: феодаль строй вакытында халыкның баш күтәрүләре һәм аларга каршы көрәш массаларның тормышчан һәм иҗади активлыгы белән тәэмин ителгән, һәм ул сәяси әдәбиятның үсүенә китергән.

Түнтәрелешләр барышында абызларның алгы сафта булулары дәвамлы күренешкә әйләнгән, бу — акрынлап урнашкан абызлар институтының система буларак тотрыклылыгын да күрсәтә. Түнтәрелешләрдә башта кушканны үтәүче кебек катнашып, тәҗрибә туплап, аннары алар җәзага тартылганнарның бушаган урынына — әйдаман урынына — баскан. 1735-1736 еллардагы түнтәрелеш җитәкчесе, үз заманының укымышлысы, русча белгән абыз Килмәк Нурушевны 1705-1711 еллардагы баш күтәрүне оештыручылар Кырымга җибәрә. Бөрҗән олысыннан булган абыз Газиз каракалпаклар белән озак вакытлар элемтәдә тора. 1722 елда нәкъ менә аның янына Солтан Морат җибәргән биш каракалпаклы килә, ә хакимият аларны тотып бирүләрен таләп иткәч, «Газиз абыз илчеләрне үзеннән олау белән озаттыра, ә кай тарафка китүләрен белмәмешкә салыша». 1737 елның 15 сентябрендә баш күтәрүчеләр «Казахларның Кече җөзенә һәм Каракалпакстанга Аиткол абызны, Кумак Сөендековны һәм Карачурин улын җибәрәләр» [6].

Оренбург шәһәре оешкан урынга И.К.Кириллов артыннан килүче Вологда роталарына һөҗүм иткән вакытта, Килмәк отрядында әле күзгә нык ташланмаган старшина, абыз Бәпәнәй Торыпбердин була. Ул — Йосыф Арык җитәкчелегендәге түнтәрелешнең идеологы, 1737 елда үзе әйдаманга әверелә, өндәмәләрендә һәм хатларында протест хәрәкәтен туктатуның бер шарты итеп Килмәк абызны, Акай батырны һ.б. тоткынлыктан азат итүне куя.

1755 елгы баш күтәрүдә катнашкан Бушман-Кыпчак олысы абыз-старшинасы Кинҗә Арсланов 1773-1775 еллардагы чуалышлар вакытында Е.И.Пугачёв гаскәренең Хәрби советы әгъзасына әйләнә. Абызлар сөйләмә һәм язма иҗатының идея-эстетик казанышлары яктылыгында, аларның эшчәнлеге нәтиҗәсендә, 1755 елгы түнтәрелеш идеологы һәм җитәкчесе Батыршаның һәм җырчы-көрәшче Салават Юлаевның әсәрләре пәйда була.

Чичәннәр белән бер дәрәҗәдә торып, ул дәвер башкорт җәмгыятенең иң алдынгы гаклый көчләреннән саналган, гади халыкка якын абызлар аның бүгенге һәм иртәгәсе көнен кайгырткан. Түнтәрелешләрдә катнашкан өчен җәзалауны алардан башлау бер дә гаҗәп түгел. Абызларның гомере иртәме-соңмы дар агачында яки баш чаба торган бүкәндә өзелгән. Халык хәрәкәтләренең тулып ашкан ачуын бер юлга кертеп җибәрүче, халыкларның протест чыгышларының идеологлары һәм теоретиклары нәкъ менә алар булган. Падишаһ, төбәк администрациясе һәм патша наместниклары исеменә алар каләме белән язылган үтенечләр, гаризалар сәяси документ функциясен башкарган.

Төбәкнең иҗтимагый тормышына абызларның йогынтысы, абруе халык һәм администрация вәкилләре та-

рафыннан берсүзсез танылган. Шул дәвер патша администрациясе рәсми кәгазьләрендә алар «караклар», «котыртучылар», «ата караклар», «төп чуалтучылар» кебек тупас һәм кимсетүле исемнәр белән аталып йөртелгән. Үзләренең буйсынуларын белдереп, хакимияткә баш иеп килүчеләр арасында барыннан да бигрәк абызларның булуы мөһим саналган: «Вятка һәм Кама елгалары буйларында көн күрүчеләр Сарапулга башка яхшы кешеләр, муллалар, абызлар белән Коръәнне үбү өчен» [7] килгәннәр.

А.И.Тәфкилев Югары Җаек кирмәнен төзүгә каршы халыкның баш күтәрүен оештырган һәм кулга алынган Йосыф Арыковны түгел, башка абызҗитәкчеләрне хакимият өчен куркыныч дип санаган. Аның сүзләре буенча, Юлдаш мулла, Бәпәнәй Торыпбердин абыз һәм «гади халыкны кайнатучы башка билгесезләр» Урал тау арты башкортларының баш караклары булганнар [8].

Абызларның популярлыгын чагылдырган тагын бер фактны атап үтик. 1736 елда Килмәк абыз Нурушев генерал-майор А.И.Румянцев лагерена ясаган уңышсыз һөҗүменнән соң гаскәрсез кала. Шуңа да карамастан, Казан даругасы Кыр-Елан олысы башкортлары аны үзләренә чакыра. Өч тапкыр чакырганнан соң, ниһаять, Килмәк абыз килгәч, нык сөенеп, үзләрен яклаучы булуын үтенәләр, «бөтен йортлары белән аның янында булырга теләүләрен җиткерәләр». Килмәк абызның: «Кешеләр аз калу сәбәпле, саклый алмаячакмын», — диюенә каршы баш күтәрүчеләр: «Без ул булганга канәгать һәм аның исеме мең кешене алыштыра», — дип җавап бирә [9].

«Халык» терминының мәгънәсе киңәю һәм төгәлләшү дә абызлар белән бәйләнгән. XVI-XVII гасыр башы хакимият эш кәгазьләрендә бу сүз башкортларны гына күздә тоткан. Җирле халыкның милли составы төрлеләнгән, башкорт общинасында социаль бүлгәләнү көчәйгән саен, «халык» атамасының эчтәлеге үзгәрә барган.

Воевода Хованский исеменә юлланган хатта, соңрак патшага аталган үтенеч язуында «Морза абыз, Исмәгыйль абыз һәм Үсәй, шулай ук Казан өязендә Арча даругасыннан Чермәк, Җөри даругасыннан Токай абыз», төбәкнең күпмилләтле халкын җәза отрядларыннан аралауны таләп итеп, болай дип язалар: «Солдатларның һәм кара урыс кешеләренең башкортларны, татарларны, арларны, чирмешләрне һәм чувашларны талауларыннан һәм үтерүләреннән сакласагыз иде. Бу гамәлләр бик күпләрнең бөлүенә һәм үлеменә китерде» [10].

Әлеге катлаулы һәм күпьяклы, ләкин үсештәге процесс — уртак мәнфәгатьләр җирлегендә халыкларның үзара якынаю баруы — шул заманның публицистик документларында чагылыш тапкан, алар җәмгыятьтәге социаль һәм идеологик бүленешне («ышанычсыз башкортлар») һәм русларга мөнәсәбәтне ачык чагылдырган. «Рус кешеләре»н үзара мөнәсәбәтләр, каршы чыгу, һөҗүм объекты буларак «йомышлы рус кешеләре»нә, «хәрби кешеләр»гә, «целовальниклар»га, «монахлар»га бүлеп һәм шулай ук бер төркемгә җыеп карау чын дошманның кем булуын яхшы белгәнлекне күрсәтә [11].

Җир биләмәләрен һәм качкыннарны кире кайтару кебек кискен мәсьәләләрдә мөрәҗәгатьләр, үтенеч кәгазьләре, гаризалар язучы абызлар бик еш кына төбәккә күченеп килгән рус һәм рус булмаган халыкларны яклау позициясенә баскан, гәрчә мантыйк буенча киресен эшләү таләп ителсә дә. Күченеп килүчеләрне кудыру алар утырган җирләрне азат итәр иде, кана. Абызларның качып күченүчеләрне үҗәтләнеп яклауларында, әлбәттә, феодаль югары катламның мәнфәгатьләре дә роль уйнагандыр: килгән халык алар өчен — арзанлы эшче көч.

Әмма баш күтәрүчеләрнең үҗәтлеге, абызлар алып барган агитация җирле халык һәм күчеп утырган руслар арасындагы үзара бәйләнешләрне ныгыт-

кан. Себер даругасы Көди волостеннан Исмәгыйль мулла башта җыенда, аннары хөкемдар Алфимьевка җибәрелгән хатында, качып килүчеләрне Сенат Указында күрсәтелгән 42 елга сөргенгә җибәрмәү турында үтенә. 1705-1711 еллар түнтәрелеш җитәкчеләренең һәм идеологларының берсе булган Смәил мулла үз хатларында күченеп килгән чуваш һәм русларны кире җибәрмәү турында сорап яза.

Түнтәрелеш җитәкчесе һәм идеологы мулла Юлдаш «иптәшләре белән» Уфа воеводасы Шемякинга (1736 елның сентябре) язган хатларында: «Чувашларны һәм чирмешләрне яклап чыктык, әмма Тәфкилев аларның малларын талый, үзләрен кол ясый», — дип аңлата. Патша администрациясенә язылган хатларда Казан даругасы Снакыркы авылы башкортларының Казан губернасына китәргә кушылган Ярмәк абызны яклап озак вакыт тартышулары да чагылыш тапкан.

Колониаль сәясәтнең икенче ягы баш күтәргән башкортлар белән күрше халыкларның берләшүен тыюда да күренә.

Патша хөкүмәте, төрле халык вәкилләренең Башкортстан төбәгенә килеп урнашуын тәэмин итү максатыннан, башкортларда ыруара һәм кавемара мөнәсәбәтләрне йомшартырга омтылган. Бер диндә булган күченеп килүче төркемнәр (ясаклы татарлар, типтәрләр, мещеряклар, бобыльләр), икътисади һәм сәяси өстенлекләр бирү юлы белән, җирле халыкка каршы куелган. Баш күтәрүчеләрнең чыгышлары оешканрак һәм масштаблырак булган саен, хакимият аларның иҗтимагый һәм көнкүреш тормышын чикләргә күбрәк көч түккән, хакимияткә каршы чыгучылар арасында киртәләр корырга юллар эзләгән.

Әйтик, 1734-1737 еллардагы түнтәрелештән соң, Оренбург экспедициясенең җитәкчесе И.К.Кириллов тәкъдиме нигезендә, Сенат кабул иткән Указда болай дип язылган була: «Башкортларга, типтәрләргә, мишәрләргә алдан гариза бирмичә һәм Казан губернаторы рөхсәтеннән башка никахлашу тыела. Әмма рөхсәт булган сурәттә дә, һәр туйдан бер чабыш аты алырга, ... ә рөхсәтсез өйләнгәннәрне сөргенгә сөрергә». Кириллов үзенең мондый тәкъдимен туганлык мөнәсәбәтләре урнашу халык арасында хакимият өчен файдага булмаган хәбәрләрнең тиз таралуына китерүе белән аңлата: «Казанда яралырга да өлгермәгән яңалык башкортка инде күптән билгеле» [12].

Патша хөкүмәте, алдан күрүчәнлек белән, мәгърифәтне түнтәрелеш фикерләре таралу чыганагы дип билгеле, мәчет һәм мәктәпләр төзүне тыя, чөнки «абызлар балаларны татарча укырга-язарга өйрәтәләр». Төрле волость һәм даруга халыклары үзара аралашмасын өчен, ясакны аерым җыю омтылышы ясала. Халыкның укый-яза белүче катламы, бигрәк тә муллалар һәм абызлар, күзәтү астына алына: «элекке тәртипсезлекләрдә мондый мөселман дин әһелләре һәм укый-яза белүчеләр бик зур караклар һәм явызлар иделәр» [13].

Халык күтәрелешләрен оештыручылар белән хакимият яклылар арасындагы ызгышны тирәнәйтү өчен, зур көч куела. Патша хөкүмәте үзенә «тугры» старшиналарны союзниклар итеп, алардан ырудашларының уй-ниятен, хәрәкәтләрен күзәтүне таләп итә, вакытында чара күрү өчен, «һәртөрле сүз берләшүләр һәм начар килешүләр», «начар ниятләр һәм әшәке имеш-мимешләр» турында хәбәр итеп торуларына ирешергә тели.

«Тугры старшиналар»ны, «яхшы кешеләр»не сатып алу, аларга хезмәтләре өчен баш күтәрүчеләрнең гаиләәгъзалары милкен тарату, өстенлекле хокуклар бирү тәҗрибәсе патша хөкүмәтен муллаларга, абызларга һ.б. дин әһелләренә карата да «чыбыркы һәм прәннек» канунын куллану фикеренә китерә. Даими рәвештә булып торган түнтәрелешләрдә халыкның зур югалтуларга дучар ителүе публицистикага конфликтлы ситуацияләр һәм образлар үтеп керүгә сәбәп була. Бу югалтулар якты киләчәк өчен дип аңлатыла, мулла

Бәпәнәй Торыпбердинның «балалар һәм оныкчыклар» турында кайгыртып язган хат һәм юлламаларында охшаш фикер күп тапкырлар кабатланган [14].

Халык бәла-казаларын җирле администрациядән күреп, Бәпәнәй Торыпбердин үз әсәрләрендә сыналган публицистик алым — хаксыз указлар чыгарырга хокукы булмаган иң югары инстанция — патша хакимиятен идеаллаштыруны файдалана. Мулла Бәпәнәй Торыпбердин В.Н.Татищевка 1736 елда язган хатында: «Патшабикә болай эшләмәс иде», — дип, «гадел патшабикәне» «гадел булмаган түрәләрдән» кискен аерып куя.

Патша хакимиятен һәм аның төбәк администрациясен бербөтен итеп күрергә теләмәүдә абызларның дөньяга караш тарлыгы чагыла, шулай ук Россиядә XVI-XVIII гасырларда булган түнтәрелешләр публицистикасындагы патшаны яклау рухының да тәэсире бардыр.

Әмма үҗәтләнеп кабатлана торган формулада («Патшабикә болай эшләмәс иде») «ә бәлки эшләгәндер дә», дигән шик бөртеге сизелә: «ә эшләгән булса», ул вакытта үз өстеңнән мондый хакимиятне тану кирәкме икән?

Халыкларның царизмга каршы аяусыз көрәшенә «каләм һәм кылыч» белән илһамландырган Бәпәнәй Торыпбердин һ.б. абызлар Башкортстан төбәген Россия империясенең эчке провинциясенә әверелдерү, башкортларны җан башыннан салым түләүче сословиегә күчерү планын тормышка ашырырга мөмкинлек бирмәгән.

Килмәк Нурушев, Бәпәнәй Торыпбердин һ.б. абызларның эшчәнлеге публицистик сүзнең җәмгыять тормышына тәэсире артуны күрсәтә. Аларның йогынтысы ук һәм мылтык кебек нәтиҗәле, ә абызның старшина-сугышчыга караганда да куркынычрак булуы түнтәрелешләр барышында да, патша администрациясе белән мөнәсәбәтләрдә дә расланган.

Түнтәрелешләрдә «хан» концепты кулланылу Россиядәге социаль протест чыгышларында киң таралган ялган исем белән йөрүгә аваздаш. Хан образын сепаратизм фикереннән арындыру һәм аның ялган исем белән йөрүчегә таба күчеше — XVIII гасырның 30-40 нчы елларында булып узган түнтәрелешләрдә, Башкортстан төбәгендә 1755 елгы баш күтәрү, 1773-1775 еллардагы Крестьяннар сугышы идеяләрен кабул итүгә әзерлек этабының мөһим факторларыннан берсе.

Әдәбият һәм искәрмәләр

1. Севортян Э.В. Этимологический словарь тюркских языков: Общетюркские и межтюркские основы на букву «Б» / АН СССР. Ин-т языкознания. — М.: Наука, 1978. — С.3.
2. Казахская советская энциклопедия. Т.1. — Алма-Ата, 1978. — С.35.
3. Маркс К., Энгельс Ф. Собр. соч. в 39 т. Т.21. — М., 1969. — С.164-165.
4. Материалы по истории Башкирской АССР. Т.1. — С.169.
5. Маркс К., Энгельс Ф. Собр. соч. в 39 т. Т.20. — М., 1969. — С.347.
6. Материалы по истории Башкирской АССР. Т.1. — С.327.
7. Там же. — С.231.
8. Ал.: Устюгов Н.В. Башкирское восстание 1737-1739 гг., М.-Л., 1950. — С.44.
9. Материалы по истории Башкирской АССР. Т.1. — С.293.
10. Россия Фәннәр академиясе Уфа фәнни үзәге архивы, 3 нче фонд, 12 нче тасвирлама, 43 нче саклау берәмлеге, 176 нчы бит.
11. Патша администрациясе һәм аның төбәктәге вәкилләре өчен «Башкортстан» сүзе географик төшенчә буларак кулланылган, ә анда яшәүче халыклар, нинди этник төркемгә керүләренә (башлап килеп урнашкан угро-финнар һәм аларның дәвамчылары: марилар, удмуртлар, чувашлар, татар-мишәрләр, типтәрләр, руслар, шул исәптән кан буенча башкортлар да) карамастан, «башкорт» дип йөртелгәннәр. Үзләренең патша администрациясенә мөрәҗәгатьләрендә баш күтәрүчеләрнең әйдаманнары рәсми язма тәҗрибәгә таяна. Фәнни һәм әхлакый нокталардан караганда, бик үк дөрес булмаган, бигрәк тә тарихи фактларны шәрехләгәндә, күп бәхәсләр һәм аңлашылмаучанлыклар тудырган әлеге традиция постсовет чорында да сакланып килә.
12. Очерки по истории Башкирской АССР. Т.1. Ч.1. — Уфа, 1956. — С.145.
13. Материалы по истории Башкирской АССР. Т.1. — С.317.
14. РГАДА по кабинету кн. 56/1133. Л.423.

Русчадан ***Илдус Заһидуллин*** *тәрҗемәсе* ■

МИЛЛИ МӘГАРИФ КАҺАРМАННАРЫ

МӘГЪРИФӘТЧЕ ШАҺБАЗГӘРӘЙ ӘХМӘРЕВ

АЛЬТА МӘХМҮТОВА,
тарих фәннәре кандидаты, ТР Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге премиясе лауреаты

Бездә күзе ачык кешеләр дә бардыр,
Бу заманда гафилләргә дөнья тардыр.
Г.Тукай

МӘКАЛӘДӘ СҮЗ XIX ГАСЫР АХЫРЫ КАЗАН ТОРМЫШЫНДА КҮРЕНЕКЛЕ РОЛЬ УЙНАГАН, БЫЕЛ ТУУЫНА 100 ЕЛ ТУЛГАН ТАТАР ПЕДАГОГЫ ШАҺБАЗГӘРӘЙ ӘХМӘРЕВ ҺӘМ АНЫҢ ГАИЛӘСЕ ХАКЫНДА БАРА.

Архив документларында Шаһбазгәрәй Исмәгыйль углы Әхмәрев (1853-1900) обер-офицер улы дип күрсәтелә (бу исем түбән чиндагы — прапорщиктан алып капитанга кадәр — офицер гаиләләрендә 1861 елга кадәр туган балаларга бирелә торган булган). Димәк, аның әтисе 50 нче елларда Россия армиясендә хезмәт иткән тылмач-тәрҗемәче булгандыр дияргә нигез бар. Гаиләдә сакланган риваятьләр исә Әхмәревләрнең нәсел агачын тирәнгә, Алтын Урда чорына ук алып китә. Бу риваятьләргә караганда, Әхмәр морзаның варислары, Мәскәү дәүләте тарафыннан Казан ханлыгы яулап алынганнан соң, күп кенә ислам диненә тугрылыклы калган морза нәселләре кебек, бөлгенлеккә төшкән һәм, тормыш көтәр өчен, я «чабаталы морзалар» рәтен тулыландырырга, яки дәүләт (армия) хезмәтенә ризалашырга тиеш булган.

Вакыты җиткәч, Шаһбазгәрәйне Казандагы беренче ирләр гимназиясенә казна хисабына укырга биргәннәр (ул чорда хөкүмәт куллана торган бер чара — рус булмаган милләтләрдән, шул исәптән татар милләтеннән дә, офицер һәм чиновник балаларын казна хисабына рус мәктәпләрендә укыту булган). Шаһбазгәрәй яшүсмер гимназист чагында аның әтисе үлеп киткән. Сукыр әнкәсе белән генә калган егеткә репетиторлык белән шөгыльләнергә дә туры килгән. Гимназияне ул 1873 елда егерме яшендә тәмамлаган.

Бу чорда Халык мәгарифе министрлыгы һәм Казан уку-укыту округы арасында Казанда татар укытучылар мәктәбе (алда — КТУМ) ачу хакында хәбәрләшү башланган була. Татар укытучылар мәктәбен ачу — татарларны мәктәп аркылы руслаштыру максатыннан чыгып эшләнгән эш; ягъни, әзерлекле, бу сәясәтне халык арасында

уздырырлык, русча укыткан укытучыларны татарларның үзләреннән хәзерләү булган. Чишелергә тиешле мәсьәләләр арасында КТУМ өчен университетта татарлардан рус теле һәм әдәбияты белгечен әзерләү проблемасы да куелган. Гимназияне тәмамлаучылар арасыннан укырга теләк, зур сәләт һәм тырышлыгын күрсәткән Шаһбазгәрәй сайланып алынган. Шулай итеп, Ш.Әхмәрев, Мәгариф министрлыгы стипендиаты буларак, 1873 елда Казан университетының тарих-филология факультетында укый башлаган. 1876 елда КТУМ ачылган көннән, университетның өч курсын тәмамлаган студент, укуы белән бергә, мәктәптә рус теле дәресләрен дә алып барган. Университетны уңышлы тәмамлаган Шаһбазгәрәй 1878 елның 19 августында мәктәпкә рус теле һәм әдәбияты укытучысы итеп рәсми рәвештә билгеләнгән.

Хәдичә Шаһиәхмәт кызы һәм Шаһбазгәрәй Исмәгыйль улы Әхмәревләр. Казан, 1879 ел

Хезмәт баскычларын ул бик уңышлы үткән: башта укытучы, 1881 елдан гомеренең азаккы көненә кадәр КТУМ инспекторы (ягъни директоры) булган. Еллар үткән саен, аның дәрәҗәсе дә арткан: коллежский ассесор (1883), надворный советник (1884), коллежский советник (1887), статский советник (1890). Бу дәрәҗәләр исә Пётр I заманында кабул ителгән һәм 1917 елда патша хакимияте җимерелгәнчегә кадәр гамәлдә булган «Табель о рангах» дигән документ нигезендә хөкүмәт чиновникларына бирелгән һәм иясенә дворянлык статусы биргән сигезенче — бишенче классны тәшкил иткән була. Мисал өчен Ш.Әхмәрев алган соңгы дәрәҗә бишенче класс чины саналган (мондый дәрәҗә, мәсәлән, вице-губернатор яки министр урынбасары хезмәтен башкаручыларга да бирелгән югары дәрәҗә хисапланган). Мәктәп директоры өчен ул, күрәсең, иң югары дәрәҗә булгандыр, чөнки һәр өч ел саен яңа чин алып килгән Ш.Әхмәревнең хәле соңгы ун ел эчендә бернинди үзгәрешләр кичермәгән. Бу елларда аның уңышлы эшләвен хөкүмәт өченче һәм икенче дәрәҗәле изге Станислав ордены белән билгеләгән.

Шаһбазгәрәйнең мәгърифәтче буларак формалашуында галим, шәрык белгече В.В.Радлов, татар мәгърифәтчеләре Шиһабетдин Мәрҗани һәм Мөхәммәтгали Мәхмүдевләрнең роле зур булган. Ул алар белән бергә КТУМ-да эшләгән, алар йогынтысында педагог, мәгариф эшләрен яхшы оештыручы булып җитешкән. Алар, бергәләшеп, татарлар өчен дөньяви мәктәпнең төпле нигезен төзегән, татарларга рус телен өйрәтү һәм дөньяви фәннәрне укыту методикасын булдырган. Аларның ба-

рысына, шул исәптән Ш.Әхмәревкә дә, татарлар өчен бердәнбер диярлек дәүләти уку йорты булган бу мәктәпне оештыру һәм саклап калу өчен генә дә күп көч түгәргә туры килгән.

КТУМ эшли башлаган көннән үк, аны оештыручыларга үзара бер-берсенә капма-каршы, ләкин бу мәктәпкә мөнәсәбәттә бердәм булган ике җитди көчкә каршы торырга туры килгән. Бу көчләрне, бер яктан, православ миссионерлар, икенче яктан, мәгърифәтче Габдулла Буби сүзләре белән әйтсәк, барлык искене изге, һәрбер яңалыкны хәрәм дип санаучы мөселман фанатиклары тәшкил иткән. Бу көчләр, төрле нигездә булса да, татарлар арасында фәнни белем таратуга, татарлардан дөньяви белем бирерлек укытучылар хәзерләүгә, гомумән, татар милли аңы формалашуга һәм мәдәнияте үсүгә каршы торганнар.

Хәтта ачылган көненнән алып тугыз ел дәвамында бу мәктәптә дин дәресләре алып барган Ш.Мәрҗанинең абруе да Казан мөтәгассыйбларын мәктәпкә пычрак атудан, Шиһаб хәзрәтне һәм башка укытучыларны ислам диненә каршы чыгуда гаепләүдән туктатып кала алмаган. «Фәкать Мәрҗанинең укыта башлавы никадәр яхшы ният вә халыкка файда итү теләге илә булса да, халык аның эшенә начар күз илә караган, аның дин дәресләре укытуын исламга зур җинаять дип уйлаган. ... Бу мәсьәләдә Мәрҗани зарарына тырышучы муллалар да байтак булган. Казанның бер мөдәррисе, олуг бер мәҗлестә: «Шиһаб мелла — миссионер, ул сатылган кеше. Русча укуга баш сәбәп ул гына булды. Кыяматтә кулыбыз якасында булсын», — дип сөйләгән. Билгеле, мондый сүзләр халыкка да таралып, аларга да тәэсир итеп, Мәрҗани хакында иң кабахәт ялган гаепләрне сөйләгәннәр. Иң яман сүзләрне ирештергәннәр. Мәрҗанигә явызлык итәргә хәзерләнүчеләр дә булган» [1], — дип күрсәткән Ш.Мәрҗанинең биографы Шәһер Шәрәф. Ш.Мәрҗанинең дошманнары гына түгел, дуслары да аның бу адымын аңлап та, өнәп тә җиткермәгән. Әгәр дә халык мөхтәрәм галим, дин белгеченең КТУМга килүен шулай кабул иткән икән, Шаһбазгәрәй әфәнде кебек рус урта һәм гали мәктәбендә белем-тәрбия алган шәхеснең татар егетләрен укыту-тәрбиягә алынуының ничек бәяләнүен аңлатып торасы да юк.

1881 елда мәктәпнең тәүге директоры М.Мәхмүдев пенсиягә озатылгач, шул елның 1 августыннан бу вазифа 28 яшьлек Шаһбазгәрәй Әхмәревкә йөкләнгән. Бу эшендә аңа В.В.Радлов һәм Ш.Мәрҗани күп ярдәм күрсәткән. Ләкин 1884 елдан, ике галим дә мәктәптән киткәч, Ш.Әхмәрев абруйлы остазларсыз калган. Ә бу дәвер Россия тарихында, бигрәк тә мәгариф өлкәсендә, контрреформа еллары булуын искә төшерсәк, яшь директорга мәктәпне саклап калу өчен күпме гайрәт, күпме көч кирәклеген дә аңлау мөмкин булыр. Мәктәпкә нигез салучы, аның яклаучысы булган В.В.Радловның Петербургка күчеп китүеннән файдаланып, атаклы Н.И.Ильминский мәктәпкә каршы һөҗүмен тагын да көчәйткән. Шул ук 1884 елда, казна акчасына мөселманнардан укытучылар хәзерләүнең зарарлыгын дәлилләп (имеш, дәүләти күзлектән караганда), Н.И.Ильминский мәгариф министры И.Д.Делянов һәм Синодның обер-прокуроры К.П.Победоносцев алдында Казан һәм Оренбург татар укытучылар мәктәпләрен ябу мәсьәләсен куйган. Зур авырлыклар белән булса да, В.В.Радлов һ.б. ярдәмендә Ш.Әхмәрев КТУМны саклап кала алган. Ләкин миссионерлар да бирешмәгән: 1890 елда алар тырышлыгы белән Оренбург мәктәбе ябылган.

1892 елда И.Д.Делянов яңадан КТУМны ябу мәсьәләсен күтәргән һәм Казан уку-укыту округы попечителеннән бу мәсьәләгә ачыклык кертүне

Әхмәревләр гаиләсе. Казан, 1912-1913 еллар

сораган. Попечитель, үз чиратында, Ш.Әхмәревкә бу мәсьәләдә үз фикерен дәлилләргә тәкъдим иткән. 1892 елның 30 сентябрендә язылган рәсми хатында Шаһбазгәрәй әфәнде мәктәпне саклап калуның кирәклеген дәлилләүне түбәндәгечә башлаган: «Укытучылар мәктәбе татар җәмгыяте тарафыннан булган һөҗүм дәверен кичерде инде. Аңа, христиан дине нигезләрен халык арасына уздыручы һәм татарларны руслаштыручы корал итеп, дошманнарча карамыйлар инде. Укучылар да милли принципларны сатучы буларак кабул ителми. Укытучылар мәктәбенең йогынтысы да киңәйде. Моннан ун-унбиш ел гына элек татарлар мәктәп шәкертләре белән бөтенләй аралашмый иде, хәзер исә алар татарлар өчен кирәк кешеләрдән санала»[2].

Инспектор КТУМда укытучылар хәзерләүнең татарлар арасында рус телен һәм дөньяви белем нигезләрен таратудагы роленә дә тукталган, рус хакимиятенең төрле адымнарына карата шикләнеп карарга өйрәнгән татарларның шик-шөбһәләре кимүендә мәктәпнең өлешен күрсәтергә дә онытмаган. Мәктәп эшчәнлегенең бу нәтиҗәләре хөкүмәтнең мәктәпне ачканда куйган максатларына туры килмәвен ачык күрсәтсә дә, Ш.Әхмәревнең әлеге рәсми хаты шулкадәр нигезле, уйланып язылган булган ки, аңа һ.б. документларга таянып, попечитель дә мәктәпне ябуга каршы фикер белдергән. Шулай итеп, КТУМ бу юлы да сакланып калган. Гомумән, Ш.Әхмәрев мәктәп белән идарә итүне бик акыллы алып барган, дип әйтергә була. Ул В.В.Радлов һәм Г.Мәхмүдев башлаган эшне — укытучылар коллективын туплауны да уңышлы дәвам иткән, КТУМда укыту-тәрбия эшләрен югары дәрәҗәдә башкаруга да зур игътибар биргән. Мәсәлән, ул башлап җибәргән дәрестән

тыш оештырылган тәрбияви чаралар арасында укучыларның рус телен яхшырак үзләштерүе максатыннан чыгып эшләнгән төрле әдәби кичәләр уздыруны һәм укучыларны рус театрына алып баруны әйтеп китәргә кирәк.

Укучылар хәзерләгән өзекләрне күрсәткән тәүге кичә 1897 елның 28 декабрендә булган. Укучылар бу кичәдә Н.В.Гогольнең «Өйләнү» һәм «Ревизор» пьесаларыннан өзекләр уйнаганнар. Бу чарадан соң төрле бәйрәмнәр яки истәлекле көннәргә багышлап кичәләр уздыру мәктәптә гадәткә кереп киткән. Бу кичәләр мәктәп укучыларының үзаңын үстерүгә, аларның дөньяга карашларын киңәйтүгә, әдәбият ярдәмендә мөстәкыйль рәвештә дөньяны танып белүгә өйрәтүгә бер этәргеч булган. Шуны да әйтергә кирәк: һәрбер шундый чара уздыру өчен, инспекторга попечитель һәм шәһәр полицмейстерыннан махсус рөхсәт алырга кирәк булган. Бу кичәләрне хәзерләү-оештыру эшен рус теле һәм әдәбияты укытучылары башкарган.

Ш.Әхмәрев милли-дини тәрбиягә дә зур әһәмият биргән. Бу юлда төп эшне, әлбәттә, дин дәресләрен алып барган Ш.Мәрҗани башкарган. Һәм инспектор мәктәп ачылган көннән алып тугыз ел буена монда армый-талмый хезмәт иткән бөек мәгърифәтченең эшчәнлеген һәрчак бик югары бәяләгән. Мәсәлән, 1883 елгы хисабында ул, Ш.Мәрҗанинең мәктәп укучыларын тәрбияләүдә зур роль уйнавын күрсәтеп, аның бу эшчәнлегенең нәтиҗәсен түбәндәгечә билгеләгән: «Мөселман гореф-гадәтләрен үтәү, атнага бер тапкыр булса да, мәчеткә йөрү, гадәти мөселманга хас тышкы күренеш һәм кием — болар барысы да халык күңелен мәктәп шәкертләре ягына тарта, яки, һич югында, алар турында төрле ялган һәм гайбәтләр таратып, мәктәпне ватандашлары алдында хурлау мөмкинлеген калдырмый» [3]. Ш.Мәрҗани мәктәптән киткәч, аңа алмашка икенче тәҗрибәле һәм абруйлы педагог, фольклорчы Таиб Яхинны (1845-1910) тәкъдим итүе дә Ш.Әхмәревнең булачак укытучыларга милли тәрбия бирүнең мөһимлегенә игътибар итүен күрсәтә.

Таиб Яхин гына түгел, мәктәптә эшләүче башка татар педагоглары да (Ибраһим Вәлиулла улы Терегулов (1852-1921), Шакирҗан Әхмәтҗан улы Таһиров (1858-1918) һ.б.), Ш.Мәрҗани башлап җибәргән эшне дәвам иткәннәр. Аларның бу эшчәнлеге татар җәмәгатьчелеге алдында мәктәп абруе үсүгә ярдәм белән генә чикләнмәгән. Гомумән, КТУМның Ш.Әхмәрев җитәкчелегендәге педагогик коллективы (монда алдынгы карашлы унлап рус педагогы да укыткан) үзенең эшчәнлеге белән миссионерларның мәктәптә руслаштыру сәясәтен үткәрүче укытучылар җитештерү үзәге ясау планын җимергән. Киресенчә, XIX гасыр азагына КТУМ, татарлар арасында беренче дөньяви урта мәктәп булып, чын зыялылар хәзерләү үзәгенә әйләнгән.

Рус һәм Европа мәдәниятен генә түгел, ислам динен һәм Шәрык классик әдәбиятын яхшы белгән, үзе чын зыялыларның үрнәге булган Ш.Әхмәрев 16 ел дәвамында КТУМны җитәкләү, шәкертләрне тәрбияләү белән генә чикләнмәгән. Мәгърифәтче буларак, ул ислам дөньясы, татарларның тормыш үзенчәлекләре һәм гореф-гадәтләре белән рус җәмәгатьчелеген дә даими таныштырып барган. Шушы максатны күздә тотып, Ш.Әхмәрев Казан матбугатында, бигрәк тә профессор Н.П.Загоскин нашир-мөхәррирлегендә чыккан «Волжский вестник» (1884-1906) исемле иҗтимагый-сәяси һәм әдәби газетада үз мәкаләләрен бастырган. Галимнең кайбер мәкаләләре «Городской и сельский учитель» исемле педагогик журналда (1894-1899, нашире һәм мөхәррире А.И.Анастасиев)

да дөнья күргән. Мәкаләләрен, гадәти буларак, «Мусульманин» исеме белән бастырып, Ш.Әхмәрев укучыларны татар җәмгыятенең хәле, андагы яңалыклар белән таныштырган, иске схоластик мөселман мәктәбен кискен тәнкыйтьләгән. Мәгърифәтчел рухлы галим мәкаләләрендә яңа, прогрессив рухта эшләүче М.Мәхмүдев, Г.Баруди кебек шәхесләрне мактап язган.

Үзенең тырышлыгы, эшчәнлеге белән Шаһбазгәрәй әфәнде казанлыларның зур ихтирамын яулый алган. 1896 елдан ул Казан шәһәр думасына әгъза итеп сайланган; шул ук вакытта Казан губернасының балалар приютларын күзәтүче оешманың да актив әгъзасы саналган. Аның иң изге теләге татар телендә газета чыгару булган, ләкин бу юлда уңышсызлык көткән. Берничә мисал.

1887 елда Казан сәүдәгәре һәм язучы, беренче татар драмасы авторы Габдрахман Ильяси (1856-1895), татар телендә «Казан» исемле газета чыгарырга рөхсәт сорап, хакимият органнарына мөрәҗәгать иткән. КТУМ инспекторы, коллежский советник (бу алтынчы класс чины) Ш.Әхмәрев язучының мөрәҗәгатенә үз исеменнән өстәмә дә кушкан. Аның эчтәлеге: «Баш идарә игътибарына түбәндәгене җиткерәм. Казанда башлангыч цензура белән атналык «Казан» газетасын чыгарырга мөмкинлек бирелгән очракта, әгәр дә матбугат эшләре буенча Баш идарә миңа рөхсәт итсә, мин аңа бушлай цензура ясарга алыныр идем» [4]. Күрәсең, татар зыялылары шулай Баш идарәнең, «Казанда шәркый телләр цензоры булмау»ны сылтау итеп, элеккеге мөрәҗәгатьләрне кире кагуын истә тотканнар һәм бу сәбәпне юкка чыгарырга тырышканнар. Ләкин Г.Ильясиның гаризасы бернинди дәлилсез кире кагылган, ә Ш.Әхмәревнең өстәмәсе, гомумән, игътибарсыз калдырылган (хакимиятнең ышанычын акламагандыр инде). 90 нчы елларда Ш.Әхмәрев үзе дә, «Казан» исемле татар газетасы чыгарырга рөхсәт сорап, өч мәртәбә Петербургка мөрәҗәгать иткән. Бу үтенечләре дә нәтиҗәсез калган. М.Х.Гайнуллин: «Аңа чиновниклар: «Дәүләт оешмаларында хезмәттә торган кешегә газета чыгару эше белән шөгыльләнү килешми», — дип җавап биргәннәр»[5], — дип күрсәткән.

Ни өчен Ш.Әхмәрев, югарыдагы түрәләрдән шелтә ала-ала, рус һәм татар телләрендә газета чыгару артыннан шулай йөргән? Аның кебек дәүләт хезмәтендә булган һәм кайгы-хәсрәтсез мул тормышта яшәгән чиновникка мондый мәшәкатьләр нигә кирәк булган соң?

Бу сорауларга җавапны без Ә.Г.Кәримуллин табып бастырган документлардан табабыз кебек. Шаһбазгәрәй әфәнде фикеренчә, татар тормышындагы торгынлыкны киметү өчен, «халык массалары арасында безнең ватаныбызның дәүләт һәм җәмгыять тормышына дөрес караш таратырга, файдалы белем алуга җәлеп итәргә, кирәкле һөнәрләрне һәм халыкны бает һәм дәүләткә файдалы булган бар нәрсәне үзләштерергә ярдәм итәргә» кирәк. Нәкъ менә әлеге эштә татарча газетаның файдасы булачак. «Бу юнәлештә эшләү өчен бердәнбер корал булып хәзерге вакытта татарларга язылышы һәм теле ягыннан аңлаешлы басма сүз генә хезмәт итә ала. Русча газета татар кешесе өчен тел ягыннан да, эчтәлеге буенча да аңлаешлы түгел, ул юнәлеше ягыннан да, программасы белән дә татарларның ихтыяҗларына хезмәт итә алмый; моннан тыш аның наширләре татар көнкүрешен, аның карашларын, гореф-гадәтләрен белеп җиткермиләр» [6], — дип ассызыклаган мәгърифәтче.

Патша хакимияте рус булмаган халыкларга үсеш мөмкинлекләре (татар телендә газета чыгарумы ул, мәктәп ачу булсынмы) бирергә омтылмаган.

Бу караш Казан губернаторының Ш.Әхмәрев гаризасы артыннан җибәргән рәсми хатыннан да ачык күренә. «Әхмәрев бик җитди кеше, төпле белемле, бигрәк тә инородецларга караган мәсьәләләр буенча; аның мөхәррирлегендә һәм җаваплылыгында газета чыгару газетаның юнәлеше хакында берниндн курку тудырмаска тиеш кебек», — дип язган губернатор. Ләкин Ш.Әхмәревкә бирелгән шундый югары бәядән соң, ул хатның дәвамын үзенең шик-шөбһәләренә багышлаган. «Шулай булса да, саклану кирәклеге хакында язмыйча да булдыра алмыйм. Татар телендәге әдәбият һәм матбугат үсеше Россиядә яшәүче рус булмаган халыкларга тәэсир итмәс дип уйламыйм. **Бу үсеш әйткән кавемнәрне рус халкына якынлаштыру һәм кушу өчен хезмәт итә алыр микән: татарларда үз диннәренә һәм телләренә булган мәхәббәт бик көчле; Россиядә яшәүче барлык халыклар арасында татарлар русларга кушу сәясәтенә иң аз бирелүчән: аларның туган телендә әдәбият үсеше исә инородецлар арасында милли үзаң уянуына һәм — моннан да куркынычрак булырга — сәяси хыяллар барлыкка килүенә китерергә мөмкин»** [7] (Фикерләрне губернатор ассызыклаган — *А.М.*).

Беренче карашка, Ш.Әхмәрев тә, губернатор да бер үк нәрсә хакында сөйлиләр кебек — татар һәм рус халыкларының бер-берсенә якынаюы хакында, тик аларны бер-берсеннән бик ерак торган, бөтенләй үзгә нәрсәләр борчыган. Ш.Әхмәрев халыкларның мәдәни якынаюын, мәгариф, дөньяви белем таратып, үз халкының артта калуын бетерүне теләсә, губернатор, беренче чиратта, татарларның русларга кушылуын, ягъни татарларны руслаштыруны күз алдында тоткан. Һәм, әлбәттә, татар халкы арасында мәгариф тарату (нинди генә формада булмасын) аны берничек тә канәгатьләндермәгән.

Теге яки бу шәхескә багышланган хезмәтләрдә без, беренче чиратта, аның иҗтимагый-сәяси йөзен ачыкларга тырышабыз. Бу очеркны да Ш.Әхмәревнең эшчәнлеген, аның карашларын тасвирлаудан башлау әлеге традициягә кайтып кала. Шул ук вакытта шәхеснең гаиләсе, шәхси даирәсе турында сүз башларга да вакыт җиткәндер. Шаһбазгәрәй әфәнденең гаиләсе нинди булган соң?

Аның хәләл җефете Хәдичә ханым (1861-1944) борынгыдан килгән татар аксөякләре, данлыклы Алкиннар нәселеннән булган. XIX-XX гасырларда бу нәселдән татар иҗтимагый тормышында күренекле урын алып торган шактый күп шәхесләр чыккан. Хәдичәнең әтисе, Шаһиәхмәт Мөхәммәт углы Алкин (1812-1878), Казан татарларыннан беренчеләрдән булып, Казанда тәүге ирләр гимназиясендә укыган, шәһәр идарәсендә төрле хезмәтләр башкарган. 1846 елда аны Казан полицмейстеры урынбасары итеп билгеләгәннәр. Коллежский советник дәрәҗәсенә (алтынчы чин) ия Ш.Алкин халык арасында намуслы, гадел һәм таләпчән полиция башлыгы буларак дан казанган.

Шаһиәхмәт һәм аның хатыны Хөсниҗамалның (сәүдәгәр Арсаевлар нәселеннән) дүрт улы һәм өч кызы булган. Үзе дөньяви белем алган Шаһиәхмәт балаларына да яхшы белем бирергә теләгән. Аның дүрт улы да гимназиядә укыган, аларның икесе университет тәмамлаган. Араларында иң билгелесе — Сәетгәрәй (1867-1919) шәһәрнең атаклы юристларыннан саналган һәм XX гасыр башына абруйлы җәмәгать эшлеклесе булып җитешкән. Алкиннарның кызлары Мәрьям, Хәдичә һәм Зөләйха, ул заман гореф-гадәтенчә, өйләрендә абыстайдан дин сабагын да тиешенчә алганнар, укырга-язарга да өйрәнгәннәр.

1878 елда, Мәрьямгә — 19, Хәдичәгә 17 яшь тулгач, Алкиннар йортында бер-бер артлы яучылар күренә башлаган.

Әлбәттә, мондый абруйлы нәсел белән туганлашырга теләүчеләр арасында яңа гына университет тәмамлап, КТУМ-да даими эшкә алынган Шаһбазгәрәй Әхмәрев тә булган. «Чабаталы морза» баласы булса да, аксөяк, укымышлы, күркәм холыклы егетне Алкиннар кире какмый. Кызларның фикерен дә сораганнар. Мәрьям үзенә шулай ук затлы, ләкин бай нәселдән чыккан Салих Саиновны сайлаган, ә Шаһбазгәрәйгә Хәдичәне ярәшкәннәр.

Ул чор гореф-гадәтләре туйга кадәр егет белән кызның күрешү-сөйләшү, мәхәббәт аңлашуларын рөхсәт итмәгән. Шулай да гыйлемле кияү егете кәләше белән аралашу, аның кыяфәтен, акыл-белем дәрәҗәсен бәяләү юлларын уйлап тапкан. Ул, булачак гаиләгә карата үзенең карашларын аңлатып, яучы карчык аркылы кызга хат күндергән. Ләкин хат Хәдичә белмәгән рус телендә язылган булган. Гимназиядә укучы энеләре ярдәмендә кыз язылганнарның эчтәлеге белән танышкан һәм татарча үз фикерләрен язып җибәргән.

Шаһбазгәрәй кызны күрү юлын да тапкан. Алкиннарның рус театрында үз ложалары булган. Сирәк кенә булса да, спектакль карарга кызларны да алып бара торган булганнар. Күрешеп танышу мөмкин булмаганны белгән егет Хәдичәнең әтиләреннән билгеле бер көнне кызны театрга алып килүләрен үтенгән. Алкиннар ризалык биргәч, Ш.Әхмәрев үзенең партерда булачагын хәбәр иткән. Менә билгеләнгән кич килеп җиткән. «Очрашу-танышу» минутлары: кыз — өстә, ложада, егет — партерда, бер-берсен күзләгән, күрәсең — ошатканнар.

Гаилә коргач, Шаһбазгәрәй әфәнде хәләл җефете Хәдичәнең белемен арттыру эшенә керешкән: ул аның өчен махсус программа төзегән, укырга тиешле китаплар исемлеген билгеләгән. Рус телен даими үзләштерү белән бергә, Хәдичә ханымга кияүгә чыкканчы таныш булмаган күп кенә нәрсәләргә өйрәнергә туры килгән: француз теле дисеңме, этикет кагыйдәләре, төрле кичә-баллардагы бию-уеннар дисеңме…

Казанда татар хатын-кызлары арасында беренче гинеколог Маһипәрвәз Әхмәрева (Дәүләткилдиева). Казан, 1914 ел

Тормышларының күп өлешен Әхмәревләр КТУМ каршындагы инспектор гаиләсе өчен махсус билгеләнгән фатирда яшәгәннәр. Гаилә ишәя башлагач, алар шул ук Иске татар бистәсендәге Зур Мещан урамында (хәзерге Нариманов урамы) икекатлы йорт сатып алганнар. Әхмәревләр дүрт кыз һәм өч егет үстергәннәр. Балалар бер үк вакытта дини-милли тәрбия дә, Европа-рус тәрбиясе дә алган.

Беренче балалары Маһипәрвәз (1880-1962) мәктәп яшенә җиткәч, Әхмәревләр алдында кызны ничек һәм кайда укыту мәсьәләсе килеп баскан. Педагог Шаһбазгәрәй әфәнде кызына дин нигезләрен генә укыту аз булуын,

дөньяви белем кирәклеген яхшы аңлаган. Ләкин кайда укытырга? Өйдәме, әллә рус гимназиясенә бирергәме? Моңа кадәр Казанда кызларын рус гимназиясендә укыткан татарлар булмавы да борчыган аны. Әгәр дә кызын берүзен генә рус мәктәбенә йөртсәң, бу аңа зарар китермәсме? Озак кына уйлаган-киңәшкәннән соң, Әхмәревләр Мәһипәрвәзне рус гимназиясенә укырга хәзерләргә булганнар. Кечкенә кызлары ят мохиттә үзен ялгыз хис итмәсен дип, Әхмәревләр ут күршеләре поручик Шәехгаттар Әсфәндияр углы Гобәев һәм аның җәмәгате Хәнифәне Мәһипәрвәзнең яшьтәше һәм дусты булган кызлары Рөкыяны да бергә укытырга күндергәннәр. Кызларны гимназиягә Ш.Әхмәрев төзегән махсус программа буенча әзерләгәннәр. 1891 елның августында кабул итү имтиханнарын уңышлы тапшырган бу ике кызчык, татар кызларыннан беренче булып, Казанның Ксенинская гимназиясендә укый башлаган.

Тиздән Әхмәревләр шәһәрнең рус өлешеннән йорт сатып алып, шунда күчәргә карар кылганнар. Яңа йортка күчкәндә, Әхмәревләр гаиләсе шактый ишле булган: балалары Мәһипәрвәз, Суфия, Ильяс, Сара, Давыт үсеп килгән. Шаһбазгәрәй әфәнденең тол калган сеңлесе Фатыйма Терегулова да үзенең ике улы Хәсән һәм Мөхәммәт белән бирегә килеп сыенган. Әлеге йортта исә тагын ике бала — Йосыф һәм Заһидә дөньяга килгән. Шәһәрнең руслар яшәгән өлешенә күчкәч, гаилә яңача — мәхәллә халкыннан тарсынмыйча, Европа мәдәнияте нигезендә корылган тормыш-көнкүреш белән яши башлаган.

Үзе үскән мөселман гореф-гадәтләренә тугрылыклы гаилә мохитеннән аермалы буларак, Хәдичә ханымга үз гаиләсенең тормышын үзгә кануннарга нигезләп төзергә кирәк булган. Бер яктан, моны Шаһбазгәрәй әфәнденең хезмәте, аралашу даирәсе сораса, икенчедән, заман, вазгыять тә шуны ук таләп иткән. Сәләте, тырышлыгы, хирыслыгы Хәдичә ханымга бу эшне башкарырга да булышкан. Әлбәттә, хатынына рус-Европа кануннарына нигезләнгән мохиткә күнегергә Шаһбазгәрәй әфәнде үзе дә күп ярдәм иткән. Һәм берничә ел эчендә яшь ханым, үзе һәм балалары яратып укыган әкияттәге гүзәл кызга әйләнгән бака кебек, укымышлы, Казан югары катлам ханымнарыннан калышмыйча, рус-Европа гадәтләрен яхшы белүче, шул ук вакытта чын мөселман хатын-кызларына хас нәзыйгъ һәм күркәм тәрбияле асыл зат — бикә булып җитешкән. Хәдичә ханым, үзе уйнарга өйрәнмичә калса да, музыканы бик яраткан, рус театрында ешрак булырга тырышкан (драма, опера, балет — һәрберсен караган). Әхмәревләрнең рус театрында даими абонементлары да булган. Үзе яхшы биюче Шаһбазгәрәй әфәнде хатынын да балларда катнашырлык дәрәҗәдә биергә өйрәткән. Истәлекләргә караганда, Хәдичә-ханымга бу шөгыль ошап киткән (ул бигрәк тә кадриль биергә ярата торган булган).

Яңа урынга күчкәч, Әхмәревләрнең аралашу даирәсе дә шактый киңәйгән. Кабан артында яшәгәндә, ул чакта Казанда бик аз санда булган татар зыялылары — Алкиннар, Мәхмүдевләр, Саиновлар, Терегуловлар гаиләләре белән ешрак аралашсалар (аларны туганлык җепләре бәйләвен дә истә тотыйк), хәзер аларның кунакчыл йортына Шаһбазгәрәй әфәнде университетта укыганда ук дуслашкан рус интеллигенциясе вәкилләре дә даими килә башлаган. Әлбәттә, элек тә Әхмәревләр рус интеллигенциясе белән аралашып яшәгән, шәһәрнең өске өлешенә кунакка, театрга, төрле мәҗлесләргә, балларга йөргән. Татар бистәсендә яшәгән чакта да алар үзләрендә «шәһәр» кунакларын кабул иткән. Ләкин яңа йортта урын да иркенрәк, килү-кайту өчен мөмкинлекләр дә күбрәк булган…

Ш.Әхмәрев һәм аның дуслары (университет профессорлары Н.М.Любимов, Н.П.Загоскин, Н.Ф.Катанов, КТУМ укытучылары И.В.Терегулов һәм М.Н.Пинегин), күрешкәч, озын-озак сөйләшүләр дә, фикер алышулар да, кызу-кызу бәхәсләр дә алып барган.

Балалар үскән. Суфия гимназиягә, Ильяс белән Давыт реальное училищега укырга кергән. Әхмәревләрнең туганнары, дуслары гаиләләрендә дә рус мәктәпләрендә укучы балалар күренә башлаган. Олылар дуслыгына балалар дуслыгы өстәлгән. Әхмәревләр йортында балаларының дуслары да — гимназисткалар, реалистлар җыелган. Гасыр азагында Казанның затлы гаиләләрендә балалар өчен төрле бәйрәмнәр, әдәби-музыкаль кичәләр уздыру модага кереп киткән. Әхмәревләр дә рус зыялыларыннан калышмаган — өйләрендә балалар өчен төрле бәйрәмнәр, чәйләр, уеннар оештырганнар. Кайчак балалар кечкенә концертлар да куйганнар: шигырьләр уку, җырлау, бию... Мондый чараларны төп оештыручы Хәдичә ханым булуын әйтеп торырга да кирәкмидер. Күрәсең, 1903 елда рус мәктәпләрендә укучы татар яшьләренең «Шимбә» түгәрәге нәкъ менә Әхмәревләр йортында оешу очраклы гына булмагандыр.

Үзенең белемен арттыруны бурычы дип санаган Хәдичә ханым ире һәм С.П.Эпштейн ярдәме белән шактый зур уңышларга ирешкән. Ул даими рәвештә рус язучыларының әсәрләрен укыган. Аның бу гадәте гомерлеккә әйләнгән. Ул чорның күп кенә зыялыларына хас булган кебек, Әхмәревләр дә Л.Н.Толстой әсәрләрен яратып укыганнар, аның уй-фикерләре белән мавыкканнар. Нәкъ менә Л.Н.Толстой идеяләре белән мавыгу Хәдичә ханымны тәрҗемә эшенә керешергә этәргән. Рус телен яхшырак үзләштерү, балаларына үгет-нәсыйхәт бирү ягыннан да уңышлы булган бу эш. Тәҗрибәләрнең нәтиҗәсе дә күренгән: 1901 елда Оренбургта Х.Әхмәрева тәрҗемәсендә Л.Н.Толстойның берничә хикәясе кечкенә китапчык буларак дөнья күргән.

Хәдичә ханым газета укырга да гадәтләнгән. Башта ул иренең ятраткан газетасын — «Волжский листок»ны укыган. «Тәрҗеман» чыга башлагач, ул да Әхмәревләрнең көтеп алып укый торган газеталарына әйләнгән. Бер яктан, И.Гаспралының карашлары аларның фикерләренә туры килгән, икенчедән, газетаның икетелле булуы Хәдичә ханымга телне өйрәнергә ярдәм иткән. Алгарак китеп булса да, әйтим: Казанда татар матбугаты барлыкка килгәч, Хәдичә ханым энесе Сәетгәрәй әфәнде Алкин чыгарган «Казан мөхбире» газетасының даими абунәчесе булып киткән, башка басмалардан да хәбәрдар булырга ярата торган булган.

Әхмәревләр тәрбия эшендә ислам нигезләренә дә таянган. Балалар ислам кануннарын да ихтирам иткән, татар телен дә камил белгән, рус һәм Европа телләрен дә мөкәммәл үзләштергән. Аларның төпчек кызлары Заһидә ханым Тинчуринаның күренекле артист Габдулла Кариевка багышланган истәлекләреннән өзек: «Ул вакытлар өчен типик интеллигент семьясында тәрбияләнеп, рус һәм көнбатыш классик әдәбиятын яшьтән үк укып үскән һәм Тургеневның «Накануне» романындагы Елена кебек героиняларын идеаллаштырган бер кыз буларак, мин, яшьтәшләрем кебек үк, прогрессив идеяләр белән сугарылган идем. Ләкин без политикадан ерак тора идек...» [8]. Аның бу сүзләрен тулысынча апалары һәм абыйларына карата да әйтергә булыр иде. Үскән саен аларда әти-әниләренә, гомумән, зыялыларга хас булган сыйфатлар — китапка, музыкага, театрга тартылу ачыла барган...

1900 елның язында дус, тату, тулы тормыш белән яшәгән бәхетле гаиләгә кара кайгы килгән: 8 апрельдә Шаһбазгәрәй әфәнденең кинәт темпе-

ратурасы күтәрелгән, ул аяктан егылган. Консилиумга җыелган университет профессорларының диагнозы — вакытында дәваланмаган аппендицит нигезендә перитонит барлыкка килгән. Операция ясарга инде соң булган, һәм 9 апрельдә яңа гына 47 яшен тутырган Шаһбазгәрәй әфәнде дөнья куйган. 39 яше дә тулмаган Хәдичә ханым берсеннән-берсе яшь җиде бала белән калган. Аларның олысы Маһипәрвәзгә — егерме, кечесе Заһидәгә нибары өч яшь кенә булган. «Балалар ятимлекне сизмәсләр, барысы да белемле, укымышлы булырлар!» — Үлем түшәгендә яткан иренә Хәдичә ханым шундый вәгъдә биргән. Шулай итеп, аларны укыту-тәрбияләү, кеше итү — барысы да тол ханымның җилкәсенә төшкән.

Шаһбазгәрәй Исмәгыйль улын соңгы юлга озату казанлылар моңа кадәр күрмәгән зур иҗтимагый чарага әверелгән. Беренчедән, мәгърифәтче белән хушлашырга татарлар гына түгел, күп кенә күренекле рус зыялылары да килгән. Мәгърифәтчене соңгы юлга озатуда Казан уку-укыту округы попечителе М.М.Алексеенко һәм аның урынбасары А.А.Остроумов, халык мәктәпләре инспекторы Н.Ф.Свешников, университет профессоры Н.М.Любимов, генерал-майор Шамил, шәһәр думасы әгъзалары, КТУМ укытучылары һәм укучылары һ.б. катнашкан. Юныс мәйданында мулла, шәкерт, студент, сәүдәгәр һәм гади халыктан гыйбарәт берничә йөз мөселман намазга җыелган.

Икенчедән, бу хакта «Казанский телеграф» газетасы 1900 елның 15 һәм 16 апрель саннарында махсус хәбәрләр урнаштырган. Аның беренчесе редакция материалы булса, икенчесендә вакыйганың шаһиты үз тәэсирләре белән бүлешкән. Г.И. хәрефләре белән имзаланган бу язманың авторы КТУМ укучысы булуы мәкаләнең эчтәлегеннән аңлашыла. Бу вакытта мәктәптә Г.И. инициаллы ике укучы гына булган: берсе — Исмәгыйль Габитов, икенчесе — Гаяз Исхакый. Кайгылы хушлашу сүзләренең авторы аларның кайсы гына булса да, укучыларның остазларын чын күңелдән яратулары, ихтирам итүләре сизелеп тора.

Ш.Әхмәревнең кинәттән вафат булуы гаиләгә һәм дус-ишләргә генә кара кайгы алып килмәгән дип ассызыкларга була. Мәкаләгә эпиграф итеп алынган Г.Тукай гыйбарәсен куллансак, «гафилләргә дөнья тарая» барган заманда Шаһбазгәрәй әфәнде кебек «күзе ачык кешеләр»нең иң күренеклесен югалту казанлыларны (татарларны гына түгел, русларны да) тетрәндергән. Ләкин бу югалтуның зурлыгын ул чакта күпчелек әле аңлап җиткермәгән. Бары соңрак, Шаһбазгәрәй әфәнде шәкертләре олы юлга аяк баскач кына, мәгърифәтче гомере буена башкарган эшнең әһәмиятен аңларга җирлек барлыкка килгән (аларның XX гасыр башында татар иҗтимагый һәм мәдәни тормышында әйдәп баручылар — Гаяз Исхакый, Садри Максуди, Гафур Коләхмәтев, Хөсәен Ямашев һ.б. буыны булуын да искә төшерик).

Әдәбият

1. Мәрҗани: Фәнни-популяр җыентык. — Казан: Җыен, 2010. — Б.136-137.
2. ТР ФА, ф.92, оп.1, д.19983, л.2.
3. ТР ФА, ф.92, оп.1, д.16166, л.24.
4. РДТА, ф.776, оп.12, 1887 г., д.49, л.3.
5. Гайнуллин М.Х. Татарская литература XIX века. — Казань: Татар.кн.изд-во, 1975. — С.65.
6. Каримуллин А.Г. Татарская книга пореформенной России. Исследование. — Казань: Татар.кн.изд-во, 1983. — С.205.
7. Шунда ук. — Б.207.
8. Кариев Г. Мәкаләләр, истәлекләр, документлар. / Төз. Гобәйдуллин Х. — Казан: Татар. кит.нәшр., 1976. — Б.136. ■

ТАТАРСТАННЫҢ ХАЛЫК ШАГЫЙРЕ,
ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЫ

СИБГАТ ХӘКИМ

(04.12.1911 – 03.07.1986)



***

Тукта, бер үткән гомерне
Искә төшерим дисәң,
Искә төшереп, бурычны
Өстән төшерим дисәң,
Башка мәшәкатьләреңнең
Карамый барлыгына,
Ялгызың тот та кырга чык,
Карабодай кырына.

Иртән дә, көндез дә түгел,
Көт кояш баеганын,
Көт шәфәкъка манылганын
Ышнада каеннарның, –
Карабодай чәчәгенә
Йогар шәфәкъ сарысы,
Хисләргә йогар сарысы,
Уйнар күңел сагышы.

Ахрысы, якты бу дөнья
Бездән дә кала бугай,
Офыклар артына батып
Бара күк карабодай.

* Шагыйрь Сибгат Хәкимнең кайбер сүз энҗеләре белән журналның башка битләрендә таныша аласыз.

ГАБДРӘШИТ ИБРАҺИМНЫҢ «ӘЛ-ҖИҺАД» ГАЗЕТАСЫНДА БАСЫЛГАН МӘКАЛӘЛӘРЕ

СЕБАСТЬЯН ЦВИКЛИНСКИ,
фәлсәфә фәннәре докторы,
Берлинның Азат университеты (Германия) Тюркология институтының штаттан тыш гыйльми хезмәткәре

СЕЗНЕҢ ИГЪТИБАРЫГЫЗГА ТӘКЪДИМ ИТЕЛӘ ТОРГАН ТЕКСТЛАР ГАДӘТИ БУЛМАГАН ШАРТЛАРДА БАРЛЫККА КИЛГӘН. АЛАР 1915 ЕЛДА ТАТАР ПУБЛИЦИСТЫ ҺӘМ СӘЯСӘТЧЕСЕ ГАБДРӘШИТ ИБРАҺИМ (1857-1944) ТАРАФЫННАН ГЕРМАНИЯ ЧИТ ИЛ ЭШЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ КУШУЫ БУЕНЧА ЯЗЫЛГАН ҺӘМ ШУЛ УК ИЛНЕҢ ТӨРЛЕ ЛАГЕРЬЛАРЫНДАГЫ МӨСЕЛМАН ХӘРБИ ӘСИРЛӘРЕ ӨЧЕН ДӨНЬЯ КҮРГӘН «ӘЛ-ҖИҺАД» ГАЗЕТАСЫНДА БАСТЫРЫЛГАН.

Бу мәкаләләр шактый мөһим вакыйгалар белән бәйле. Шуларның иң әһәмиятлесе — Беренче Бөтендөнья сугышы алдыннан башланган Германия һәм Госманлы империясе хезмәттәшлеге. 1912-1913 еллардагы Балкан сугышыннан соң дөнья масштабындагы яңа сугышның котылгысызлыгы ачык күренә, шунлыктан Германия, шул исәптән Госманлы империясе дә, үз мәнфәгатьләрен кайгыртып, бер союздаш табарга тырыша. Ислам дөньясына йогынты ясар өчен, Германиягә иптәш кирәк була. Госманлылар Балкан сугышында шактый зур югалтулар кичерә, җиңелүдән соң хакимиятне Әнвәр паша җитәкчелегендә яулап алган яшь төрекләр дәүләтне коткару юлларын эзли башлый, ә Германия-Госманлы империясе хезмәттәшлеге котылып калуның күп чараларыннан берсе генә була.

Германия һәм Госманлы империясе хезмәттәшлегенең башлангыч ноктасы дип 1913 елгы ике дәүләт арасында хәрби хезмәттәшлек турында шартнамә санала. Беренче Бөтендөнья сугышы башлану белән, ике як та 1914 елның август аенда хезмәттәшлекне сугыш вакытында да дәвам итү турында өстәмә яшерен килешү төзиләр. Германия сәясәтенең мөселманнарга мөнәсәбәтле төп юнәлешләре 1914 елның октябрендә дипломат Макс фон Оппенгейм (1860-1946) тарафыннан язылган меморандумда ачык чагылыш

таба [1]. Оппенгейм үзенең меморандумында Көнчыгыш мөселман халыкларын Англия, Франция һәм Россиягә каршы баш күтәрергә чакыра. Аның концепциясендә Якын һәм Урта Көнчыгыш колонияләрендәге мөселман милләтләре белән Россия империясендәге мөселманнар арасында аерма булмый. Немец дипломаты мөселманнарны баш күтәрүгә котыртуның иң мөһим юлы дип, госманлы хәлифәгә басым ясап, изге сугыш — җиһадны игълан кылырга мәҗбүр итүне саный.

الجهاد
EL DSCHIHAD
Berlin den 23. Juni 1915
Nr. 8
Zeitung für die muhammedanischen Kriegsgefangenen
Turkotatarische Ausgabe
ای اسیر بولغان قرنداشلر

«Әл-Җиһад» газетасының титул бите. 1915 ел, 23 июнь саны

Пропаганда сәясәтен тормышка ашыру өчен, Макс фон Оппенгейм махсус үзәк оештырырга тәкъдим иткән. Шуның нәтиҗәсе буларак, Германия Чит ил эшләре министрлыгы каршында Оппенгеймның рәислегендә Көнчыгыш мәгълүмат үзәге (Nachrichtenstelle für den Orient) төзелә. Мәгълүмат үзәгенең төп бурычы — Англия, Франция һәм Россия армияләреннән Германиягә әсир төшкән мөселман гаскәриләре арасында пропаганда үткәрү. Германия һәм Госманлы империясенең тыгыз хезмәттәшлеге нигезендә ясалган әлеге пропаганданың максаты мөселман хәрби әсирләрен госманлы гаскәре сафларында җиһадка катнашуга өндәү була. Бу очракта алманнар беренче нәүбәттә «реклама» эффектына өметләнә. Инглиз, француз колонияләрендәге һәм шулай ук Россия империясендәге мөселманнар Германиядәге әсирләрнең Госманлы дәүләтен яклап хәрби хәрәкәтләрдә катнашуларын кайгыртучанлык дип кабул итеп, алар арасында Алман дәүләте мөселманнарның хакыйкый дусты икән дигән иҗтимагый фикер оешыр дип уйлыйлар. Алманнар фикеренчә, мөселманнар моны «аңлаганнан» соң, Англия, Франция һәм Россиягә каршы баш күтәрәчәк.

Макс фон Оппенгейм бу сәясәтнең төп юнәлешләрен билгеләү белән генә чикләнеп калмый, аны тормышка ашыруда да актив катнаша. Ул 1915 елның башында Көнчыгыш буенча мәгълүмат үзәге рәисе вазифасыннан азат ителеп, Истанбулга бара һәм, Германиянең илчелеге белән бергә әлеге сәясәтне гамәлгә ашырыр өчен, гарәп һәм татар пропагандистлары табарга тырыша. Ул даими рәвештә Германия Чит ил эшләре министрлыгына яңа пропагандистлар тәкъдим итә, ә бу тәкъдимнәр һәрвакыт Яшь төрекләр җәмгыяте белән киңәшләшеп эшләнә. 1915 елның апрель аенда алман дипломатының игътибарын 1910 елдан бирле Истанбулда яшәгән татар публицисты һәм җәмәгать эшлек-

лесе Габдрәшит Ибраһим җәлеп итә. 20 апрельдә Германия Чит ил эшләре министрлыгына җибәргән меморандумында немец дипломаты, аның лаеклы кандидат икәнлегенә ышанычын белдереп: «Габдрәшит Ибраһим — Себердән килгән, озак вакыт Казанда һәм Россиянең башка төбәкләрендә яшәгән кеше. Япония, Хиҗаз кебек җирләргә зур сәяхәтләр кылган. Бу гыйлемле инсан шәех, оратор һәм рухи остаз буларак олы ихтирам казанган. Ул һәрвакыт панисламизм белән шөгыльләнгән һәм әлеге юнәлештә журналист буларак та эшләгән» [2].

Бу хат язылганнан соң, бер атна үткәч, Габдрәшит Ибраһим Берлинга килә һәм Көнчыгыш мәгълүмат үзәгендә эшли башлый. Үзәк аңа ике төп бурыч йөкли. Беренчесе — хәрби лагерьлардагы татар һәм башкорт әсирләре өчен имам вазифасын башкару һәм җомга вәгазьләре, шәхси әңгәмәләр вакытында әсирләрне госманлыларны яклап сугышта катнашырга кирәклегенә инандыру. Икенчесе — шул юнәлештә мәкаләләр язу. 1915 елның май уртасында Г.Ибраһим министрлыкка беренче мәкаләсен текъдим итә. Ул, Россия армиясендәге мөселман гаскәриләренә мөрәҗәгать итеп, аларны рус гаскәреннән качарга чакыра һәм хәлифнең дошманнарына итагать иткәннәре өчен вөҗдан газабын кичерергә кирәклеге турында яза. Икенче өндәмәсендә Габдрәшит Ибраһим татар хәрби әсирләренә мөрәҗәгать итә, аларга вөҗдан газабы кичерергә кирәклеге турында искәртеп, госманлы тарафына чыгуның стратегик файдасын күрсәтергә тырыша [3].

***

Укучыларга тәкъдим ителгән текстлар 1915 елның май аеннан башлап Габдрәшит Ибраһим тарафыннан мөселман әсирләре өчен гарәп, рус һәм татар телләрендә дөнья күргән «Әл-Җиһад» газетасы өчен язылган. Газетаның гарәпчә басмасы Төньяк Африка әсирләренә адресланса, русча басмасы Кавказ мөселманнары өчен чыгарылган. «Төрки-татар» басмасы (немец телендә: Turkotatarische Ausgabe) исә иң элек, әлбәттә, татар һәм башкорт әсирләр өчен бастырылган, әмма, Габдрәшит Ибраһимның госманлы төрекләре телендә язылган бер мәкаләсеннән күренгәнчә, газетада азәрбайҗан әсирләре өчен дә мәкаләләр була [4]. «Әл-Җиһад»ның төрки-татар һәм русча басмаларында Г.Ибраһимның бишәр мәкаләсе дөнья күргән, бу мәкаләләрнең дүртесе мөрәҗәгать рәвешендә язылган, шуларның өчесе татарча, берсе саф госманлы төрекләре телендә. Русча мәкаләләр исә — татар һәм госманлы телендәге мәкаләләрнең тәрҗемәләре. Алар күптән түгел безнең тарафтан бастырылды [5]. Татар һәм рус телләрендәге мәкаләләр арасындагы аерма юк диярлек, шулай да берникадәр үзгәлекләр күзгә ташлана. Мәсәлән, Габдрәшит Ибраһим дүртенче мәкаләнең татарча вариантында, Самара губернасыннан Истанбулга күчеп киткән мөселманнар турында сүз алып барганда, 1894 елда 70 мең татар гаиләсе күчеп киткәнлеге турында язса, русча текстта исә 1904 елда җиде мең гаилә күченде, ди.

Мәкаләләр Германия Чит ил эшләре министрлыгы куйган бурычларны гамәлгә ашыру максатыннан язылганга күрә, автор Германияне мөселманнарның иң «тугры дусты» булганын исбатларга тырыша. Шундый ук дәлилләрне Г.Ибраһимда гына түгел, Көнчыгыш мәгълүмат үзәге өчен язган башка авторларда да табарга мөмкин. Әмма мәкаләләрдә сәясәтченең үзенә генә хас бик күп аспектлар бар. Мәсәлән, Г.Ибраһимның мөселманнарның вөҗданына басым ясап мөрәҗәгать итүен һәм Россия мөселманнарын русларга каршы баш күтәрергә чакыруын аның 1907 елда Санкт-Петербургта үз басмаханәсендә нәшер иткән «Мең бер хәдисе шәриф тәрҗемәсе шәрхе» әсәрендә дә табарга мөмкин. Бу әсәр, мөгаен, госманлы әдибе Мәхмәт Арифнең хәдисләр туплан-

масы һәм комментарийләренең татарча тәрҗемәсе генә түгелдер, чөнки Г.Ибраһим госманлы авторының комментарийләрен тәрҗемә итү белән генә чикләнмичә, аларны Россия империясе мөселманнары тормышына адаптацияләшергә һәм радикальләштерергә тырышкан. Россия дәүләт органнары Г.Ибраһимның тәрҗемәсендә шактый күп хәвефхәтәрләр күреп, аны бер елга төрмәгә хөкем итә. Нәтиҗәдә, Г.Ибраһим 1908 елда Россия империясеннән кача [6]. Г.Ибраһимның Россия империясендә мәктәп-мәдрәсә системасының уңай роле турында ассызыклап мөрәҗәгать итүе дә яңалык түгелдер, чөнки автор 1908 елга кадәр берничә тапкыр Россия дәүләт органнарына шундый ук эчтәлекле гаризалар һәм язмалар тәкъдим иткән [7].

Әмма «Әл-Җиһад»та бастырылган мәкаләләрдә яңа аспектларны да табарга мөмкин. Мәсәлән, Г.Ибраһим Россия мөселманнарының 1904 елдан башланган милли хәрәкәте, Россиянең XVI гасырдан мөселманнарга каршы кылган сәясәтенең һәр адымын колониаль сәясәт буларак кына түгел, ә русларның гөнаһы буларак та тасвирлап, беренче тапкыр җентекләп язган. Г.Ибраһимның моңа охшаш карашлары «Әл-Җиһад» газетасында дөнья күргән мәкаләләреннән соң ике ел үткәч, янәдән Германиядә Көнчыгыш мәгълүмат үзәге тарафыннан чыгарылган бер журналда немец телендә басыла [8]. Әлеге барлык аспектларга да нәтиҗә ясап, Г.Ибраһимның «Әл-Җиһад»тагы мәкаләләре аның фекерләренең бер синтезы булган, дип әйтергә мөмкин.

I.

El Dschihad. Zeitung für die muhammedanischen Kriegsgefangenen. – Turkotatarische Ausgabe. – 1915. – Nr.8, 23. – Juni.

Б.1

ӘЙ, ӘСИР БУЛГАН КАРЕНДӘШЛӘР!

Әй, йортларыннан аерылып, ят илләрдә тоткын булып, ата-анасыннан, дус-ишләреннән, карендәш-ыругларыннан, туган-үскән җирләреннән ерак төшкән бичара гариб [ватаннарыннан аерылып, читтә яшәүче] кешеләр! Без сезгә чын күңелдән шәфкать кылабыз, бик ихлас берлән сезнең хәлегезне уйлап мәрхәмәт кылабыз, сезнең өчен кайгырабыз һәм, хакыйкать, чын күңелебездән кайгырабыз.

Әй, мөселманнар! Без сезнең ялгыз бу җирдә әсир булганыгыз өчен кайгырмыйбыз, чөнки сез хәзердә хакыйкатьтә әсир түгелсез, бәлки сез Германия патшалыгының газиз кунаклары вә хөрмәтле мосафирлары буласыз. Бу көндә Германия дәүләте вә Германия җәмәгатьләре сезләргә вә җөмлә мөселман әсирләренә хөрмәтле кунаклар дип карый, чөнки бу сугышта Германия дәүләте хәлифәи мөслимин Исламбул* патшаһы [9] берлән иттифак булып, җөмлә мөселманнарның хаксыз дошманы булган рус, англичан, француз дәүләтләре илә сугышып, һәммә мөселманнарның хак вә «право»ларын сакларга иҗтиһад кыладыр.

Җөмләгезгә [һәммәгезгә] мәгълүм Россия патшаһы, үзенең кул астында булган мөселманнарның мөкатдәс диннәренә, мәдрәсәләренә, мәсҗедләренә дәхи иркенчелек бирмәенчә, һәртөрле кысымчылыклар кылып, хәтта «Мәхкәмәи шәргыя» Духовное собраниеләренә дәхи дин исламны яхшы белмәгән кешеләрдән мөфти вә казыйлар сайлап куядыр, дәхи ничә төрле золым вә җәберләр кылып, бичара мөселманнарның җирләренең күбесен казнага алып бетерде, башкорт җирләрен тартып алып куйды, Төркестан тарафларында сартларның вә казахларның җирләренә рус авылларын утыртып, бичара мөселманнарның үз милекләре булган җирләрендә үзләрене ихтыярсыз кылды. Менә без, сезнең шундый хәлләрегезне уйлап, бик кайгырабыз, сез үз хәлегезне үзегез белмәгән сәбәпле, дусыгыз илә дошманыгызны аера алмаенча, сез-

* Истанбул

не даимән әсир хөкемендә тоткан вә сезнең үзегезне вә динегезне һәр заман хәкарәт кылып, хур кылган дошманнарыгызга итагать кылып, дусларыгызга каршы сугышка кердегез, бөтен дөнья мөселманнарының хәлифәләренең дусы булган хакыйкый дусыгызга мылтык аттыгыз.

Германия дәүләте, Германия кавеме вә җәмәгатьләре — ялгыз бүген өчен түгел, бу сугыш өчен генә дә түгел, бәлки һәрвакыт вә һәр заман өчен һәммә мөселманнарның дусыдыр. Чөнки мөселманнарның хәлифәсе вә дин исламның ялгыз гына патшаһы булган солтан Мәхмәд Рәшад Хан [10] хәзрәтләренең иттифак кылган дусларыдыр. Шул сәбәптән һәммә германнар мөселманнарның дусларыдыр, һәр мөселман һәр заман өчен буны шулай дип белергә тиеш.

Әй, хөрмәтле кунакларыбыз! Инде сезгә бу сүзләрне сөйләмәктән максадыбыз шулдыр ки: сез үз хәлегезне үзегез уйлагыз, бик яхшы тәфәккер кылыгыз, сугыш беткәч, солых булган заман, Хак Тәгалә хәзрәтләре насыйп иттерсә, тәкрар үзегезнең туган-үскән йортларыгызга кайтып, ата-ана вә карендәш ыругларыгыз илә күрешеп шатланырсыз, иншаллаһ. Ләкин шуны онытмагыз: сез тәкрар шул иске дошманыгыз кул астына кайтып торачаксыз. Сез никадәр туры булабыз, турылык кылабыз дисәгез дә, дошманнар сезнең малыгызны алыр, динегезне хәкарәт кылып, тәкрар сугыш булганда, шул дошманнарга итагать кылып, дин исламның пашалыгы булган хәлифә гаскәренә каршы, мөселман карендәшләрегезгә каршы мылтык атып, шәригать исламиянең хараплыгына сәбәп булырсыз, хәзер дә һәм Кавкасия тарафында Россия мөселманнары рус солдатлары берлән бәрабәр төрекләр мөселман карендәшләренә каршы сугыша. Хәлбуки, Пәйгамбәр галәйһи вәсәллам әйткән «сибап үл-мөслим фыскан вә кыйталуһу көферән» [дип], ягъни мөселманны сүкмәк — фасикълыктыр [имансызлыктыр], мөселманга каршы сугышмак — көферлектер. Ходай сакласын, дин дошманы булган русларга ярдәм кылып, мөселманнарга каршы вә мөселманнарның дусы вә мөселманнар берлән гаһед кылышып [килешеп] иттифак булган алманнарга каршы сугышмак вә аларга мылтык атмак, әлбәттә, ислам шәригатенә вә Коръән әмеренә хилафтыр.

Сез фикер кылмагыз, һич бервакыт уйламагыз Германия хөкүмәте бу сүзләрне үз файдасы өчен яздырадыр дип. Бүген Германия куәте һәр тарафта галиб [өстен] булып, дошманнарына каршы үзен саклар- га һәр заман кадир [көчле] улдыгы өчен башкаларның ярдәменә мохтаҗ түгелдер, ләкин хәзер дә бу сугышта мөселманнарның мәнфәгате берлән алманнарның мәнфәгать вә файдалары берләшмештер. Шул сәбәптән Германия хөкүмәте мөселманнарның киләчәк заманда рәхәт булмакларын фикер кылып, күзләрен ачмак өчен иҗтиһад кыладыр. Һәм бу иҗтиһадлары халис [чын] дуслык йөзеннәндер.

Б.2

Әй, мөселманнар! Киләчәк заманнар өчен күзләрегезне ачыгыз. Дусыгызны-дошманыгызны белегез, мөселманнарның асыл ватаннары — шәригать хөкеме берлән хөкем кылган җирдер. Үзләре кайда торсалар да, кайда булсалар да, калебләре, күңелләре шул шәригатьнең хаким булган мәмләкәтендә булырга тиеш. Дин өчен хәлифәнең әмере берлән җиһад һәр мөәмингә фарыз булган заманда сезләр, русларга итагать кылып, дин карендәшләрегезгә каршы сугышка ничек батырчылык кыласыз? Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә хозурында ни дип җавап бирерсез? Дөньяның очында үз хәлегезне уйлап карасагыз, бу бер йөз каралгыдыр. Йөзләрчә, меңнәрчә адәм кулында кылыч корал була торып, бер дә үз файдагызны фикер кылмаенча, гомерегезгә дошманнарыгыз ку-

лында ихтыярсыз хур-хәкыйрь булып, һәртөрле михнәт вә мәшәкатькә сабыр кылмак бөтенләй акылга хилафтыр. Бу хәлләрне уйлагыз, йортларыгызга кайткач, дин карендәшләрегезгә сөйләгез. Бу хурлыктан котылырга иҗтиһад кылыгыз, гафил булсагыз, һаман шул дошманнарыгыз кулында ихтыярсыз хәкыйрь булырсыз. Гафилләрнең хәле хараптыр.

Габдрәшит

II.

El Dschihad. Zeitung für die muhammedanischen Kriegsgefangenen. – Turkotatarische Ausgabe. – 1915. – Nr.9, 7. – Juli.

Б.1

ЯНӘ ӘСИР МӨСЕЛМАННАРГА БЕРНИЧӘ СҮЗ

Сугышка кергән адәмнәр һәр заманда бер максутка бинаән сугышалар: диннәрен саклар өчен, йортларын саклар өчен, намусларын, хәйсиятьләрен [дәрәҗәләрен] саклар өчен. Төрекләр сугышканда, һәр заман ислам динен сакламак өчен сугышалар, алманнар сугышканда, үзләренең җирләрен, йортларын дошман тәсәллытыннан [11] сакламак өчен сугышалар. Әмма руслар, англичаннар сугышканда, зәгыйфь булган халыкларның җирләрен тартып алмак өчен сугышалар, руслар, безнең Казан ханын юк кылып, җирләребезне тартып алдылар һәм, Әстерхан ханын юк кылып, җирләрен алып куйдылар. Сибирия-Тобольски ханлыгын юк кылдылар, казахларның ничә ханнарын, Кенесары [12] ханнарын, Җиһангир [13] ханнарын күзебезнең алдында юк кылдылар. Кокан, Сәмәрканд, Кашгар ханнарын һәммәсен руслар бетерде. Кырым вә Кавказ ханлыклары дәхи рус урынына кереп китте. Шулай аның азында җиде-сигез мөселман ханлыгын юк кылып, бу дошманнар миллионнарча мөселманнарны үзләренә әсир кылдылар. Без — бичара мөселманнарга үзләре теләгәнчә золым кылалар, үзләре теләгәнчә хөкем кылалар, хәтта моннан егерме биш ел мөкаддәм безнең Коръәнебездән ничә аятьләрне чыгарырга да башлаган иделәр, соңра халык арасында сүз күбәйгәч, хәзерге Коръәнне искесенчә калдырабыз, дип куйдылар. Хәтта Казанда Скарятин [14] дигән бер залим губернатор булганда, мәсҗед манараларына чиркәү кебек чаң тагарга да тырыштылар. Казан губернасында Мәңгәр, Әтнә [15] авылларының мәсҗеденә тагарга дип ничә чаңыл китергәннәр иде, халык риза булмагач, губернатор, солдатлар берлән барып, Бекиров кебек зур байларыбызны хәкарәт кылып, Скарятин кяфер аяк табанын үптереп, соңра итегенең үкчәсе берлән башларына типте. Бу эшләр буннан ничә ел гына әүвәл — 1885 елларда гына булды. Шикаять кылырга дип Петербурга барган Казан байларын Петербургтан тотып кайтардылар. Вә аннан соңра да ничә төрле золымнар кылдылар, ничә мәдрәсәләрне яптылар, ничә муллаларны дине өчен Себергә җибәрделәр.

Әй, бичара мөселманнар! Шул хәлләрне бер дә уйламаенча, шул дин дошманы кул астында әсир булып торганбыз аз кебек, дәхи шул дин дошманның әмре берлән мөселман карендәшләребезгә каршы сугышасыз. Мөселманнарның хәлифәсе булган Истамбул хәлифәсенә каршы сугышасыз, русларның, англичаннарның һәм французларның максутлары шул җир йөзендә берданбер генә калган ялгыз гына мөселман хәлифәсен бетермәктер. Германиянең максуды шул мөселман хәлифәсен аю кебек ашарга торган дошманнардан сакламактыр. Әй, мөселманнар! Сез моны, яхшы уйласагыз, үзегез дә беләсез. Бик аз гына мөселманчылыгы булган кеше бу хәлләрне уйларга кирәк. Мөселманнарның хәлифәләре беткәч, Истамбул шәһәре кулдан киткәч, ничүн [16] җир йөзендә яшәргә кирәк.

Инде бу сүзләрне укыгач, сезнең хәтерегезгә килер: «Нихәл итик соң?» — дип. Шул үзегезнең җаныгызга, ма-

лыгызга дошман булган руслар[дан] үзегезнең хан бабаларыгызның үчләрен алсагыз, бик яхшы булып китәр иде. Сугышта булгач, әҗәл җиткән булса, кяфергә итагать кылып үлгәнче, шулай дин юлындарак дин кайгысы берлән үлгән дәхи артыграк булыр иде. Ходай сакласын, кяфергә итагать кылып, хәлифә гаскәренә вә хәлифә берлән иттифак булга[н] Алмания патшалыгына каршы мылтык атучылар, Ходай сакласын, кяфергә ярдәм кылганнары өчен, сугыш вакытында кяфер булып үләләр, әмма без әйткәнчә үлсәләр, ихлас ниятләренә күрә шәһит булыр иде. Менә, карендәшләр, мөселманнар үз диннәренә үзләре хөрмәт кылмаган сәбәпле, төрле фетнәләргә, төрле бәлаләргә төшәләр. Үзләре һаман да үз хәлләрен, үз файдаларын уйламыйлар. Һаман да шул кан дошманнарының, җан дошманнарының, дин дошманнарының боерыгына итагать кылып, һаман үз диннәрен үзләре аяк астына таптыйлар.

Без сезне шушы хәлләрдән коткармак өчен иҗ[ти]һад кылабыз. Тәкрар әйтәбез, сез хәзер дә монда Германия патшалыгы кулында әсирләр вә һәм хөрмәтле кунаклар булып торасыз, сезгә хөрмәт кылалар, мөселман булганыгыз өчен. Урыс кулында әсирсез, үз йортыгызда үзегезнең ихтыярыгыз юк, динегездә ихтыярыгыз юк, шулай була торып, шул дошманыгызга кол булып, аларның әмере берлән динегезнең хараплыгы өчен сугышып, үз динегезне үзегез хурлыкка төшерәсез. Бу сүзләрне ничә мәртәбә тәкрар кылсак та аздыр, чөнки җөмлә мөселманнарның терәклеге өчен лазем булган сүзләрдер.

Әй, мөселманнар, әй, әсирләр! Сез бу сүзләрне һаман күңелләрегездән чыгармагыз, солых булганнан соң, йортларыгызга кайтсагыз да, һаман уйлагыз, карендәш ыругларыгызга сөйләгез. Шул әзали [азгын] дошманнарыгызның золым вә җәберләреннән хилас булырга [котылырга] иҗтиһад кылыгыз. Бу дошманнар сезнең динегезне харап итәрләр. Мин бу җиргә сезгә нәсыйхәт итергә

Б.2
хәлифә тарафыннан килдем вә мин бурая [монда] килеп сезгә нәсыйхәт итмәк өчен Германия дәүләте бик разый булды.

Габдерәшит

IV [17]

El Dschihad. Zeitung für die muhammedanischen Kriegsgefangenen. – Turkotatarische Ausgabe. – 1915. – Nr.11, 18. – August.

Б.1
ГӨНАҺЫНА КҮРӘ ҖӘЗАСЫ

Безнең картларда бер сүз бар: «Һәркем ни кылганын күрер», — диләр. Теләсә, бер ялгыз бәндә булсын, теләсә, җәмәгать булсын, һәркем ни кылган булса, шуның җәзасын күрергә тиеш. Бу һәм кануны илаһи, һәм кануны табигыйдер. Гөнаһ кылган кеше җәзасыз калмас.

Россия хөкүмәте вә рус халкы бүген кылган гөнаһларының җәзасын тарталар һәм тартырга тиеш иде. Ничә йөз елдан бирле симергән руслар, ничә еллардан бирле үз кул астында булган руслардан башка халыкка, хосусан мөселманнарга, татарларга ничә төрле хәкарәтләр, ничә төрле золымнар кылып, ахырында диннәренә каршы дәхи төрле хәкарәтләр кыла башлаганнар иде. Рус татарны күргәндә, әүвәл әйтә торган сүзе — «татарская лопатка», татар — көрәк бук көрәр [өчен] генә кирәк, дип әйтәләр иде. Ялгыз түрәләре генә түгел, күп вакытларда һәр рус татарларга каршы бу сүзне туры килгәндә әйтеп каладыр иде. Петербурда, Мәскәүдә һәр йортның капкасына язып куйганнар: «Татарларга бу йортка керергә ярамый», — дип. Бичара татарлар русларның хәкарәтенә сабыр итә-итә, шулкадәр өйрәнмешләр, ахырында бу сүзләрнең хәкарәт икәнен белми башлаганнар.

Бөтен Россиядә руслардан башка халыкларның һәммәсе мәзлум [изелгән], ничә төрле хәкарәтләргә мәгъруздыр [дучар]. Поляклар,

яһүдиләр, чирмешләр, чувашлар, хәтта малоруслар дәхи русларның золымнарыннан шикаять итерләр. Ләкин русларның бу халыкларга кылган золым вә җәберләре мөселманнарга кылганы кадәр түгелдер, шулай булса да, ул җәмәгатьләрнең һәммәсе русларның дошманлыкларын белеп, лазем булган каршылыкларны кылалар иде, ләкин бичара җәһел мөселманнар һәр хокуктан, һәртөрле праволардан мәхрүм булсалар да, русларга каршы бер сүз әйтергә дә хәлләре килмидер иде. Хәтта 1892 елда мәдрәсәләребездә кул берлән язган дини китаплар булмасын, Төркиядә басылган китаплар булмасын дип, кул берлән язылган китаплары табылганлыгы өчен, ничә мәдрәсәне яптылар, ничә мулланың указын алдылар. Соңра мөселманнарның үз араларына фетнәләр салып, ничә төрле дәсисә [хәйлә] вә шайтанлыклар берлән бәгъзе муллаларга медальләр биреп вә бәгъзеләренә дә награтлар [18] биреп, ничә төрле фетнәләр чыгардылар. Ахырында күп адәмнәр, сабыр кыла алмаенча, йортларын, җирләрен сатып, торган үскән җирләреннән аерылып 1894 елда ялгыз Самар губернасыннан җитмеш мең йорт Исламбул[г]а күчеп китте, Ырынбур, Казан губерналарыннан дәхи бик күп адәмнәр, диннәрен сакламак өчен, ислам йортына күчтеләр, хәзер дә һәммәсе хәлифә кул астында камил рәхәтлек берлән гомер кылып торалар. Бүгендә Исламбулның авылларында тора торган ике йөз меңгә якын Казан татары бар. «Һәммәсе гаскәр булса, дин өчен сугышка бара», ярдәм кылса, дине өчен ярдәм кыла, җаны рәхәт, күңеле тыныч, һәммәсе мөселманлык юлында һәр нәрсәсен фида кыларга хазир [19]. Рус кулыннан котылганлыклары өчен, Хак Тәгалә хәзрәтләренә шөкер кылалар.

Руслар хакыйкатән мөселманнарның каннарын эчәрләр, Уфа губернасында Ырынбур губернасында башкортларның җирләрен алып бетерделәр. Халык фәкыйрьлектән нихәл итәргә белми, иген игәргә җир юк, урман эчендә утырса да, ягарга утын юк. Мөселман җирләренә христианнарны утырттылар, моннан утыз-кырык ел мөкаддәм бер дә рус булмаган өязләргә дә бу заманда рус тутырып куйды, мөселманнарның җирләрен алып русларга бирде. Бичара мөселманнарның үз йортларында үзләренә рәхәтлек юк Төркестан тарафларында, Ташкент, Сәмәрканд якларында хәзер дә рус тутырып яталар, хәтта бик күп җирләрдә мөселманнарны авылларыннан көч берлән чыгарып, ихтыярсыз кылып җибәрәләр. Бичара мөселманнарның үз ханә вә йортларына үзләренең ихтыярлары юк, күчеп китәләр. Хәзер йортка рус кереп утыра, хәзер дә дәхи бу хәлләр бар. Шул дәрәҗәдә золым, һичкемгә шикаять кылырга да юл юк, шикаять кылган кешеләр үзләре җәзага грифтар [дучар] булалар, сөйләгән кешеләрне Себергә җибәрәләр.

Менә ничә заманнан бирле рустан башка халыкларга шул золымнарны кылып килгән руслар, бүген [М]әхмәдкә [20] кылган золымнарының җәзасын тарталар, бер яктан төрекләр берлән сугыша, бер яктан германнар берлән, хәзердә үзләренең йортларында үз халкы берлән сугыша башладылар. Мәскәүдә кырык биш мең кара хезмәтче халык рус хөкүмәтенә каршы сугыш кылалар. Шәһәр эчендә [сугыш] унбиш көн бер ай булды, һаман шул ук руслар бер-берен үтерәләр, Петербурда һәм Киевтә вә башка шәһәрләрдә сугышлар барадыр. Меңләп кешеләре үлә, границаларның һәммәсендә руслар мәгълүб булып [җиңелеп], бик күп шәһәрләрне германнар алып куйдылар. Бу сугышта рус аз булса ун миллион кешесен югалтадыр, ничә миллиард акчасы бетте, чыкмаган җаны гына калды. Ходай теләсә, җаны чыгарга да күп калмады. Менә ничек кылган гөнаһларының җәзасын тарта, Хак Тәгалә хәзрәтләре дин исламга ярдәм бирсә, Кафказия рус кулыннан азат булып

Б.2

китә, Польша Варшавага кадәр рус ку-

лыннан китә, Финляндия китә. Менә ничек кылган гөнаһларының җәзасын тарта. Ходай Тәгалә гадел патшадыр, русларның гамәленә күрә анлара [21] җәза биргән һәр куәтле зәгыйфьләргә золым кылган булса, җәзасын тартадыр. Без хәзер дә шушы хәлләрне күзебез берлән күрәбез, Хак Тәгалә хәзрәтләренең гадәләтенә шөкер кылып, гомум мөселманнарны залимнәрнең шәрләреннән [явызлыкларыннан] саклап, һәммә мөселманнарның азат булуына дога кылабыз.

Габдрәшит Ибраһим

Искәрмәләр һәм әдәбият

1. Оппенгейм меморандумы турында карагыз: TIM EPKENHANS (Hrsg.): «Geld darf keine Rolle spielen» I. Teil, Archivum Ottomanicum 18 (2000), S.247-250; TIM EPKENHANS (Hrsg): «Geld darf keine Rolle spielen». Edition: Max Freiherr von Oppenheims Memorandum «Die Revolutionierung der islamischen Gebiete unserer Feinde» (Oktober 1914) aus dem Politischen Archiv des Auswärtigen Amts in Bonn [II. Teil], Archvium Ottomanicum 19 (2001), S.121-163.
2. Макс фон Оппенгеймның Германия Чит ил эшләре министрлыгы өчен 1915 елның 20 апрелендә әзерләгән меморандумы 1915 елның 22 апрелендә министрлыкка язган хаты эчендә. Саклану урыны: Германия Чит ил эшләре министрлыгының Сәяси архивы [Politisches Archiv des Auswärtigen Amts, Berlin], R 21246, Bl. 31, 33.
3. Габдрәшит Ибраһимның икенче өндәмәсе листовка рәвешендә. Өндәмәнең кулъязмасы Германия Чит ил эшләре министрлыгының Сәяси архивында саклана һәм 2003 елда бу мәкаләнең авторы тарафыннан бастырылган. Карагыз: SEBASTIAN CWIKLINSKI: Ein an tatarische Kriegsgefangene gerichtetes Propagandaflugblatt aus dem Ersten Weltkrieg // Bertugan 4 (2003), S.20-25.
4. «Әл-Җиһад» газетасының татарча басмасы турында карагыз: ЛЯЛЯ ГАТАУЛЛИНА: «Да будет дарована великая победа мусульманской армии и ее союзникам!» (Газета «Эль-Джихад» как средство пропаганды среди татарских военнопленных в Германии во время Первой мировой войны) // Гасырлар авазы / Эхо веков, 2009. — №1. — С.37-45.
5. СЕБАСТЬЯН ЦВИКЛИНСКИ: Политические призывы Габдрашида Ибрагимова к военнопленным российским мусульманам в 1915 г. // ГВОЗДНИКОВА И.М.; ХИСАМИТДИНОВА Ф.Г.; ФАРХШАТОВ М.Н. (ред.): История в лицах и личность в истории. Материалы Вторых Международных Усмановских чтений, посвященных 90-летию со дня рождения видного историка-аграрника Башкортостана, профессора Хамзы Фатыховича Усманова. Уфа, 17 октября 2013 г. — Уфа, 2013. — С.251-264; Габдрәшит Ибраһимның беренче татарча мәкаләсе, бу мәкаләнең авторы тарафыннан төрекчәгә тәрҗемә ителеп, факсимиле буларак та бастырылды, карагыз: SEBASTIAN CWIKLINSKI: Abdürreşid İbrahim'in Birinci Dünya Savaşında Almanya ve İsveç'teki Faaliyetleri // MEHMET ALİ ARPACI (ред.): Türk-Japon ilişkilerinin dönüm noktasında Abdürreşit İbrahim. Uluslararası Abdürreşit İbrahim ve Türk-Japon ilişkileri bilgi şöleni 22-23 Mayıs 2012 Konya. Bildiriler. – Konya, 2012. – S.285-306.
6. Габдрәшит Ибраһимның хәдисләргә комментарийләре һәм Россия дәүләт органнарының реакциясе турында карагыз: SEBASTIAN CWIKLINSKI: Abdürreşid İbrahim (1857-1944). Eine Biografie, Berlin, 2012 [Dissertation, Mikrofilm] – S.148-182.
7. Габдрәшит Ибраһимның 1901 елда Россия империясе Халык мәгариф министрлыгына (Министерство народного просвещения) язган бер язмасы турында карагыз: М.Н.ФАРХШАТОВ: Самодержавие и традиционные школы башкир и татар в начале XX века (1900-1917 гг.). — Уфа: Издательство «Гилем», 2000. — С.134-141.
8. Карагыз: SCHEICH ABDURRESCHID IBRAHIM: Vom Sein und Werden der tatarischen Nation // Der Neue Orient Bd. 1 (1917). – S.10-12; SCHEICH ABD-ER-RESCHID IBRAHIM: Die Wiedergeburt der turko tatarischen Völker Rußlands // Der Neue Orient Bd. 1 (1917). – S.408-410; SCHEICH ABD ER RESCHID IBRAHIM: Mein Brief an den Papst // Der Neue Orient, Bd. 2 (1917/18). – S.54-55.
9. Патшасы.
10. Мәхмәд Рәшад — 1909-1918 елларда Госманлы империясенең 35 нче солтаны.
11. Берәүне үз биләвенә алып, аның өстеннән үзе теләгәнчә хөкем йөртүдән.
12. Кенесары Касыйм улы — 1841-1847 елларда казах Урта җөзенең (ханлыгының) ханы.
13. Җиһангир (1804-11.08.1845) — 1824-1845 еллардагы Бүкәй урдасы ханы турында булырга тиеш.
14. Скарятин Николай Яков углы (1821-1894) — 1866-1880 елларда Казан губернаторы.
15. Биредә сүз хәзерге Татарстан Республикасына кергән Олы Мәңгәр һәм Олы Әтнә авыллары турында бара.
16. Ни өчен.
17. Габдрәшит Ибраһимның өченче мәкаләсе госманлыча язылганга күрә, монда бастырылмаячак.
18. «Награда» сүзеннән.
19. Әзер.
20. Биредә дә сүз югарыда телгә алынган Мәхмәд Рәшад турында бара.
21. Аларга. ■

«СӨЕМБИКӘ» ЖУРНАЛЫНА 100 ЕЛ

«ХАНЫМ ВӘ ТУТАШЛАР ДИКЪКАТЕНӘ...»

ЧУЛПАН МӨСЛИХОВА,
«Казан» милли мәдәният үзәгенең «Казанның меңьеллыгы» музее хезмәткәре, Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты аспиранты

XIX-XX ЙӨЗЛӘР ЧИГЕНДӘ ИҖТИМАГЫЙ КҮТӘРЕЛЕШ, ДЕКМОКРАТИЯ МӨМКИНЛЕКЛӘРЕННӘН ФАЙДАЛАНУ, ЦЕНЗУРА ТАЛӘПЛӘРЕНЕҢ ЙОМШАРУЫ – БОЛАР БАРЫСЫ РОССИЯ ҖӘМГЫЯТЕНДӘ ХАТЫН-КЫЗЛАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫ, ЮГАРЫ БЕЛЕМ АЛУ ӨЧЕН АЛШАРТЛАР ҖЫЕЛМАСЫН ТӘШКИЛ ИТӘ [1].

صان ١٩١٤ سنه ١٥ نچی مای ١٣٣٢ سنه ٣ نچی رجب

سویم بیکه

١٣٣١

١٤-صان. بهاسی: ٢٠ تین.

Женскій журналъ „СЮЕМЪ-БИКА“ Годъ издания III. № 10.

Выходитъ два раза въ мѣсяцъ.

Условія подписки съ доставкой и пересылкой:

Таксa объявленія: впереди текста строка петита 50 к., позади текста 40 к. Постоянный заказъ по соглашенію.

Цѣна 20 к. АДРЕСЪ: Казань, Редакція журнала „СЮЕМЪ-БИКА“.

کاندیتر فابریقه‌سی

„آلفا“

قزانده.

سویم بیکه

ژورنالینه ١٩١٦ نچی یل اوچون مشتری قبول ایته‌در.

بهاسی:

Казань, Редакція журнала „Сюемъ-Бика“.

Редакторъ-Издатель Я. ХАЛИЛИ. Казань, Типо-литографія „УМИДЪ“ 1916.

«Сөембикә» журналының титул һәм соңгы битләре. 1914 ел, 14 нче сан

Татар вакытлы матбугаты ныгый барган саен, газета-журнал редакцияләренә хатын-кызлардан килгән хатлар саны да арта бара. Бу күренеш газета-журналларның күпчелегендә «Хатын-кыз галәме», «Хатын-кыз сәхифәсе», «Хатын-кыз дөньясы», «Хатын-кыз почмагы» кебек махсус бүлек-сәхифәләр ачуга китерә [2, 31 б.].

Татар җәмәгатьчелегенең хатын-кыз мәсьәләләренә игътибары арту нәтиҗәсе һәм хатын-кызларның иҗтимагый тормышта активлашуы [3, 42 б.] алар өчен махсус матбугат кирәклеген көн тәртибенә куя. Булачак яңа басманың концепциясен, программасын Якуб Хәлили эшли.

1913 елның 16 сентябрендә Казан губернаторы тарафыннан Я.Хәлилигә ике атнага бер тапкыр хатын-кызлар өчен рәсемле татарча журнал чыгарырга рөхсәт бирелә [4]. Губернатор раслаган программадан күренгәнчә, журналда «хатын-кызларның хокукый, сәяси, әхлакый һәм гаилә тормышларын» чагылдырган мәкаләләргә, шулай ук бала тәрбияләү, аш-су, кул эшләре, мода, матурлык һәм бизәнү серләрен яктырткан аерым бүлекләргә дә урын бирелергә тиеш була.

Ниһаять, 1913 елның 27 октябрендә төрки халыклар тарихында икенче, ә татар халкы өчен беренче булган, хатын-кызларга багышланган журналның тәүге саны дөнья күрә. Әсма һәм Якуб Хәлилиләр журналны үз хисапларына нәшер итә. А.Х.Мәхмүтова ассызыклавынча, «Гаспринскийлар кебек үк, ир белән хатын, кулга-кул тотынышып, эшкә керешкән. Монда да Заһидулла бай кызы Әсманың бирнәсе милләт өчен хезмәт иткән» [5, 43 б.].

Журналның бизәлеше үзенчәлекле. Тышлыкта символик ай фонында татар ханбикәсе Сөембикәнең сурәте төшерелгән. Әлеге сурәт һәм басманың исеме аның эчке тематикасына туры килеп тора. Сөембикә образы татар халкының азатлык символы буларак аңлашыла. Журнал да үз укучыларын (ә аның төп аудиториясе, нигездә, хатын-кызлар) азатлыкка, тәрәккыяткә, эмансипациягә өнди. Шулай ук тышлыкта шул санның иң үзенчәлекле, кызыклы һәм әһәмиятле мәкаләгә төшерелгән фото да бастырыла. Шуны да искәртергә кирәк: һәр журналда диярлек заманы өчен алдынгы булган гүзәл затларыбыз, яңа ачылган мәктәпләрдә укучы кызларның фотосурәтләре урын ала. Мәсәлән, Фатыймаи-Фәридә, Шәмсиҗиһан Кәримова, Зәйнәп Әкимбетова, Фәхрелбанат Сөләймания, Маһруй Мозаффария, Мөхлисә Буби һ.б. фотосурәтләрен күрергә мөмкин. Хатын-кызлар йөзләрен ачып, татар милли киемнәрендә, Европа костюмнарында фотосурәткә төшү шул заман өчен зур яңалык булып санала. Журналда милли киемнәр кигән төрле милләт хатын-кызларының фотосурәтләре аңлатмалар белән дә тәкъдим ителә. Медицина, кеше анатомиясе, бакчачылык серләре схема һәм рәсемнәр белән тәфсилләп аңлатыла. Журналда төсле рәсемнәр юк. Әмма анда бастырылган күпсанлы сурәтләр бүгенге көн өчен тарихи әһәмияткә ия.

Матбугат буенча Казан вакытлы комитеты материалларыннан күренгәнчә, «Сөембикә» ныклап аягына баскан 1916 елда журналның тиражы 1200-1300 данә булган [6, 32 б.]. Басманың үз укучыларын тиз таба алуы «Сөембикә» идарәсенең җавапларыннан да күренә. Шуларның берсендә, журнал таралып бетү сәбәпле, өстәмә сораучыларга тупланмаларны җибәрә алмаулары турында хәбәр ителә.

«Сөембикә»нең тематик диапазоны киң. Ул хатын-кыз галәменең барлык өлкәләрен дә яктыртуны максат итеп куя. Үзенең шигарен дә шул максатны күздә тотып билгели: «Сөембикә» — «хатын-кызларга махсус ике атнага бер чыга торган әдәби, хокукый, икътисади (экономик), әхлакый, гыйльми рәсемле журнал». 1913-1918 елгы

төпләнмәләрдән күренгәнчә, журналның һәр саны әлеге шигарьгә тугры булып кала. Шулай ук музыка, аш-су, кул эшләре, мода буенча һәр хатын-кызга тормышта кирәкле мәсьәләләргә дә туктала. Әмма бу темаларга караган мәкаләләр санаулы гына. Татар хатын-кызларының эмансипациясен тәэмин иткән нигезләрнең берсе — мәгърифәтле, белемле булуны яхшы аңлаган журнал идарәсе — милли мәгариф темасын яктыртуга зур көч сала. Журналның идарәсе: «Мөселман хатын-кызларының уку эшләрен тәртипле бер юлга кую мәсьәләсе шундый тизлектә хәл кылынырга тиешле мәсьәләдер», — дип язып чыга (1913, №7).

Җәдиди мәктәпләр ачылу турында мәгълүматлар, уку-укыту программалары, мөгаллимәләр хәле сан саен диярлек журналның беренче полосасын биләп тора. 1914 елның 12 нче санында дөнья күргән «Карья [авыл] кызларында уку» исемле мәкалә авторы Буа өязе Суыксу авылында кызлар өчен мәктәпнең булмавына йөрәге сызлануын күрсәтә. Шул ук елның 20 нче санында М.Уралбаева шәһәрләрдә дә мондый төр мәктәпләрнең азлыгын күрсәтеп уза: «Җәмәгать тарафыннан салынган вә халык акчасына тәрбия кыйлынган бер кызлар мәктәбе юк. Безгә бердәнбер кереп укыр урын булса — Аллаһ гомерләрен озын кыйлсын! — әлеге Маһруй Мозаффария ханым белән әлеге Ләбибә ханымнарның квартиралары, әлеге карт абыстайларыбызның пич аралары иде» (1914, №20). Ләкин шунысы куанычлы: 1915 елда журнал «Авылларда кызлар мәктәбе» дигән мәкаләсендә җәдитчә укытуның авылларга да үтеп керүен күрсәтә. Моның сәбәбен журнал кызлар арасында белем-мәгърифәткә омтылышның көчәюе һәм кыз балаларга белем бирә алырлык кадрларның хәзерләнүе белән аңлата: «Казаннан ерак түгел Субаш Аты авылындагы кызлар мәктәбендә яшь кенә Мәрзия туташ укыта. Ул үзе Казандагы Фатиха Аитова мәктәбендә укыган» (1915, №5); «кыз балалар өчен мәктәпләремез елдан-ел тәрәккый иттереп килә, шәһәремездән ерак булган авылларымызга да нур төшә башлаган» (1916, №3-4). 1916 елның 15-16 нчы саннарында Багъбостан кызлар мәктәбенең эшләү дәрәҗәсе турында тәфсилләп язылган. Шәһәрләрдә генә түгел, ә авылларда да әлеге төр мәктәпләрнең кирәклеге, әһәмияте ассызыклана.

Журнал идарәсе мәктәпләр булмау яисә кызларның мәктәпкә билгеле бер сәбәпләр аркасында бара алмаган очракта, үзлекләреннән мөстәкыйль уку өчен методик эшләнмәләр, дәреслекләр бик ярдәм итәр иде, дигән тәкъдим белән дә чыга. 1914 елның 14 нче санында «Татар кызы» имзасы астында басылган «Дикъкать итешле» мәкаләдә автор: «...үзеңнән үзең генә укып аңларлык китаплар тәртип кыйлынсалар, безнең хәлемез бераз өмидле, булмаса — бөтенләй өмидне кисәргә генә кала», — дип яза. Шул ук вакытта мөгаллим һәм мөгаллимәләр өчен махсус басма кирәклеген дә «Сөембикә» яклап чыга. Бу басма мөгаллим һәм мөгаллимәләрне берләштергән, аларның максат-бурычларын, эшчәнлекләрен, проблемаларын күрсәткән, чишәргә булышкан, тәҗрибә уртаклашу урыны булыр иде дигән фикерне белдерә. «Сөембикә» журналы үзе дә мөгаллимәләрнең тәҗрибә уртаклашу, аралашу мохитен тудыра ала.

Җәдиди һәм кадими уку методларын тикшерүгә идарә зур урын бирә. Мәсәлән, Мәрьям Якупова үзенең мәкаләсендә кадими абыстайларның кызларга тиешле белем бирмәүләре, ә бары тик төрле мәҗлесләрдә җыелышып, гайбәт сөйләүләрен, кызларга газета-журналларны укытмауларын, дөньяда барган тормыш белән таныштырмауларын искәртә. Җәдитче укытучыларның исә, авылларда гына түгел, хәтта шәһәрләрдә дә кысрыклануын, эшләреннән чыгаруларын ачып яза. «Сөембикә», үз чиратында, җәдиди кызлар мәктәпләрендә укы-

тылырга тиешле фәннәрнең атналык сәгатьләре билгеләнгән программаны да бастыра (1914, №6).

Мәктәпләр ачылу белән бергә педагогик кадрлар хәзерләү мәсьәләсе дә туа. Журнал үзенең беренче саннарыннан ук татар хатын-кызларының дөньяви белем алуга хокукларын яклап, дарелмөгаллимат ачу фикерен куәтләп чыга (1914, №1). Шул ук вакытта төрле төбәкләрдә ачылган мәктәпләр, курслар турында да мәгълүматлар биреп килә. Мәсәлән, 1914 елгы 12 нче санда Бохарада Бурнашевлар ачкан мәктәп турында, 14 нче санда Уральскидагы кызлар мәктәбе, шул ук елның 18 нче санында Троицкида Яушевлар тарафыннан мәктәп ачылырга тиешлеге турында мәгълүмат китерелә. 1916 елның 15-16 нче саннарында Багъбостан кызлар мәктәбе, аның эшләү дәрәҗәсе турында мәгълүматлар китерелә. Шулай ук Багъбостан ханым туплаган (1916, №20-21), Казанда Мәһруй Мозаффария (1917, №2) оештырган курслар турында мәгълүматлар тәкъдим ителә. Елдан-ел журнал битләрендә «Мөгаллимә кирәк кешеләргә!» дигән игъланнар ешрак күренә башлый. «Берничә ел тәҗрибә туплаган мөгаллимәләр «Сөембикә» редакциясенә килделәр. Әгәр мөгаллимә кирәк кешеләр булса, мәктәпкә яисә хосусый укыту өчен булсын, «Сөембикә» редакциясенә мөрәҗәгать итегез» (1914, №19). Журналның шушы ук санында бер мөгаллимәнең Бохара, Кавказ якларында мөгаллимәлек итү теләге җиткерелә: «Үткән сәнада [елда] авылда мөгаллимәлек иттем. 1913 елда Уфада җәйге ханымнар курсының 2 нче шөгъбәсендә укып, мөгаллимәлеккә алган шәһадәтнамәм [таныклыгым] бар» (1914, №19); «Учительницаларымыздан Фатыйма туташ Дәүләтгилдиева өч сыйныф русский класс тәмам иткән фәкыйрь кызларны дүртенче сыйныфта буш укытадыр. Әгәр дә 3 сыйныф тәмам иткән кызлар укуларны дәвам иттерүне, белемнәрне арттырасылары килсә, Фатыйма туташка мөрәҗәгать итсеннәр» (1914, №3).

«Сөембикә» журналы XX гасыр башы татар җәмәгатьчелегендә еш әйтелә торган «милләт аналары» тезмәсен еш файдалана. «Милләт аналары» нинди булырга тиеш? Аларның гаиләдә, җәмгыятьтәге урыннары нидән гыйбарәт? Журнал авторлары менә шулар турында фикер йөртә. Мәкаләләр авторлары хатын-кызны ана буларак кына күзалламыйлар, аңа барлык татар җәмгыятен тәрәккый итә алырлык куәт итеп карыйлар: «аның (хатын-кызның) барлыгыннан хәят нур алсын, киләчәк көнләр ялтырасын, милләт, ватан ул барлыктан файда күрә алсын» (1914, №3); «... без дә инсан һәм дә милләт анасы булуы игътибары илә һәркемнән артык инсан баласыбыз» (1914, №20).

«Милләт анасы» бала тәрбияләүнең бар нечкәлекләрен белергә тиеш. Шуңа да «Сөембикә» балага физик һәм рухи тәрбиянең асылын аңлатып килә. Димәк, журнал әниләр өчен кулланма вазифасын да үти.

Журнал идарәсе, хатын-кызларны эстетик яктан тәрбияләү, мәдәни зәвыгын үстерү бурычын күздә тотып, әдәби әсәрләргә дә зур урын бирә. Биредә хатын-кыз авторларның әдәби әсәрләре кыйммәтле хәзинә булып тора. Аларда хатын-кызларның уйкичерешләре нигезендә чынбарлыкның чагылышы җәелеп ята. «Милләт аналары» үзләрен борчыган сорауларны, проблемаларны шигъри юлларга да салып бирә. Бибиҗамал Терешкавия, Фәһимә Гайнуллина, Җиһан Әмирия кебек мөхтәрәм гүзәл затларыбызның исемнәрен мисалга китерергә мөмкин. Җиһан Әмириянең 1916 елда «Сөембикә» журналында дөнья күргән «Сатылган кыз» исемле шигырендә кызларны мәҗбүриләп, акчага сатып кияүгә бирү проблемасы күтәрелә:

Ник сызланмыйм?
Агам мине сатты картка!

«Сөембикә» журналында милли баш киемнәренә реклама. 1916 ел, 6 сан

Әсма Шәфигулла кызы Хәлилия, «Сөембикә» журналының мөхәррир-нашире Якуб Хәлили хатыны. XX гасыр башы

Әз акчага хәмидсез, ямьсез картка...
Туган илдән аерылып китте башым;
Кошлар очып җитмәс җиргә —
ерак якка...
Төрле җәбер-золым, михнәт,
җәфа берлә...
Аямыйча кәһәрлиләр мин —
баланы.
Чит илләрдә ялгыз башым
күрә хурлык...
Әй Ходаем, үзең коткар мин —
баланы?!

Журналның күп кенә саннарында дини тематика да яктыртылып килә. Бу өлкәдә Г.Гыйсмәти мәкаләләре аеруча кызыклы. Ул шәригать кануннарының хатын-кыз азатлыгына каршы килмәвен, аның хокукларын кысмавын дәлилләргә тырыша.

«Сөембикә» төрле шәһәрләрдә, төбәкләрдә, илләрдә барган хатын-кызлар хәрәкәте, аларның үз хокуклары өчен көрәшүен чагылдырган фактлар белән дә таныштырып бара. «Италиядә парламент кандидаткасы», «Франциядә хатыннарның сайлау хокукына малик булырга тырышулары» кебек язмалар моңа мисал булып тора. Ф.Сәйфи Көнбатыш Европада хатын-кыз мәсьәләсен хәл итү юллары турында яза. Аның «Гарби Европада хатыннар хәрәкәте һәм хатыннар мәсьәләсе» (1914, №8) язмасы татар хатын-кызларын да, алардан үрнәк алып, белем һәм тәрбия өчен, ирләр белән тигез сәяси хокукка ирешү өчен, көрәш юлына басарга чакыра.

Журналда игъланнар, рекламалар да бастырыла. Алар, нигездә, һәр санның тышлык битендә бирелә, һәр санның соңгы битендә исә «Идарәдән җаваплар» урнаштырылган. Биредә редакция исеменнән мәкалә авторларына рәхмәт сүзләре, теге яисә бу язма буенча фикерләр, язмаларның басылу-басылмавы турында мәгълүматлар китерелә.

Журналның популярлыгын, сыйфатын, һичшиксез, аның нашире, мөхәррире һәм мәкалә авторлары тәэмин итә. «Сөембикә» журналының беренче елларында барлык эшләрен Якуб Хәлили һәм аның хатыны Әсма Хәлили эшлиләр. Күп кенә мәкалә авторлары да үзләре була. 1914 елдан

журналның сәркатибе булып күренекле публицист Фәхрелбанат Сөләймания эшли башлый. «Сөембикә»нең 1914 елның 1 октябрендә дөнья күргән 23 нче санында түбәндәге игълан урын алган: «Фәхрелбанат ханым Сөләймания «Сөембикә» идарәсенә даими мөхәррирләремездән булып килде. «Сөембикә»нең соңгы номерлары аның карамагында чыгачактыр. Фәхрелбанат ханым һәркөнне 10нан 12гә кадәр «Сөембикә» идарәсендә, 4тән 6га кадәр үзенең хосусый фатирында кабул итәчәктер». Аның мәкаләләре, нигездә, гаиләдә һәм җәмгыятьтә татар хатын-кызларының урыны, иҗтимагый вазифалары, кыз балаларга белем-тәрбия бирү мәсьәләләренә багышлана.

Журналда ир-ат авторлардан Сәгыйть Сүнчәләй, Ризаэддин Фәхреддин, Шәһит Әхмәдиев, Вакыйф Җәләл, Каюм Кулаткы, Лотфи Гадел кебек шәхесләрнең мәкаләләре басылган. Хатын-кыз авторлардан Багъбостан Мөэминова, Маһруй Мозаффария, Мәхбүбҗамал Акчурина, Өммегөлсем Терешкавия, Бибиҗамал Терешкавия, Зәйнәп-Сәгыйдә, Мәрьям Якупова, Камилә Мозаффария һ.б. исемнәре даими күренә. Шуны әйтергә кирәк: журналның беренче саннарыннан ук хатын-кыз авторларның мәкаләләре билгеле сәбәпләр аркасында азрак була. Әмма айлар үтү белән, авторлар арасында хатын-кыз исемнәре ешрак күренә башлый. Журнал үз чиратында хатын-кызлар өчен фикер уртаклашу мәйданына әйләнә. «Сөембикә» редакциясе, үз шигаренә тугры калып, куйган максатына да ирешә. Хатын-кызларыбыз курыкмыйча үз фикерләрен, зарларын, проблемаларны чишү юлларын журнал битләрендә күрсәтә башлый.

Гомумән алганда, йөз ел элек милли матбугатыбыз тарихында беренче тапкыр татар телендә чыга башлаган «Сөембикә» журналы чын мәгънәсендә хатын-кызлар өчен әдәби, мәдәни һәм сәяси мәйданга әверелү өчен җирлек хәзерли. Ул бик күп каләм осталарына, аеруча хатын-кызларга иҗади мөмкинлекләр ача. Төрле илләрдә, шәһәрләрдә барган хатын-кыз хәрәкәтләре белән таныштырып, татар хатын-кыз галәмендә дә көрәш чаткыларын уята. «Сөембикә»не шул чорның «милләт аналары»н тәрбияләүдә дәреслек-ярдәмлек булып торды, дип әйтү һич тә ялгыш булмас. Ул гүзәл затларыбызның ярдәмчесе, киңәшчесе, мөгаллиме, һәм, гомумән, якын дустына әверелде.

Татар халкының тарихы кебек, журналның тарихы бай да, каршылыклы да була. 1917 еллардагы иҗтимагый-сәяси вазгыять җилләре «Сөембикә» журналына да килеп җитә. 1918 елның 8 гыйнварында журналның соңгы саны дөнья күрә. 1926 елның августыннан журнал «Азат хатын» исеме белән янә чыга башлый. Сугыш вакытында туктап торганнан соң, 1958 елда журнал кабат тогызыла. Бүген 1913-1918 елларда чыгып килгән «Сөембикә» журналының традицияләрен 1991 елның гыйнварыннан шул ук исемдә чыга торган журнал уңышлы гына дәвам итә.

Чыганаклар һәм әдәбият

1. Хасбулатова О.А., Гафизова Н.Б. Женское движение в России (вторая половина XIX — начало XX вв.). — Иваново, 2003. — С.58; Хабибуллина А. Татарская женщина и ее наследственные права в конце XVIII — начале XIX вв. // Эхо веков / Гасырлар авазы. — 2007. — №1.
2. Мәхмүтова А.Х. Вакыт инде: без дә торыйк… (Җәдитчелек һәм хатын-кызлар хәрәкәте формалашу): очерклар. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2012.
3. Шунда ук.
4. ТР МА. 420 нче фонд, 4 нче тасфирлама, 7404 нче эш.
5. Мәхмүтова А.Х. Вакыт инде: без дә торыйк… (Җәдитчелек һәм хатын-кызлар хәрәкәте формалашу): очерклар. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2012.
6. Мәхмүтова А.Х. Милләт аналары: тарихи-документаль һәм биографик җыентык / төз.-авт. А.Х.Мәхмүтова. — Казан: Җыен, 2012. — 560 б. ■

«ӘЙ, КЫЙММӘТЛЕ АНА!»

(«Сөембикә» журналында мәгърифәтче Фатыймаи-Фәридә турында мәкаләләр)

ФАТЫЙМАИ-ФӘРИДӘ (1889-1914) – ТАТАР ДӨНЬЯСЫНДА, АЕРУЧА XIX ГАСЫР АХЫРЫ – XX ЙӨЗ БАШЫ ТАТАР ЗЫЯЛЫЛАРЫ АРАСЫНДА МӘШҺҮР ШӘХЕС. УЛ ХАТЫН-КЫЗ АЗАТЛЫГЫ ӨЧЕН АКТИВ КӨРӘШЧЕ, ЮЛБАШЧЫ БУЛА. 1912 ЕЛДА ТОМСК ШӘҺӘРЕНДӘ ЧЫГА БАШЛАГАН «СИБИРИЯ», СОҢРАК, 1913 ЕЛДА, УФАДА БУ ГАЗЕТАНЫҢ ДӘВАМЧЫСЫ БУЛАРАК ИГЪЛАН ИТЕЛГӘН «ТОРМЫШ» ГАЗЕТАЛАРЫНДА ФАТЫЙМАИ-ФӘРИДӘ ХАТЫН-КЫЗЛАР ӨЧЕН МАХСУС СӘХИФӘ БУЛДЫРА.

«Сөембикә» журналның Фатыймаи-Фәридә сурәте төшерелгән титул бите. 1914 ел, 12 нче сан

Ул әлеге газеталарның дөньяга чыгуына зур көчен куя. Мәгърифәтченең хатын-кызлар проблемаларын яктыртып, аларны чишү юлларын күрсәткән күп кенә мәкаләләре билгеле. Барыннан да бигрәк Фатыймаи-Фәридә татар хатын-кызлары арасында мөгаллимә буларак танылган. Ул үзе яшәгән җирләрдә кызлар өчен мәктәпләр ачып, аларны җәдитчә укытырга тырыша. Кызганыч, хатын-кызларны караңгылыктан яктылыкка алып чыгу теләге белән янган ханым 25 яшендә каты авырудан вафат була. Фатыймаи-Фәридәнең вафатыннан соң да татар вакытлы матбугатында аның теләк-хыялларын, максатын, эшчәнлеген яктырткан, мәгърифәтче белән бәйле булган хатирәләр даими рәвештә басылып килгән. Сезнең игътибарыгызга «Сөембикә» журналының 1916 елгы 9 нчы санында басылган берничә мәкаләне тәкъдим итәбез [1].

МӨХТӘРӘМӘ ФАТЫЙМАИ-ФӘРИДӘ ХАНЫМ ХАКЫНДА САБЫЙЛЫК ХАТИРӘТЕМ

Кыйммәтле анабыз Фатыймаи-Фәридә ханымның вафатына февраль уналтысында ике ел тулу мөнәсәбәте илә аның илә кичерергә муаффәкъ булындыгым бер кыш ашнасында [танышлыгымда] — алдыгым тәэсиратны мәрхүмәне искә төшерү нияте илә язмакчы булам.

1903 нче сәнә иде. Мәскәүдә кызларга махсус тәртипле бер ысул җәдидә мәктәбе булырга түгел, мәктәп исемен алырлык бер ысул кадим мәктәбе дә юк иде. Бинаән галәйһи [шуңа күрә] (мәрхүм) атам үзе галим кеше булмаса да, аңлырак кешеләрнең үтенүе илә мине тәртипле бер мәктәптә укытырга тели иде. Шуның өчен Мәскәүдән шактый гына ерак булса да дахили [эчке] Русия мөселманлары арасында тәртипле вә низамлы укытуы илә таныла башлаган Буби мәдрәсәсенә [2] укырга илтмәкче булды һәм шул көз сентябрь ахырларында юлга чыктык. Казанга кадәр машина илә барып, аннан пароходка утырып, Бубига китәчәк идек. Ләкин Казанга барып җитүебез илә соңга калганлыгыбызны аңладык. Казаннан китәчәк соңгы пароход фәкать Чистайга кадәр генә барачак, имеш. Инде ни эшләргә? Әгәр кире кайтсак, табигый, икебез өчен дә бик күңелсез булачак. Бинаән галәйһи әтием мине соңгы пароход илә Чистайга илтеп, үзенең якын танышларыннан Мортаза әфәнде Ваһаповларда (Фатыймаи-Фәридә ханымның атасы) урынлаштырып, Чистайның ибтидаи [башлангыч] мәктәбендә укырга калдырып китте. 8-9 яшьлек бер баланың, беренче мәртәбә ана кочагыннан аерылып, чит бер шәһәрдә белмәгән халыклар арасында калуы, табигый, бала өчен бик авыр бер хәлдер.

Ләкин шулай булса да, Фатыймаи-Фәридә ханымның җылы-йомшак сүзләре, шәфкатьле мөгамәләсе миңа ул авырлыкларны сиздермәде. Беренче көннән үк ул миңа татлы сүзләре илә мәктәп вә балаларны сөйләп, укырга кызыктыра башлады. Һәм шулай мин ул кышны Чистайның яңа гына ачылып тәртипкә куелып өлгермәгән ысул җәдидә мәктәбендә укырга башладым. Мәктәптә укылмаган бәгъзе дәресләрне мәрхүмә мөхтәрәмә Фатыймаи-Фәридә ханымнан укый идем. Бер генә кыш булса да сабыйлык хәятемнең иң мәсгуд [бәхетле] көннәрен Фатыймаи-Фәридә ханым янында кичерүгә муаффәкъ булдым. Мәрхүмә гыйлемгә мәфтүн [гашыйк] гайрәтле бер кыз булдыгыннан, кызларга махсус мөкәммәл [тулы] гыйлем йортлары булмадыгы заманда үзенең тырышлыгы нәтиҗәсендә бик күп нәрсә өйрәнергә муаффәкъ булган [ирешә алган] иде. Фатыймаи-Фәридә ханымның йөрәгендә яшьтән үк үз халкына булган самими мәхәббәте, тута вә сеңелләренә кулыннан килгән кадәр ярдәм итү фикере бик нык урынлашканга, миңа да аннан бик күп истифадә итәргә [файдаланырга] туры килде. Ул һәрвакыт минем фикеремне ачарга, миңа укуны сөйдерергә тырыша иде. Ул вакыт ысул җәдидә мәктәпләрендә дә тарих, җәгъръафия [география] фәне укытылмаганлыктан, мөхтәрәмә Фатыйма ханым мине үзенең теләве илә төрекчә бер әсәрдән җәгъръафия, тарих дәресе укытты.

Фатыймаи-Фәридә ханымның иң яратып укыган әсәрләре төрекчә әсәрләр иде. Ул төрекчә әсәрләрне шулкадәр яратып, чын күңеленнән бирелеп укый иде ки, аш һәм чәй янында аны сөекле китапларыннан аеру авыр була иде. Хосусән [аеруча], ул рамазан аенда бөтен кешене яткырып, үзе сөекле китаплары илә сәхәрне каршылый иде. Әлхасыйль [җыйнап әйткәндә], Фатыймаи-Фәридә ханымның иң мәхәббәт куйган ноктасы уку иде. Ул, бай булса да, башка кызлар кеби кием вә модага, алтын-көмешкә һич исе китми, мөхтәрәм атасы сәүдә эшләре

илә чит шәһәргә йөрүче кеше булса да, Фатыймаи-Фәридә ханым үзе өчен һичбер вакыт зиннәт-фәлән китерүне теләми, бәлки: «Миңа шул китапларны ал,» — дип атасына төрле заказлар бирә иде.

Ул вакыт татар хатын-кызлары өйдә китапханә булындыруның биля ни идекен белмәдекләре хәлдә, Фатыймаи-Фәридә ханым бик мөкәммәл бер китапханәгә малик [ия] иде. Фатыймаи-Фәридә ханымның китапханәсендә төрекчә, русча, гарәпчә бик күп әсәрләр бар иде. Ул Истанбулдан журнал, газета ала иде. Фатыймаи-Фәридә ханым илә кышны бик күңелле генә уздырып торган бер заманда, күп кешеләрне мәгънәви аналарыннан аера торган май ае да килеп җитте. Миңа да Фатыймаи-Фәридә ханымнан аерылырга туры килде. Ул мине актык минутка кадәр үз сеңеле кеби мәгънәви тәрбиясендә булындырды. Мине пароходка озаткан чагында, шул сүзләрне сөйләде: «Һәмширәм [кыз туганым]! Сиңа бу уку илә генә калырга ярамыйдыр. Моннан соң тәхсилеңне [укуыңны] монтазам [тәртипле] сурәттә дәвам иттерергә тырыш. Сәгадәт — гыйлемдә генәдер. Хосусән [бигрәк тә] татар дөньясының якты көнгә чыгуы, бәхетле хәяткә ия булулары хатын-кызларын тәрбия итүгә баглыдыр. **Бер милләтнең тәрәккыйсе тәрбияле гаиләләр аркылы гына буладыр.** Гаилә эчендә иң зур эш коручы хатындыр. Менә без шул вазифаны үтәргә хәзерләнергә тиеш. Тәгътыйль [каникул] чагында да укырга тырыш, мин сиңа һәрвакыт хат язармын», — диеп мине озатты. Табигый, мин дә күз яшьләремне агыза-агыза, кыш буе бергә торып, күп ярдәмнәрен күргән кыйммәтле анамнан аерылдым.

Җәйне Мәскәүдә, икенче көзне исә иртәрәк юлга чыгып, Буби мәдрәсәсенә таба юнәлдем. Бубида вакытта да Фәридә ханымнан хатлар алып, укып кайтышлый һәр ел Чистайга кереп күрешеп чыга идем. 1906 нчы сәнәдә Фатыймаи-Фәридә ханымнан алдыгым бер мәктүптә: атасы Бөгелмә өязе Кәрәкәшле карьясендә [авылында] [3] җир алып, эш ачканлыгын, вә җәй көне булу мөнәсәбәте илә, Фатыймаи-Фәридә ханым да шунда барып истирахәт кыйлачагын [ял итәчәген] бәян кыйлган иде.

Фатыймаи-Фәридә ханым гомумә табигатьне бик ярата вә аның күренешләре илә рухлана иде. Кәрәкәшлегә барып тора башлагач та язган бер мәктүбендә: «Күккә җитәргә якын ямь-яшел таулары, башкорт сахрасы дип ләтафәте [гүзәллеге] илә мәшһүр кырлары, очсыз-кырыйсыз урманнары, тау-ташларыннан ап-ак күбекләрне сачеп аккан шәляләле [шарлавыклы] ермаклары, хисапсыз җиләк-җимешләре, берсеннән-берсе ләтыйф [матур], берсеннән-берсе гүзәл чәчәкләре һич вә җәһәлә тәгъриф [аңлату] мөмкин булачак түгелдер. Шулкадәр гүзәл манзаралар арасында башына ак киез эшләпә киеп, зәңгәргә кызыл, сарыга яшел кушып теккән күлмәк кигән башкорт кызларының йөгерә-йөгерә җиләк җыюлары — тугрысы бик кыйммәтдар бер картина манзарасы тәшкил итәдер...» — дип язулары Фатыйма ханымның табигатьне ни дәрәҗә яратканлыгын белдерсә кирәк. Ул елларда татар кызларына махсус чын тәрбия бирердәй мәктәпләрнең юклыгы, татар хатын-кызларының һәркем тарафыннан изелеп, үз хокукларын үзләре химая кыла алмаулары, Фатыймаи-Фәридә ханымны чыннан ачындыра вә ничек кенә булса да, аларны шул әсарәтләреннән [әсирлекләреннән] коптарып, якты дөньяга чыгарырга тырыша иде. Шул ният илә Фатыймаи-Фәридә ханым Кәрәкәшлегә җәй көне истирахәт өчен генә диеп барган булса да, андагы башкорт кызларының гыйлем-мәгърифәттән тәмам хәбәрсез булулары вә шул көнгә кадәр тәртипле бер мәктәп күрмәүләре Фатыймаи-Фәридә ханымны шунда калырга мәҗбүр итә. Ул үзенең туып-үскән җирен (Чистай

шәһәрен), русча укуын, вакытлы гына калдырып булса да, гыйлемгә сусаган туташ вә сеңелләренә үз мәсърафы [акчасы] илә беренче мәктәп ачып, аларны заманга муафикъ [туры килгән] рәвештә тәрбия итәргә башлый. Бөтен көчен сарыф кыйлып, аларның фикерләрен ачарга тырыша. Берничә истигъдадлыракларын [сәләтлерәкләрен] аерым хәзерләп, мөгаллимә булыр өчен Буби мәдрәсәсенә җибәртә.

Хәзерге көндә мөхтәрәмә Фатыймаи-Фәридә ханымның исемен мәңгегә калдыру өчен салына башлаган «Мәдрәсәи Фатыймия»да Фатыймаи-Фәридә ханымнан тәрбия алып, соңра Буби мәдрәсәсен тәмам иткән Зәйтүнә ханым [4] мөгалимәлек итә. Ике йөзгә якын кыз укыйдыр.

Мөхтәрәмә Фатыймаи-Фәридә ханымның матбугатка чыгып, моннан соңгы милләтенә булган җитди хезмәтләре татар дөньясына вә бигрәк тә хатын-кыз галәменә бик ачык мәгълүм булганлыктан, бу турыда артык язмыйча, үземнең сабыйлык хатирәтемне шуның илә тәмам итәм.

Әй, кыйммәтле анабыз Фатыймаи-Фәридә ханым! Бу көн синең гали рухыңның тынычлыгы өчен бөтен татар дөньясы нечкә күңелләреннән сиңа догалар кыйлалар, мәктәпләрдә синең тәрҗемәи хәлләреңне сөйләп, мәгъсум [гөнаһсыз] балалар да гөнаһсыз күңелләреннән чыккан пакь догаларын гарешләргә [күкләргә] җибәрәләр.

Шат бул, әй кыйммәтле ана! Аллаһ синең гали рухыңны гали җәннәттә кыйлсын!

Хәдичә Дунаева. *Мәскәү. Сөембикә. — 1916 — №9. — Б.166-169.*

ФАТЫЙМАИ-ФӘРИДӘ ХАНЫМГА ИКЕ ЕЛ

Милләтебезнең анасы, хатын-кызларыбызның юлбашчысы булган Фатыймаи-Фәридә ханымның вафат булуына шушы 1916 ел, 16 февральдә ике ел була, мәрхүмәнең милләтебезгә кыйлган хезмәтләрен, хатын-кызларга кыйлган яхшылыкларын уйлап, күзгә яшьләр тула. Әмма ни чара? 1908 елда сентябрь числосында салкын Сибириягә, Томски каласына иң әүвәл мәртәбә бардыкларында, Омскида туктап кунак булдылар. Безләр ул вакытта Омскида идек.

Ул вакытта Фатыймаи-Фәридә ханымның, яңа гына аткан чәчәк кеби, сөекле әнкәләренең куеныннан яңа гына чыгып килгән вакыты иде. Яшь, матур, күңелле, кәефе яхшы, рухы шат, һәрнәрсәгә бер төрле дикъкать илә карап, күңелле вә куанычлы сүзләр сөйләп, җанны рәхәтләндермәктә иде. Шул күрешүдә Фатыймаи-Фәридә ханым илә күп сүзләр сөйләштек. Бәхетсез милләтнең, һәммә хатын-кызларыбызның һәрбер тәрбиядән мәхрүм калулары тугрысында кайгырыштык. Һәрничек булса да аларга ярдәм итешергә сүз бирештек. Шул вакытта мәрхүмә Фатыймаи-Фәридә ханымнан бу кадәр ерак сәфәргә баруының сәбәбен сорадым. Чит җирдә, чит кешеләр арасында торуның авыр икәнлеген дә бераз сөйләдем.

Моңа каршы, әлбәттә: «Бу сүзләрегез дөрес. Мин үзем бүгенгә кадәр горбәтчелекне [туган илдән аерылуны] күрмәсәм дә, аның авыр икәнен беләм. Әмма шулай булса да, үземнең мәңгелек юлдашым булган Вагыйзь әфәнде [5] илә бергә үзебезнең зәгыйфь вә аянычлы милләтебезгә хезмәт итүне үзебезнең беренче бурычыбыз дип беләбез. Шул сәбәпле, бу хезмәтне җан-тән илә кабул итеп, милләткә хезмәт итәчәкбез», — диде.

Үз Ватаныгызда да хезмәт итәргә мөмкиндер бит дидекемдә, алай да мөмкин, ди, шулай булса да, анда бездән башка да хезмәт итүчеләр күп. Менә бу якта караңгы вә салкын Себергә төрле сәбәпләр илә килеп таралган вә адашкан һәмширәләребез бик күптер. Алар һәркайсылары гыйлемгә

сусаганнар вә йөдәгәннәр. Аларның арасына килеп хезмәт итүчеләрнең саннары бик аз, турысын әйткәндә, юк хөкемендәдер, диде.

Без шуларны игътибарга алып, милләткә хезмәт итү нияте илә бу сәфәргә чыктык. Җәнабе хак сәламәтлек бирсә, мөмкин кадәре тырышып хезмәт итәчәкбез. Әгәр дә сәламәт булсак, берничә елдан соң кайтып, үз ватандашларыбызга да кулыбыздан килгән кадәр ярдәмләшербез. Минем өчен дөньяда иң татлы вә иң кыйммәтле нәрсә булса — ул да шушы һәмширәләремә мөмкин кадәре ярдәм итү, аларны токтыннан коткарып, якты дөньяга чыгарудыр. Шушы тәмле вә ләззәтле сүзләрне сөйләшеп, киләчәктә янә күрешүне теләп аерылыштык. Һәм мәңгегә аерылыштык. Томскида вакытларында мәктүп язышып торсак та, тагын бер кәррә [тапкыр] күрешүгә насыйп булмады.

Мәрхүмә сәламәт вакытында безләр өчен күп кайгырды, язды, сөйләде, безләрне һәрдаим яктылыкка өндәде. «Сибирия» вә «Тормыш» газеталарында «Хатын-кыз дөньясы»н ачты, аның аркасында чит җирләрдә, ерак шәһәрләрдә адашып калган, әллә ниндәен ... [6] кешеләрнең кулында җәберләнгән тута вә сеңелләребезнең аһ вә зарларын ишетәдер идек, мөмкин булганда, ярдәм итүчеләр дә табыладыр иде. Болар һәммәсе дә мәрхүмә Фатыймаи-Фәридә ханымның ижтиһады илә мәйданга килгән иде.

Ходайга мең кәррә шөкерләр булсын, мәрхүмә Фатыймаи-Фәридә ханымның яндырган шәме көннән көнгә яктырды, нурланды. Караңгы вә салкын Сибириягә гыйлем нуры сачелде, һичнәрсәдән хәбәрләре булмый йоклап яткан хатын-кызларның йөзенә гыйлем нуры төште, күзләре ачылды, уку-укыту эшләренә әһәмият бирә башладылар.

Болар, әлбәттә, безнең өчен беренче шатлык һәм куанычтыр. «Тормыш» газетасында хатын-кыз дөньясының югалуына җаныбыз әрнесә дә, ханымнарга махсус «Сөембикә» журналы барлыгы безләрне шатландыра, җаныбызны рәхәтләндерә.

Мөхтәрәм әфәнделәр! Һәм дә мөхтәрәмә ханымнар! Милләт юлында корбан булган мәрхүмә Фатыймаи-Фәридә ханымның исемен мәңгегә калдыру нияте илә Кәрәкәшле авылында мәктәп сала башлаганлыклары һәркайсыбызга мәгълүм. Төрле җирләрдән иганәләр дә килгәләп торадыр. Әмма моның илә генә бу зур бинаны тәмам итүгә имкян [мөмкинлек] юк.

Сез хөрмәтлеләрдән үтенәмен: шушы изге эшнең тиз көндә вөҗүдкә чыгуына [барлыкка килүенә] ижтиһад итүегезне. Тамчы тамып, күл була, дигән кеби, һәркайсыларыгызның мөмкин кадәр ярдәм итүегезне теләп, сүземне кистем.

Кәримә Ишмөхәмматова.
Петропавел. 1916 сәнә 6 нчы февраль.
Сөембикә. — 1916. — №9. — Б.169-170.

Искәрмәләр

1. Фатыймаи-Фәридә ханымның тормыш юлы, журналистлык һәм мөгаллимлек эшчәнлеге турында галимә Альта Мәхмүтова китапларыннан таныша аласыз: Махмутова А.Х. Пора и нам зажечь зарю свободы! (Джадидизм и женское движение). — Казань: Татар.кн.изд-во, 2006. — С.124-142; Мәхмүтова А.Х. Вакыт инде, без дә торыйк... (Җәдидчелек һәм хатын-кызлар хәрәкәте формалашу): очерклар. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2012. — Б.293-322; Милләт аналары: тарихи-документаль һәм биографик җыентык / төз.-авт. А.Х.Мәхмүтова. — Казан: Җыен, 2012. — Б.437-485.
2. «Буби» мәдрәсәсе — Вятка губернасы Иж-Буби авылындагы (хәзерге Татарстан Республикасы Әгерҗе районы) җәдиди мәдрәсә.
3. Кәрәкәшле авылы — Татарстан Республикасы Ютазы районындагы авыл.
4. Зәйтүнә Юльметова.
5. Мөхәммәтвагыйз Нәүрозов — Фатыймаи-Фәриданең ире, «Сибирия» һәм «Тормыш» газеталарының баш мөхәррире.
6. Чыганакта да күпнокталар белән бирелгән. Биредә кабахәт кебек сүгү сүзе булып, аны «Сөембикә» мөхәррирләре махсус төшереп калдырганнардыр.

Текстларны басмага
***Чулпан Мөслихова** әзерләде.*

КЫРЫМ ҺӘМ ИДЕЛ-УРАЛ ТАТАРЛАРЫ АРАСЫНДАГЫ БАГЛАНЫШЛАР*

ФИЛҮСӘ АРСЛАН,
Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе

ХХ ГАСЫР БАШЫНДА СЕВАСТОПОЛЬ ШӘҺӘРЕНЕҢ ҖАМИГЪ МӘЧЕТЕ ИМАМ-ХАТЫЙБЫ БУЛЫП ХЕЗМӘТ ИТКӘН ЙОСЫФ ИСМӘГЫЙЛЬ УЛЫ РӘХИМОВНЫҢ БАЛАЛАРЫ СӘНГАТЬ, МӘГЪРИФӘТ ЮЛЫН САЙЛАГАН. БУ ГАИЛӘДӘ ИКЕ МУЗЫКАНТ – ҖЫРЧЫ ШӘФЫЙКӘ, КОМПОЗИТОР КАМИЛ ҺӘМ МӘГАРИФ ХЕЗМӘТКӘРЕ НУРИЯ ТӘРБИЯЛӘНӘ.

Йосыф Рәхимовның өлкән улы **Камил Рәхимов** – башкорт профессиональ музыкасына нигез салучыларның берсе, композитор, фольклорчы, БАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе. Ул 1900 елның 25 августында Севастополь шәһәрендә туа. 1919-1921 елларда Кызыл Армия сафларында хезмәт иткәндә, хәрби оркестрның музыканты була. Кырым педагогика институтының рабфагын тәмамлаганнан соң, Ленинград каласына Калинин исемендәге политехник институтка укырга китә, әмма музыкага тартылу аны Казан музыка техникумына алып килә, бер елдан Камил Уфа сәнгать техникумына күчә. Уфа радиокомитетында музыка редакциясендә эшли. Журналның алдагы санында язуыбызча, 1938 елда әтисе Йосыф хәзрәт атарга хөкем ителә һәм шул ук елда Камил Йосыф улы да донос нәтиҗәсендә эшеннән алына, сөргенгә сөрелә. 1947 елдан ун ел дәвамында Башкортстан Мәдәният министрлыгының фольклор бүлегендә эшли. Ул мәктәпләр өчен музыка һәм җыр буенча дәреслекләр яза, башкорт, татар, рус, чуваш һәм башка халыкларның 400гә якын милли җырларын нотага сала. СССР Фәннәр Академиясенең Башкортстан филиалы белән тыгыз фәнни хезмәттәшлек алып бара.

Башкортстанның һәм Татарстанның тенор тавышлы җырчылары «Сандугач»ны аның эшкәртүендә җырлыйлар. Бу җыр беренче мәртәбә 1955 елда Мәскәүдә үткән Башкортстан әдәбияты һәм сәнгате көннәрендә Мәгафур Хисмәтуллин башкаруында яңгыраган. «Ашказар», «Перовский» (оркестр өчен), «Салават», «Биеш» (хор һәм оркестр өчен), «Сандугач», «Зөлхиҗҗә» кебек күпсанлы эшкәртмәләрдә К.Рәхимовның халык мелодикасы үзенчәлекләрен белүе ачык чагылды. Якуп Колмай сүзләренә «Туган илем», Зыя

* Ахыры. Башы журналның 11 нче санында



Башкортстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, композитор, фольклорчы Камил Рәхимов. Уфа. 1960 еллар

Шәфыйка Йосыф кызы Котдусова. Казан. 1950 еллар

Колбәков сүзләренә «Башкортстан» җырлары гына да гимн булырлык әсәрләр. К.Рәхимов башкорт музыка мәдәниятенең аякка басуына һәм үсешенә зур өлеш кертте. Бу уңайдан Заһир Исмәгыйлевнең сүзләре искә төшә: «Камил Йосыф улын композиторлар һәм музыка белгечләре, язучылар, башкаручылар — аны белгән һәркем ихтирам итте. Ул репрессия елларында чиктән тыш авырлыклар кичерде һәм бөтен кешегә изгелек теләүче булып калды. Халык җырларын өйрәнү һәм язып алуда фольклорчылар белән үзенең тәҗрибәсен юмарт уртаклашты, аларга нык ярдәм итте. Севастопольдә туган бу татар кешесе башкорт халык җырларын чиктән тыш тирәнтен белә иде... Ул намуслы музыкант, сирәк булганча игелекле, зур йөрәкле, гаҗәеп кеше иде».

Уфа каласында Камил Рәхимов яшәгән фатирда (бу йортка аның исемен мәңгеләштергән такта куелган) гомер сөрүче улы Эмиль Рәхимов әтисенең якты иҗаты һәм тормышы турында китап чыгарырга җыена. Бирсен Ходай, ул аңа лаек...

Татарстанның тәүге опера җырчыларының берсе, республикабызның атказанган артисты **Шәфыйка Йосыф кызы Котдусова** — бу нәселнең тагын бер моңлы баласы. Ул 1910 елның 18 мартында Севастополь шәһәрендә Йосыф хәзрәт Рәхимовның дүртенче баласы булып дөньяга килә. Йосыф Исмәгыйль улы фикердәш дусты Исмәгыйль Гаспралының кызы Шәфыйка (Шефика) хөрмәтенә үз кызына да шул исемне куша. Гаспралы һәм Рәхимовлар гаиләсе дустанә мөгамәләдә була. Шундый затлы, гыйлемле даирәдә көләч йөзле, терекөмештәй җитез булып үсә кечкенә Шәфыйка. Биш яшендә инде ул гарәби язуда укырга-язарга өйрәнә, шуның өстенә француз телендә дә аралаша.

Табигатьтән бирелгән искиткеч җырлау сәләтенә һәм музыка училищесына имтиханнарны уңышлы тапшыруына карамастан, аны, мулла кызы булу сәбәпле, укырга алырга ашкынып тормыйлар. Шулай да ул училищены ике белгечлек — пианист һәм җырчы буларак тәмамлауга ирешә. Шәфыйкә унҗиде яшендә кырым татары, мулла улы Абдураим исемле юристка кияүгә чыга.

Сеңлесе Нурия (10 яшь), әниләре Фатыйма абыстай, Ш.Котдусова (18 яшь). 1928 ел

1941 елда ул Казанга чакырып китерелә. Бу елны Мәскәүдә Татар әдәбияты һәм сәнгате көннәре үтәргә тиеш була, әмма, сугыш башлану сәбәпле, оештырылмый кала. Шәфыйканың Татар опера һәм балет театры солисты буларак, Н.Җиһановның «Алтынчәч» операсыннан Алтынчәч партиясен башкаруы либретто авторы Муса Җәлилне дә таң калдыра. Аннан соң җырчы башкаруында Рәйханә («Качкын»), Галиябану («Галиябану»), Су-Сылу («Түләк»), Фәридә («Фәридә»), Карлыгач («Намус»), Сәрвәр («Башмагым»), Шәмсия («Акчарлаклар»), Гөлйөзем («Наёмщик»), Фәйрүзә («Идел буенда»), Микаэла («Кармен»), Розина («Севильский цирюльник»), Джильда («Риголетто») кебек төп рольләр бер-бер артлы тезелеп китә.

Шәфыйканың ире Абдураим мулла улы булганы, өстәвенә мулла кызына да өйләнгәне өчен, төрле эзәрлекләүләргә дучар ителә, әмма ул үзе теләп фронтка китә һәм 1942 елда Мәскәү янында һәлак була. Шәфыйка Котдусова, сугыш башланып, бер ай узгач, балаларын әбиләре белән үзе янына алып килә. Гаиләне Казан бик коры, хәтта үтә салкын кабул итсә дә, икенче яктан, алар бәхетле — Кырымда яшәүче татарлар дучар булган коточкыч геноцидтан сакланып калалар.

Шәфыйка Котдусованың Казан сәхнәсендә иҗат иткән ун елы аеруча югары бәягә лаек. Сәхнәләрне балкытып эшләп йөргәндә, аны «һөнәри яктан сәләтсез» дигән сылтау белән эштән азат итәләр. Ул Мәскәүгә китә һәм Иван Козловский, Зара Долуханова, Сергей Лемешев, Рәшит Бәйбутов кебек данлыклы җырчылар белән концертларда чыгыш ясый һәм уңыш казана. Хаксызга рәнҗетүләр сәламәтлеген нык какшата (артистлар арасында Ш.Котдусованың талантына көнләшеп карауччылар да табыла) һәм ул 46 яшендә бакый дөньяга күчә. Соңгы юлга аны меңләгән Казан халкы озата…

Шәфыйка Котдусованың сеңлесе, Йосыф хәзрәтнең кече кызы **Нурия Рәхимова** 1918 елның 18 июлендә Севастополь шәһәрендә Йосыф хәзрәт белән Фатыйма абыстайның уникенче баласы булып дөньяга килә. 1941 елда Кырым педагогика институтының рус теле һәм әдәбияты факультетын тәмамлап, Кырым мәктәпләрендә укыта, завуч вазифаларын башкара. Сугыш вакытында немецларга әсирлеккә эләгә, сак астында мал вагоннарына төялгән халык белән Германиягә оза-

Шәфыйка Котдусова Н.Җиһановның «Алтынчәч» операсында Алтынчәч партиясен башкара. Казан. 1940 еллар

тыла һәм Ратенов шәһәренең оптика заводы янындагы концлагерьга ябыла. Газаплы, михнәтле ике ел гомер бу заводта коллыкта үтә. 1945 елның февраль аенда дусты белән алар концлагерьдан кача. Нурия ханым, төрле авырлыклар үтеп, 1946 елның октябрь аенда гына Казанга — әнисе Фатыйма абыстай, апасы Шәфыйка һәм аның ике улы Җәвид белән Эрнст янына кайта.

Аңа «халык дошманы кызы» һәм «әсир булган» дигән кара тамга. Туган илендә дә тыныч яшәү насыйп булмый: биш ел дәвамында Нурияне Черек күл буена, КГБ бинасына, һәркөнне диярлек чакырталар. Аның күп телләр, шул исәптән немец телен белүе шик-шөбһә уята. Әмма ул бөтен җәберләүләргә түзә һәм, төрле мәктәпләрдә эшләп, үзен яхшы укытучы итеп таныта.

1952 елда Нурияне Казан шәһәре мәгариф бүлеге педкабинетының методисты итеп эшкә алалар. Ул намуслы хезмәте өчен «Татарстанның атказанган укытучысы» дигән мактаулы исемгә лаек була. Татарстан мәгърифәтен үстерүгә зур өлеш керткән игелекле, шәфкатьле, нурлы йөрәкле ханым Нурия Йосыф кызы Рәхимова Казан каласында 2004 елның апрель аенда, 86 яшен тутырып, вафат була.

Йосыф Рәхимов кызы Нурия, оныгы Ирек (Эрнст) Котдусов белән. Севастополь. 1936 ел

Севастополь мәчете имам-хатыйбы Йосыф хәзрәтнең балалары Камил, Шәфыйка, Нурия Рәхимовлар аяусыз язмыш сынауларын җиңгәннәр, киләчәккә өмет белән караганнар, үзләренең иҗатлары һәм хезмәтләре белән халыкка шатлык өләшкәннәр, гыйлем-мәгърифәт таратканнар...

Шәфыйка һәм Абдураим Котдусовларның Җәвид һәм Эрнст исемле уллары үсә. 1934 елда дөньяга килгән Эрнст Абдураим улы Котдусов (Кудусов) хәзер Мәскәүдә яши. Ул, 1958 елда М.В.Ломоносов исемендәге Мәскәү дәүләт университетының география факультетын тәмамлап, диңгез ярлары геоморфологы белгечлеген ала. Галим үзенең фәнни эшчәнлеген Каспий диңгезе ярларын өйрәнүдән башлый. Соңрак Ерак Көнчыгыш диңгезләре ярларына бәйле берничә географик фәнни ачыш ясый. Үзенең ачыш-эзләнүләрен фәнни журналларда һәм әдәби әсәрләр кысасында бастыра. Эрнст — 60ка якын фәнни хезмәт, берничә ачыш авторы. Алар арасыннан «Географические авантюры» (Мәскәү,

Эрнст Абдураим улы Котдусов. Мәскәү. 1980 еллар

1999); «Противостояние продолжается (записки диссидента)» (Симферополь, 1996); «Москва и Крым» (Мәскәү, 2002); «География Крыма» (Мәскәү, 2004); «Юным дарованиям» (Симферополь, 2002); «Этносы Крыма и образование нации крымских татар» (Мәскәү, 2004) исемле китаплары аеруча игътибарга лаек.

Җәвид Абдураим улы Котдусов (Кудусов) — хор дирижёры, педагог, ТАССР һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, профессор, Петров исемендәге Халыкара фән һәм сәнгать Академиясенең әгъза-корреспонденты (Санкт-Петербург), 1998 елдан — Симферопольдә Кырым дәүләт индустриаль-педагогия университетының музыкаль тәрбия кафедрасы мөдире.

Җәвид Котдусов 1928 елның 28 декабрендә Симферополь шәһәрендә туа, балачагы Карасу Базар (Белогорск), Керчь, Симферополь калаларында уза. Җәвид ундүрт яшеннән Кара, Балтыйк диңгезләре флотларында хезмәт итеп, үз холкын авырлыкларга каршы торырлык дәрәҗәдә чыныктыра. Ул, Казан дәүләт консерваториясенең өченче курсында укыганда, татар сәнгате тарихында беренче җыр бәйрәмен Татарстанның нефть районнарында һәм Казанда үткәрә. Үзен талантлы дирижёр, оста оештыручы итеп таныта.

Консерваторияне тәмамлыйсы елда (1961) сәләтле егетне Татар җыр һәм бию ансамбленең хормейстеры итеп чакыралар, ул биредә берничә ел дәвамында сәнгать җитәкчесе вазифасын да башкара. Гадәттә, ансамбльгә авылдан килгән, музыкаль әзерлексез җырчылар кабул ителгән. Котдусов тиз арада әлеге үзешчәннәргә музыка дәресләре биреп, аларның һөнәри осталыкларын күтәрә. Ул җитәкләгән ансамбль илебезнең татарлар яшәгән төрле төбәкләрендә булып, милләттәшләребезгә халык көйләрен һәм композиторларыбыз әсәрләрен ирештерә. Аның башкаруында «Бөдрә тал», «Зиләйлүк», «Зөлхиҗҗә», «Гөлҗамал», «Сакмар» кебек кабатланмас интерпретацияле озын һәм үзенә генә хас ялкынлы темперамент белән эшләнгән бик күп кыска көйләр бүген Татарстан радиосы фондының алтын хәзинәсен тәшкил итә. Бу чорларда Татар җыр һәм бию ансамбле, Ж.Котдусовның югары һөнәри осталыгы нәтиҗәсендә, яңа уңышларга ирешә. Ансамбльдәге рухи атмосфера, танылган композиторлар А.Ключарёв, З.Хәбибуллин, Ф.Гаскәровләр белән хезмәттәшлек Җ.Котдусовка иҗади яктан камилләшү, үсү мөмкинлеге тудыра.

1970 елда, Казан дәүләт мәдәният институтында хор-дирижёрлык кафедрасы ачылгач, Җ.Котдусовны бирегә мөдир итеп тәгаенлиләр. Профессиональ коллектив белән эшләү тәҗрибәсе бай булган максатчан шәхес, хезмәт сөюе белән ул кыска гына вакыт эчендә үзешчән хор коллективлары өчен җитәкче-дирижёрлар әзерли торган кафедраны аякка бастыра .

Җ.Котдусовның таланты оратория, кантата, хор цикллары, поэма, концерт ритмнарын һәм аһәңнәрен зур формалы хор жанрларында тамашачы хозурына тапшыруда ачык күренде.

Ж.Котдусовның концерт программалары барокко, классицизм, романтизм, көнбатыш һәм хәзерге чор музыкасы белән бергә үрелеп барды, ул сәхнәдән бөек композиторлар — Бах, Бетховен, Гайдн, Моцарт, Шуберт, Вольф, Вагнер, Верди, Равель, Пуленк, Гершвин, Шостакович, Фалик, Шнитке — әсәрләрен яңгыратты. Татар халык һәм композиторлар җырларын хор белән башкаруны яңа биеклеккә күтәрде. 1970-1980 елларда аның иҗат программалары Казан рухи тормышының үзәгендә торды һәм татар күмәк җырлау сәнгатен дөнья музыкасы ядкәрләре белән баетты. Җәвид Котдусовның тагын бер зур игелекле хезмәте — кырым татарларының моңын Идел буе татарлары моңы белән бәйләп, ата-бабаларының традициясен дәвам иттерү булды.

Җәвид Абдураим улы яшь педагоглар әзерләүгә, уку процессының методикасына, укыту һәм үзешчән коллективлар өчен репертуар әзерләүгә, укучыларның музыкаль фикерләү дәрәҗәсен киңәйтүгә зур әһәмият бирде. 1994 елда, Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать академиясендә татар музыкасы кафедрасы ачылганда, Ж.Котдусов беренче кирпечне салды.

Хөрмәтле Җәвид әфәнде гомеренең көзендә бөтен талантын, сәламәтлеген биргән илен калдырып, 1998 елның октябрь аенда туган ягына — Кырымга күченеп китте. Хәзерге Кырым дәүләт индустриаль-педагогия университетының ул җан өргән музыка факультеты гөрләп яшәвен дәвам итә.

Бу елның 28 декабрендә Җәвид Абдураим улына 85 яшь тула. Аның бүген дә кешеләрнең рухи дөньясын баетып яшәргә омтылуы зур батырлык. Ж.Котдусов татар музыка тарихына милли күмәк җыр сәнгатенә нигез салучы күренекле шәхес булып кереп калачак!

Кырым һәрвакыт татарны үзенә тарткан. Кырым һәм Идел-Урал буе татарлары тарихның төрле дәверләрендә бер-берсе белән багланышта яшәгәннәр. Исмәгыйль хәзрәтне Севастополь мөселманнары үзләре янына эндәшүләре, И.Гаспралының аның улы Йосыф хәзрәтне Акъярга чакыруы һәм, еллар узганнан соң, Йосыфның оныгы Җәвид аганың ата-бабалары яшәгән җиргә кайтып хезмәт итүе — бу бер тамырдан чыккан ике халыкның дуслыгы чагылышы.

Җәвид Абдураим улы Котдусов. Симферополь. 2003 ел

Бер мәкаләдә генә югарыда искә төшереп киткән кабатланмас бөек шәхесләрнең тормыш юлларын, иҗатларын, татар халкына кылган изге гамәлләрен тулысынча яктырту мөмкин түгел. Аларның һәрберсе турында роман язарлык. Мәкаләмне әдәбият галиме Мәсгуд ага Гайнетдин сүзләре белән тәмамлыйсым килә: «...Бүген без чын батырлыкка мәйдан тарая барган, ялган «батырлыклар»га киң базар табылган чорда яшибез. Батырлык — ул кешенең камиллеккә ирешүе, асылына кайтуы... Кешелек, җәмгыять, ясалмалыклардан арынып, Исмәгыйль һәм улы Йосыф хәзрәтләр, аның балалары һәм оныклары үрнәгендә намуслы, иҗади эшчәнлек сәләтенә ия яшәешкә кайтканда гына, кешелекнең киләчәге бар дип ышанып була». ■

Әдәбият

...Көн үтсенгә язган җырлар белән
Шаккатырып булмый бу илне.
Буе аның Пушкин, Лермонтовлар,
Тукайлардан килгән буй инде.

Йөрәге дә шуларныкы кебек.
Шагыйрьләрнең юлын кан кискән...

Сибгат Хәким

КОТАДГУ БИЛИК*

(Котайткыч белем)

ЙОСЫФ БАЛАСАГУНИ
(ЙОСЫФ ХАСС-ХАҖИБ)

СҮЗ БАШЫ.
КӨНТУГДЫ ИЛБИК ТУРЫНДА

Ушлы эшне уңлар, белек өйрәтер,
Ә холыксыз дөнья үзен күрсәтер.

Бер җәфа бу дөнья: кортка шикелле,
Кыланышы кыздай, тик яше олы.

Кылыклары кыздай — җәзибәле ул.
Ләкин кочыйм дисәң, бирмәс сиңа кул.

Сөйгәнне ул сөймәс — боландай кача,
Сөймичә качканның аягын коча.

Бер битен күрсәтә язмыш, бер китен,
Холыксыз ул — аңар ярау бик читен.

Бер карый, бер кире борылып китә,
Кыланчыклана, тик бирелми һич тә.

Сансыз ир картайткан, үзе әле яшь,
Сансыз бәккә сөйләп сүзе киселмәс.

Бар иде дөньяда бер яшь бәк, белкә.
Ул яшьлек китерә белде бер илгә.

Бу Көнтугды иде, аты билгеле,
Дөньяда дан алган котлы, белекле.

*Кыланышы тугры һәм холкы уңай***,
Сүзе чын-бөтен һәм күзе-күңле бай.

Белдекле бәк иде, ушлы һәм уяу
Усалга ут иде, дошманга — кырау.

Үзе батыр, горур, кылмышы кыю,
Һәм көннән-көн артты аның абруе.

Сәясәт йөретте ул һиммәт белән,
Бу һиммәт яраша сәясәт белән.

Моңа бик бап килә бер шагыйрь сүзе
(Укыса, ачылыр укучы күзе):

«Ир кешегә һиммәт — чын ирлек кирәк,
Явызлык аңардан торсын бик ерак.

Кешелек ул — алдан хәстәрләп кую,
Кешелек ул — кеше кадерен белү».

Шундый холкы илә Көнтугды илбик
Яктыртты дөньяны кояш шикелле.

Утыртты ушлыны үзенә якын,
Хаклады галимнең гыйлеме хакын.

Җыелды янына бәкнең, асылы —
Зирәк һәм белемле халык вәкиле.

Илат, ил-көн эшен башкара барды
Ярдәмгә чакырып булдыклыларны.

Бераз миңа ярдәм бирсеннәр, — диде, —
Һәм эшкә өйрәнә торсыннар иде.

Моңаеп-уйланып әйтте бер көнен:
— Авыр эш бу — бийлек һәм юк беркемем.

Баш авырттыргыч эш һәм бетәсе юк,
Бу эшне башкарыр кеше бик тансык.

* Дәвамы. Башы журналның 10, 11 нче саннарында.
** Курсив илә язылган юллар нәкъ оригиналдагыча, тик сүзләрнең фонетик йөзе генә борынгыча.

Хәзер барча эшне кылалмыйм инде,
Эш аткарыр кеше табасы иде.

Кирәк миңа юньле, булдыклы кучты[1],
Ушлы һәм белдекле оештыргучы.

Рәхимле, һәр эше тәртипле булсын,
Теле дә, күңле дә төз-ипле булсын.

Кыла бирсен иде минем эшемне
Һәм аңласын иде эчем-тышымны.

Ни, ди, дөнья күреп күп йөргән кеше,
Яше җиткән, күпне кичергән кеше:

«Һәр иртә киңәшче-ярдәмче кирәк.
Иң тәүдә — белдекле бөкә[2], чын терәк.

Урынбасар булсын, барча эшләрен
Белеп эшләсә ул, теләк үтәлер.

Ярдәмче күп булса, бий армас, талмас,
Бар эш башкарылыр, тәртип бозылмас.

Иргә бер ярдәмче кирәк һәр эштә,
Ә билек эшендә инде — бигрәк тә.

Тик Көнтугды кеше таба алмады,
Һәр эшкә берүзе чапты, алҗыды.

Тиер булды һәр көн мәшәкать — имгәк:
Ял итим дисә — бер яңа эш кинәт.

Берәү бу хакта бик яхшы сүз әйткән
(Ул үзе ыектан[3] булган, әлбәттә):

Тыналыш теләсәң, имгәк иярә,
Сөенеч сорасаң, тормыш гамь бирә.

Күтәрелгән саен, арта ир гаме —
Баш үскәнчә арта бүрек үлчәме.

Уяу илбик тотса илгә күз-колак,
Аңарга капкалар тиз ачылачак.

Илбик буып атты яраксызларны,
Исәрләрне илдән куып чыгарды.

Ләкин саклык илә идарә итте,
Һәр эше ырады[4], ил алга китте.

Шагыйрь әйткән мондый хәлгә бик бап сүз
(Аның сүзе дөрес акылга нигез):

«Уяу һәм сак булса мактала ирән,
Гафиллектә үлгән ирләр мең төмән».

Гафил булма — саклан һәрбер эштә син,
Һәр ике дөньядан мәхрүм китмәссең.

Кешенең гамьсезе гафиллек кыла,
Яу басса, иң тәүләп гафилләр үлә.

Ни ди, ишет, берәү — дөнья тоткан ир —
Уяу булып, дошман явын еккан ир:

«Ил үсешсен дисәң, сак бул, ил башы!
Уяу булу шул ук шәригать эше.

Гафил гафиллектә йоклар гомерен,
Гафил булма — сак бул, и дәүләт ире!

Илбикнең саклыгы — илгә иминлек,
Илнең татулыгы шуннан, билгеле».

Илен төзде — барсы да бай булдылар,
Бәрәннәр белән дус булды бүреләр.

Сөеклеләреннән илбик мактaлды,
Дошманнар ишетеп хәтта баш салды.

Кайсы сыгынып килде, эстәп күшеген[5],
Кайсы килде — үпте илбик ишеген.

Күңле уяу кемсә ни ди, ишеткел
(Сүзе аллы-гөлле чәчәк шикелле):

«Бийлек ул — уяулык, уяулык — изге,
Юрыгы[6] төз булса, актыр бий йөзе.

[1] Кучты — «алпарның (рыцарьның) корал йөртүчесе», монда эшлекле ярдәмче.
[2] Бөкә — физик җәһәттән дә, рухи җәһәттән дә бик көчле кеше.
[3] Ыек — изге зат, төрки фәрештә.
[4] Ырау — тиз һәм уңышлы рәвештә алга бару.
[5] Күшек — «сыеныр җир» (шуннан, әйтмәкче, русча «киоск» сүзе килә).
[6] Юрык — яшәү юнәлеше, идеясе.

Бийлек — изге, канун тагы изгерәк,
Юрык-заңны дөрес куллану кирәк.

Ни бәхетле булыр иде халыклар,
Дөрес юлны тотса һәрбер хөкемдар».

Ни бәхет илбикнең игелек даны,
Бу дан мәңге котлы итәдер аны.

Ни шәп була бийнең һәйбәт кешесе,
Намус белән илгә кылса үз эшен.

Илбик игелеге тия бер илгә,
Даны бар дөньяга шуннан җәелә.

Бу илбикнең дә, күр, изгелек аты
Күтәрелә барды аты һәм коты.

Җиһан халкы моны белеп, һәр көнне
Аның хезмәтенә күпләп эркелде[7] *.

АЙТУЛДЫНЫҢ КӨНТУГДЫ ХЕЗМӘТЕНӘ КИЛҮЕ

Айтулды дигән бер егет бар иде.
Ул моны ишеткәч хәзерлек күрде.

Шәп углан иде ул — төпле һәм иплe,
Зирәк һәм белемле иде шултикле.

Йөзе күркәм — күреп, йөзең камашыр,
Сүзе йомшак, теле — күңел дәвасы.

Өйрәнгән иде күп һөнәр — гыйлемнәр,
Һәр бапта эш килә иде кулыннан.

Үз-үзенә әйтте шулай беркөнне:
«Илдә иң һөнәрмән — ул мин шикелле.

Нигә йөрим коры вакыт уздырып?
Керим хезмәтенә илбиккә барып.

Бийне шатландырсын ирдәмлекләрем,
Китсен миннән михнәт-имгәклекләрем.

Зирәк һәм белдекле, юньле бий, диләр,
Һөнәрле кешене кадерли, диләр».

Шагыйрьләр бу хакта әйтә бер үгет
(Шул сүзне кабатлап, уйланды егет):

«Зирәкләр кадерен зирәкләр белер.
Галимнәр янына галимнәр килер.
Ничек белсен мокыт белем кадерен?
Белемне эзләүче — белемле бийдер».

Белекләләр белер — белем кадерле.
Белексезләр каян белсен ул серне?!

Галим кадрен дә тик белә галимнәр
Һәм гәүһәр кадрен дә белә тик гәүһәр».

Шулай уйлап, кием, ат, корал-ярак
Әзерләп, Айтулды әйтте: «Хуш, барам».

Үзенә кирәкне кылды-юнәтте,
Һәм илбик ягына йөзен юнәлтте.

Уйланды: «Илбиккә барам хезмәткә,
Ничек булыр хәлләр шәһәргә җиткәч.

Мал-мөлкәт бигрәк тә кирәк чит илдә,
Әйберем төгәнсә бигрәк читен лә.

Чиксез кирәк булыр алтын һәм көмеш,
Әгәр башла, дисәм аерым бер эш.

Ни ди, әнә, белкә — гыйлеме диңгез
(Сүзен уйлап әйткән нурлы якты йөз):

«Кем дә кем сәрайга[8] хезмәткә керсә,
Кирәгер һичшиксез шул ике нәрсә:

Беренчедән, исән, сап-сау булырга,
Эшне тоткарламый хезмәт кылырга.

Икенчедән, мал — саф алтын да кирәк,
Шуны күбәйт, эшкә салып, бул зирәк.

---

[7] Эркелү — бер үзәккә омтылып җыелу.
[8] Сәрай — дворец, ә сарай — подсобное небольшое здание.
* Аратта өстәмә:
Бәхет кушагын ул баглады җиргә:
Сарык һәм бүреләр йөреде бергә.

Хезмәтең уңышлы булыр шулчакта,
Юлыңда ачылыр һәр бикле капка».

Шулай дип ул алды көмеш-алтыннар,
Кирәк булачак дип, алды күп тавар.

Өеннән чыкты һәм юлга юнәлде,
Бер йөреп, бер туктап, шактый юл алды.

Килеп җитте илбик торган урдага
«Ирештер, — дип, — күңлем теләк-арзуга».

Кәнткә[9] керде, куныш сорады шунда,
Кертүче булмады — тарайды дөнья.

Мосафирханәгә ахыр юнәлде,
Моңайган хәлендә шунда төнәде.

Ни, ди, ишет инде, белкә бик белеп
(Ул әйтә сынап һәм дөньяны күреп):

«Ничек кыен, күрче, белемсез кеше
Ят җирдә йөресә яп-ялгыз башы.

Тәүге тапкыр килгән булса берүзе,
Мөшкиллектә кала мондый килүче.

Белемсез ят кеше бер сукыр кебек,
Нәрсәдер сораса, җибәрмә сүгеп.

Бөтенләй чит илгә эләксә бер ир,
Тел яшергән килен шикелле йөрер.

Ятны ярлыка, дип, бир ашам-эчем,
Илгизәрне изге бел, яхшы кеше.

Мосафирны кунак ит, ди изгеләр.
Дан сиңа, өеңдә кунса илгизәр.

Кешегә кирәк һәр җирдә белешләр,
Шулар белән эшләп була күп эшләр».

Айтулды шактый ук каңгырып йөрде,
Кайгырудан хәтта саргайды йөзе.

Сорашып-күрешеп, күп нәрсә белде,
Торак сатып алды — ачылды күңле.

Якын һәм дус булды төрле кешегә,
Якты булды йөзе олы-кечегә.

Дус итте бигрәк бер яхшы кешене,
Күсәмеш[10] иде ул дусның исеме.

Аңа Айтулды ачты эч серен —
Теләге нилеген, үзе кемлеген.

Әйтеп бирде үзе ниләр белгәнен,
Үз җиреннән монда ничек килгәнен.

Ирсү дигән бер хасс-хаҗиб бар иде,
Хөкемдә илбиккә бәрабәр иде.

Һәм Күсәмеш бер көн дәстүр[11] теләде,
Хаҗибкә керде һәм хәлне сөйләде.

Хасс-хаҗиб сорашты хәлне җентекләп,
Килүче турында төп-төгәл, төптән.

Күсәмеш сөйләде аның турында —
Теләге ни аның, ни бар уенда.

Хаҗиб әйтте: «Әйдә, дәстүргә килсен,
Мин аңарга карыйм, ул мине күрсен.

Илбиккә дә әйтеп карыйм, без бергә
Уйлашырбыз сиңа кайчан килергә.

Күсәмеш дәстүрдән кайтты: «Котлыймын,
И, Айтулды, синең туа ич көнең.

Барып күрешерсең, хасс-хаҗиб белән,
Шаять, ирешерсең үз теләгеңә.

Сине күрсен, белсен, ишетсен сүзең,
Ни теләкләрең бар — әйтерсең үзең.

Сүземне сөйләдем мин бәйнә-бәйнә,
Миннән дә яхшырак син аңлат янә.

[9] Кәнт — даладагы кала, кирмән. (Төп текстта кәнт диелгән). К. татарча диалекталь кәнт «нәкъ, үзәк».
[10] Күсәмеш — «теләкче», «теләктәш» дигән сүз.
[11] Дәстүр — кабул итү һәм кабулханә (приёмная).

Ни шәп әйткән берәү — теле, күңле төз
(Уйлап баксаң әгәр, бик тә тугры сүз):

«Кеше кабатлыйдыр бүтәннәр сүзен,
Ләкин һәрвакытта уйлый үз-үзен,

Синә кемдер ничек якын булмасын,
Асылда үзеңне уйлап куясың.

Үзеңне аяучан кеше эзләсәң,
Иң тәүдә ул үзең булыр, вәссәлам».

Киенде Айтулды, Күсәмеш бергә.
Киттеләр хасс-хаҗиб чакырган җиргә.

Капудан керүгә болар икесе
Килеп каршы алды хаҗиб кешесе.

Күсәмеш тәүбашлап керде дә алдын,
Бераздан соң чыгып чакырып алды.

Каршы алды хаҗиб. Чакырды түргә.
Җылы сүзләр әйтте. Ни яхшы, күр, ә?

— Кәефләрең ничек? Әйбәтме хәлең?
Килеп, кая төштең? Кайдасың хәзер?

Белешләрең бармы, якын кардәшең?
Бармы иптәшләрең, ашарга ашың?

Янә әйтте: «Бездән теләгең нидер.
Ни эстәп йөрисең? Кирәгең белдер».

Һәм Айтулды әйтте: «И, котлы хаҗиб,
Ишеттем Көнтугды һиммәтле хан, дип.

Күптән үк ишеттем мин аның данын —
Белемле һәм зирәк илбик булганын.

Шундый бәккә хезмәт итәргә иде
Дип үк капусына ерактан килдем.

Ошбу теләктәмен, и тәкъсир, инде
Минем сүзләремне җиткерсә идең».

Хаҗиб Айтулдыга сөеп карады,
Мактау сүзләрен дә бик кызганмады:

— Кыяфәтең күркәм, сөйләвең куштан,
Тугрылык билгесе күренә тыштан.

Ни ди берәү — үзен сөйкемле итмеш:
— Җитешсез ягың да күренсен җитеш.

Яраткан гайбеңә дә карар сөеп,
Яратмаганга шәп ягың да — гаеп.

Бу сүзнең исбаты ошбу сүзләрдә
(Ишет һәм хәтерлә, и изге бәндә):

«Күңел кемне сөйсә, гаебе дә матур
Барча киресе уң, караңгысы — нур.
Күңел кемне сөйсә, ул тоташ гүзәл,
Күрексезлеге дә күренмәс булыр».

Хаҗиб Айтулдыга: «Ярый, сабыр ит,
Минем сөйләгәнне тыңла, кабул ит.

Иң элек илбиккә әйтим сүземне —
Кайда, кайчан кабул итәр үзеңне.

Сине белсен дә, дус итеп карасын,
Хөрмәт итсен сине, арзанламасын.

Менә сиңа карап тордым һәм хәзер
Сөеп, эшләреңне җайларга әзер»,

Кебек сүзләр әйтеп, тынмады теле.
Эшеңне эшлим, дип баглады билен.

Кешенең изгесе шулай буладыр,
Халаекка шундый хезмәт кыладыр.

Ни, ди, бар халыкка баш булучы ир,
Күп эшне һәм төгәл башкаручы ир.

«Кемнең мөмкинлеге булса киң вә зур,
Халыкка изгелек кылу фарыз ул.

Кемнең кулы озын булса халыкка,
Ул ия булсын төз, дөрес холыкка.

Ил күзендә торса кемнең хаяте,
Булсын сөчек[12] телле, матур гадәтле.

Вафасыз бу дөнья төзәр һәм бозар,
Җыелды бу, дисәң, яңадан тузар.

---

[12] Сөчек телле — татлы телле.

Бүгенге бәхеткә ышанма — бул сак,
Җәренгә урының кайда булачак?

Бәхет тапсаң аңа куанып шашма —
Көтмәгәндә китәр дә куяр ташлап.

И, дәүләт иясе! Хәлең нык булсын,
Дисәң, беренче шарт — изгелек кыл син.

Сиңа тисә билек-ханлык, олуглык,
Кечелекле холык булдыр, иң элек».

Хаҗиб әйтте янә: «Кайт инде, йөре,
Сөен, багладың син бәхет кәмәрен[13].

Син гарьләнмә — эшне бозма ашыгып,
Вакты җиткәч, ошбу капка ачылыр.

Бер белекле ни шәп әйткән бу сүзен:
(Белекленең сүзе — бәрчен һәм бүзең[14]).

«Кем вакытыннан элек ыргылса эшкә,
Калыр бу кыланыш тик үкенечкә.

Форсатын бел, эшкә шуннан соң тотын,
Барча эш, и бөкә, сөяр вакытын».

Ишетеп барча бу сүзне, Айтулды
Әйтте: «Хуш, мин сабыр итәргә булдым.

Хаҗиб мине тыңлап гарзымны белде,
Вакытын, шартын үзе хәл итсен инде.

Хаҗиб үзе мине кайчан чакырса,
Килеп җитәрмен мин шул ук вакытта».

Шулай дип Айтулды өйгә кузгалды,
Барган урамнары эңгердә калды.

Хаҗиб күрде холкын бу Айтулдының,
Бүтәннәрдән бераз аерым торуын.

— Күргәнем юк, — диде, — мондый егетне,
Белемле һәм зирәк, гомумән, өстен.

Шушындый кешеләр илбиккә кирәк,
Илбиккә кирәкләр илгә бик кирәк.

Шушындый кешеләр сирәк табыла,
Сирәклеккә күрә кирәк тә була.

Нәрсә сирәк булса, шул кыйммәтлерәк —
Аны табу өчен күп хезмәт кирәк.

Максатка җиткерә кеше ирдәме,
Күпләргә дә тия аның ярдәме.

Вакыт табып, хаҗиб илбиккә керде,
Айтулды хакында аңар җиткерде.

Әйтеп бирде холкын, гарзын, кемлеген,
Санады һөнәрен,ниләр белүен.

Тыңлап, илбик әйтте: «Китер, бер карыйк.
Каян килгән, нишли, нәрсәгә ярый?

Шундыйрак кешене мин теләр идем,
Үти алсын миңа илбикләр эшен.

Әйтик, эшләремне мин җайга салдым,
Тик шәп ярдәмчегә бик тә мохтаҗмын.

Бар, аны тиз генә син монда чакыр,
Хәзерлә хезмәткә, и алпар — батыр».

Торып чыкты хаҗиб, капуга[15] килде,
Бер углан[16] йөгертте: «Әйтеп кил», — диде.

Ул углан-хәбәрче барды йөгереп,
Айтулды киенде шундук, сөенеп.

Ашыгып, капуда атыннан төште,
Хаҗиб та каршыга килеп җитеште.

Чакырды ханәгә, күрсәтте түрне,
Айтулды вәкарьләп утырды, күрче.

Илбик әйтте: «Чакыр, ул миңа керсен,
Мин аны күрим һәм ул мине күрсен».

[13] Кәмәр — алтынлы билбау, каеш.
[14] Бәрчен — ефәк төре, бүз — кыйммәтле мамык тукыма (борынгы мәкаль китерелә).
[15] Капу — сәрай капкасы.
[16] Углан — хезмәтче егет.

Хаҗиб чыгып әйтте: «Айтулды, әйдә,
Бәхет кәмәреңне билеңә бәйлә».

АЙТУЛДЫНЫҢ БИЙГӘ КҮРЕНГӘНЕ

Бу Айтулды керде, бийгә күренде.
Ачылды илбикнең күңле, сөенде.

Айтулды йөгенде[17], кыеп, сүз ачты,
Сөчек теле илә бийгә ярашты.

Илбик әйтте: — Кем син, ничек исемең?
Кайлардан киләсең, нindидер илең?

Ипләп кенә ачты Айтулды телне,
Сүзен чичәнләрчә матурлый белде.

Дусларча сүз башлау — акыллы эше,
Тупас сүзле — хайван, түгел ул кеше.

Менә шул мәгънәдә әйткән бер шагыйрь:
«Эш башлап, ашыкма, уйла, бул сабыр.

Каударланма һич тә һәм бул тынычрак,
Белешми эш итсәң, үкенәсең, хак.

Барча хәлдә сакла салкын акылың,
Сабыр булган — колдан бий булган соңын».

Һәм Айтулды әйтте: «И, котлы илбик,
Яхшы бийдә коллык — ул хөрмәт кебек.

Атым — кол, хезмәткәр, урыным ишек,
Кылганым — кешелек, шулдыр төп эшем.

Сиңа килдем теләп, озын юл йөреп,
Теләккә ирештем озак тилмереп.

Хәзер теләгем шул: кире җибәрмә,
Хезмәтеңдә якын булыйм — җирәнмә».

Моны ишеткәч, күр, сөенде илбик.
Димәк, тапты үзе теләгән ирне.

Һәм әйтте: «Айтулды, мин күрдем сине,
Сөендерде холкың һәм күркең мине.

Үзең рәхим итеп, бул хезмәтемдә,
Капуда булырсың — миңа якында.

Синнән хезмәт, миннән әҗере булсын,
Ача хезмәт кенә бәхет капкасын.

Тайпылмыйча хезмәт кыл, син, бүгеннән,
Хезмәт хакын исә бәгең билгеләр».

Айтулды җир үпте, күр, әйтте: «Илбик
Елмайса, ачыла дәүләткә ишек.

Хезмәт өчен килдем мин өйдән торып,
Озын юл йөредем сиңа йөз орып.

Куәт бирсен Аллаһ сиңа хезмәттә
Һәм сәламәт булыйк инде, әлбәттә».

Урыныннан торды, елмаеп чыкты,
Күңеле ачылды — карашы якты.

Бәхет дулкынында йөзгән бер егет,
Теләгенә җитеп, әйткән бер үгет:

«Көлә бакса мескен бәндәгә бийләр,
Күтәрелер өмет тулып күңелләр.

Ачык тотса биләр бөрәүгә йөзен
Ярыр ир күзе[18] һәм ярашыр сүзе.

Бийләр кемне якын итсә, яратса,
Шуны яраталар куштан-яраннар».

Көнен торгак, кичен яткак[19] булды ул,
Шулай бийгә тугры хезмәт кылды ул.

Бийгә керү — чыгу эшен башкарды,
Илбик аны сыный-күзәтә барды.

Тапшырды яңадан яңа хезмәтләр
Һәм эш, дәште аңа һәрчак хөрмәтләп.

---

[17] Йөгенү — тез чүгеп, сәламләү, хөрмәт күрсәтү.
[18] Күз ярыу — күзең якты булу, ягъни шатлыкта булу; Себер сөйләшләрендә дә киң кулланыла торган борынгы тәгъбир.
[19] Торгак һәм яткак — борынгы терминнар: көндезге һәм кичке дежурлык итүче хезмәткәрләр.

Хезмәтенә күрә хөрмәте колның
Һәм кечек кол шулай буладыр олуг.

Хезмәт иткән, диләр, бийгә яраган;
Хезмәт күрсәтмәгән нигә яраган?

Ни әйтә күп күргән белкә кешеләр
(Үгеткә яраклы нечкә фикерләр):

«Тугрылар талантсыз да түргә җитә,
Яраксыз яраныр да алга үтәр»;
Тайпылышсыз хезмәт иткән кешеләр
Хезмәте сеңсә, һәрчак алга китәр».

Төгәл эшләп килгәч көнендә эшен,
Илбик аңар киңрәк ачты ишеген.

Айтулды аң-белем туплады эштә
Һәм булды тынычта вә сөенечтә.

Хезмәттә остарды, тәҗрибә артты,
Илбик аңар ныграк ышана барды,

Һәм егет күптөрле хәлдә сыналды,
Эшендә абруйлы иркенлек алды.

АЙТУЛДЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ БАШЫ КАРШЫНДА БУЛГАНЫ

Илбик бермәл ялгыз утырган мәлдә
Айтулдыны дәште шатлыклы хәлдә.

Кереп дәргяһына[20] басты Айтулды,
Бире кил, дип, илбик ымлап чакырды.

Чыгарды бер зур туп, утыр, дип, шуңа.
Айтулды утырды бераздан гына.

Сорады мәгълүмат — төрледән-төрле,
Айтулды тел ачып җаваплар бирде.

Бик сөенде илбик, балкытты йөзен,
Ә Айтулды аска каратты күзен.

Тынып калды илбик һәм сүз дәшмәде,
Айтулды шунда да күзен ачмады.

Илбик аңар тагын сораулар бирде,
Айтулды шунда да йөзен ачмады.

Һәм илбик сынады, аңар күз тегеп,
Акылын, белемен һәм зирәклеген.

Сөеп бакты илбик. Шаярып алды.
Тик Айтулды йөзен чөерде тагы.

Каһәрләнде илбик. Йөзе каралды.
Әйтте: «Бу кылтаю сиңа ярармы?

Ялгыштым мин үзем — ышандым артык.
Моны чит кешегә ничек аңлатыйк?

Белекле затлар ни диләр — колак сал:
Ашыгу зыяны сузыла елларча.

Пешмәгән аш тәнгә чир булып керер,
Шашкын карар җанга газап китерер.

Шашудан ул ялгыш юлга төшүләр;
Ашыкмаган барча изге кешеләр.

Ялгышым шул булды: шашкын эш кылдым.
Кешене белмәстән якынлаштырдым.

Акыллы бий, кирәк булса хезмәткәр,
Эшләтеп күрмичә алмый хезмәткә.

Хезмәттә катнашып, сынап күрергә,
Тик эш кадрен белсә, урын бирергә.

Айтулды сүз атты: «И, изге бием,
Нигә ачуланып киттегез инде?

Языгым нидә соң — бер дә белмимен.
Әйтеп бир һәм сораш, сөйләп бирермен.

Языгым бар икән — мәелең, кыйна,
Югыйсә йөзеңне каралтма миңа.

Ни, ди, мондый хәлгә карата канун
(Кыяс ысулыннан[21] килеп чыккан ул):
«Хезмәтче ялгышса, чакыртып тизрәк,
Ялгышлык сәбәбен сорарга кирәк.

---
[20] Дәргяһына — хөрмәтле затның каршысына.
[21] Кыяс ысулы — чагыштыру, аналогия ысулы.

Гөнаһы бар икән — җәза бирергә,
Гөнаһы булмаса, шелтәлә ипләп».

Моңа каршы илбик ярсынды тагын:
— И, надан, белексез, акылсыз азгын.

Син үзеңне кара — син кем дә мин кем?
Бу горурлык синдә каян бу тиклем?

Хезмәтем бар, дисәң — ансы әле юк,
Файдалымын, дисәң — ялган шулай ук.

Мин сиңа тиешсез илтифат кылдым.
Урын биргән идем — бардың, утырдың.

Ул тупка, гадәттә, асыл, лаеклы
Зат утыра, ә син утырырлыкмы?

Сиңа сөйләдем һәм сүзең тыңладым,
Күзләреңне йомдың — бу ни? Таң калдым.

Кичердем берьюлы, мин сөйли бирдем,
Ә син исә тагын йөзең чөердең.

Беләсеңме, ни ди белкә — акылдар:
«Бик игътибарлы бул бийләр янында».

Атаң яки анаң әйтмәдемени:
«Бийнең каршысында бик үзсенмә», — дип.

Аңлатмадымыни ыру башы да
Ничек кыланырга бийләр каршында?

Бийләр ялкын сыман — хәтергә алыйк,
Бигүк якын барсаң, яндырыр, анык.

Гамьсез булып торсаң, ялкын ялманыр,
Өстенә кабынса, ут чолгап алыр.

Хөкемдарлар сөя буйсынганыңны,
Юкса башың кисә, суыра каныңны.

Бер карауда алар котың алалар
Яки көч кулланып, дәһшәт салалар.

АЙТУЛДЫ ИЛБИККӘ ДӘҮЛӘТ БАШЫ СЫЙФАТЛАРЫН АҢЛАТА

Айтулды көлде һәм әйтте: «Аңладым,
Син сорадың — әйттем. Мине тыңла, дим.

Хәлеңне аңладым мин синең тирән.
Хәзер син үзең дә белүең кирәк.

Инде менә синең янга килгәнем —
Тугры булу минем гадәт, дигәнем.

Урын бирдең, тик буш калды урындык,
Мин белдердем — миңа тиеш урын юк.

Тупны тәгәрәттем — шуны белдердем:
Мин үзем туп кебек тәгәрәп йөрим.

Бер үзе генә туп булалмый терәк.
Шуның кебек дәүләт — китәргә тора.

Сине сөеп карасаң, мин күз сирпермен,
Ягъни синең кебек фикер йөртермен.

Мин — дәүләт, ди. Һәм мин, сукырдай, кемне
Тотып алсам, шуны җибәрмим инде.

Янә сөйләдең син, мин дә сөйләдем:
Сөеп бактың исә, йөзне кизләдем[22].

Күрсәттем мин шулай дәүләт кылыгын
— Ышанырлык түгел аның холыгы.

Ни ди, ишет, менә төркичә мәкаль
(Моны әйткән күпне күргән аксакал):

«Агар су, тасма тел, ку кот тик тормый,
Алар илгизәрләр кебек — һич тынмый.

Ышанычсыздыр дан, бәхет вафасыз:
Аягы таючан һәм ул ава тиз.

Куанма ку[23] шанга, котка — дәүләткә,
Акыллы падишам, торма гафләттә!

Дәвамы алдагы саннарда

Филология фәннәре докторы, профессор
Рифкать Әхмәтҗановның
шигъри тәрҗемәсе ■

[22] Кизләү — яшерү, каплау (чагыштыр: кизләү чишмә — өсте каплана торган чишмә).
[23] Ку — буш, күренеше генә бер, эчтәлеге юк нәрсә.

ХАТЛАР БУЛЫП КАЛГАН ХАТИРӘЛӘР

ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАР!

ЖУРНАЛНЫҢ БУ САНЫНДА СЕЗНЕҢ ИГЪТИБАРГА КЛАССИК ӘДИПЛӘРЕБЕЗ ГОМӘР БӘШИРОВ ҺӘМ ФАТИХ ХӨСНИНЕҢ РАФАИЛ ТӨХФӘТУЛЛИНГА ТӨРЛЕ ЕЛЛАРДА ЯЗГАН ХАТЛАРЫН ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ. КЫЗГАНЫЧ, Р.ТӨХФӘТУЛЛИННЫҢ ҖАВАП ХАТЛАРЫ САКЛАНЫП КАЛМАГАН.

РЕДАКЦИЯДӘН

ГОМӘР БӘШИРОВ ХАТЛАРЫ

Беренче хат

Рафаил дус!

Бу хикәя артыннан озакламыйча син үзең килерсең кебек иде, үзең белән сөйләшергә җыенып тора идем. Син килгәнсең дә киткәнсеңме, ничекме, күрә алмадым. Ә хикәяң һаман тора бирде. Инде мәнә озакламый яңадан чыгып китәсе булганлыктан, хат язарга булдым. Туп-туры һәм ачык итеп әйтим: бу хикәя уңышлы чыкмаган. Нигә? Ничектән? Мәнә уйлашып карыйк. Минемчә, монда гомумиләштерү җитми. Характерлы, үзенчәлекле образлар бирәсе урында, син тормышта булуы да, булмавы да мөмкин бер вакыйганы алгансың да шуны хикәя итеп язгансың. Дөрес, тормыштан туп-туры алып язган вакыйга да әдәби әсәр була алырга

мөмкин. Тик моның өчен аңа байтак кына шундый элементлар кирәк.

Бу хикәянең исемен «Кем гаепле?» дип тә куярга мөмкин булыр иде. Чөнки монда шундый сорау үзеннән-үзе туа, ә җавабы юк. Син әнә шадра председательне каһәрлисең. Дөресме? Минемчә, юк. Председатель үзенчә хаклы. Иң элек бит дуңгыз — балалары өчен әни — аларны тәрбияләүче кеше җавап бирергә тиеш. Ул үз урынында кеше калдыруга ничек кенә булса да ирешергә тиеш иде. Шушы җаваплы кеше, эшенә бармыйча, кабартма пешереп йөри икән, аның ачуланырга хакы бар. Хамидәнең дә әллә ни гаебе юк кебек. Апа кеше бераз ачуны китерә, чөнки әнисе урынына ул бара алган булыр иде. Кыскача. Монда берсе дә чын-чыннан гаепле түгел, әмма гаеп аз-азлап кына барысында да бар.

Хикәя булып чыкмаган, аерым бер орган булып калган.

Минемчә, шушындагы рамкадан чыгарга уйласаң, моннан төзәтеп караганда да әйбәт хикәя чыкмас.

Теге «Күләгәле койма» дигән хикәя … яза башлаганнарың бар иде шикелле. Алары ни хәлдә? Син инде ничек тә әнә шундагы югарылыктан түбән төшмәскә тырыш. Шул ук геройлар катнашындамы, яңаларын өсти барыпмы.

Әмма шундагыча аерым образларны күперенке, күрерлек, яратырлык яки нәфрәтләнерлек итеп бирергә тырыш. Хикмәт — шунда, хикмәт — характерда, образларда. Бусында исә характерлар оешып җитә алмаган. Шуның белән бу хатны тәмам итеп, киләчәк әсәрләреңә уңыш теләп калам. Институтка алганнар дип ишеттем, бик шәп булган. Көз көне Мәскәүгә яшьләр семинарына да барасың булыр әле. Ул да күп нәрсә бирер.

Сәлам белән, Г.Бәширов

Яңа хикәяң булса — җибәр, монда килсәң, безгә дә сугыл.

11.08.1955

Казан

Икенче хат

Исәнме, Рафаил!

Ягымлы хатың өчен, «И язмыш, язмыш…» хакында куанычлы фикерләр әйтүең өчен сиңа зур рәхмәт. Мондый хатлар үзеңә ышанычны ныгыта. Күңелне күтәреп җибәрә. Йокысыз төннәрең, иксез-чиксез борчылуларың, икеләнү-шикләнүләреңнең җилгә китмәвенә ышанасың.

Минем яшьтә каләмдәшләрнең фикере аеруча кадерле. Үзеңә-үзең ышаныбрак карый башлыйсың. 85 ел уен түгел! Әнә нинди үзгәрде дөньялар. Бөтенләй яңа кеше дөньяга пәйда булды. Әллә аңлый ул сине, әллә юк. Яшьләр арасында безнең буын кешеләрен ихтиозаврлар белән янәшә итеп күрүчеләр дә юк түгел бит. Хәтта «Җитәр инде, сугыш турында тыңлаудан туеп беттек!» — дип кычкыручылар бар икән. Коточкыч җансызлык, имансызлык бит бу! 50 миллион корбанны, канлы күз яшьләрен ничек онытмак кирәк! Әнә шундыйларның туң йөрәген аз гына эретеп булмасмы икән дип язасың. Бу бит безнең вазифабыз.

Әсәрне эчтән җылытып торучы тагын бер нәрсә — яшьлекне сагыну. Болар бит күбесе үзебезнең баштан үткән хәлләр. Сагындыра алар, кыены, газабы, рәхәте, михнәте — барысы бергә кушылып сагындыра.

Бу әсәрне язгач, үземә-үзем бер нәрсәне ачтым: беренче заттан мин, бүтән алымнарга караганда, нечкәрәк, үтемлерәк итеп яза алам бугай, ахрысы. Моны мыекка чорнарга кирәк әле. Тик бер үк алымны еш кабатларга ярамый.

Мин үземне хәзер «файдага калган» кеше сыманрак хис итәм. Чөнки минем яшьтәшләремнең күбесе «китте» инде, калганнары да, кызганычка каршы, сафтан чыкты. Мин, шөкер, яза алам әле. Гомеремне дә айлар, еллар белән түгел, әсәрне язарга киткән вакыт белән исәпләп йөртәм. Моны-

Мәскәүдә яшь язучылар конференциясе. Беренче рәт (сулдан уңга): Р.Төхфәтуллин, Г.Бәширов, Х.Госман, Р.Шәйхетдинов; икенче рәт: Х.Камал, Ш.Хөсәенов, Ю.Малевинский. 1956 ел, декабрь

сын тәмамладым, икенчесен башладым. Хәзер инде миңа шунысын аякка бастырмыйча һич тә китеп барырга ярамый! Закон!..

Бу әсәрем тәмамланганчы килеп чыга-нитә калса, газраилгә:«Карале, агай-эне, тыңла әле сүзне, китеп тор әле беразга!» — дип әйтергә исәп...

Инде синең искәрмәңә җавап. Соңгы җөмләне әйткәндәге Зәйни хикәя башындагы Зәйни түгел бит инде ул. Байтак еллар узып, тормыштан шундый сабаклар алгач, ул яшәеш фәлсәфәсен тирәнрәк аңларга тиеш. Теге елларны яшьлек кызулыгы белән иң дөрес юлдан киттем дип йөрсә дә, тормышның әнә нинди тирәнлектә яткан серләре бар икән бит...

Үзеңә сәламәтлек, эшеңә
уңышлар теләп,
күп сәламнәр белән: Г.Бәширов
21.04.1986

ФАТИХ ХӨСНИ ХАТЛАРЫ

Беренче хат

Рафаэль иптәш Төхфәтуллин!

Сез яшь язучылар киңәшмәсенең 9 январьда ачылуы турында Москвадан хәбәр алгансыз дип уйлыйбыз. Монда иптәшләр 7 январьда сәфәр чыгарга уйлап торалар. Билетлар 7 январьга заказать ителде. Ә сезнең, юл төенчегегезне тотып, 6 январьдан да соңга калмыйча, Казанга килеп җитүегез кирәк. Расчёт яклары Москвада ясалачак, шуның өчен юл расходларына (бу яктан китүгә) үз чамагызга исәп тотарга туры килер.

Шушы турыда Сезгә хәбәр итәргә кирәкле таптык.

Сәлам һәм хөрмәт белән:
Язучылар Союзы правлениесенең
җаваплы секретаре:
Ф.Хөсни
1955 ел, декабрь

Икенче хат

Рафаэль туган!

Ниһаять, сине Союзга член итеп алу мәсьәләсен чынлап торып куярга вакыт җитте бугай. Без кабул итү, оформление яклары үз оешмабызда хәл ителгәнче диебрәк (яңа устав буенча мондый хокук безнең үз оешмабызга бирелә) торган идек, ләкин яңа Устав әле хәзергә кадәр директив органнарда расланмаган, шунлыктан оформление ягы Москвага кайтып кала. Димәк, яхшы дип тапкан әйберләреңнең подстрочный тәрҗемәләрен әзерләтергә кирәк. Боларның кайберләре инде бездә (яки Сезнең үзегездә) булырга тиеш. Шушы якларын яхшылап уйлап, нәрсәләрне тәрҗемә иттерергә кирәклеген әйтеп, оригиналларын җибәреп куегыз.

Аннары менә без сиңа Союзга алыну алдыннан тутырылырга тиешле кәгазьләрнең бланкларын җибәрәбез, тутырып җибәр. Гаризаны аерым кәгазьгә кулдан 2 экз. яз.

Сәлам һәм хөрмәт белән:
Ф.Хөсни
21.03.1956 ел

Өченче хат

Рафаэль дус!

Нишләп әле син болай кинәт тынып калдың? Подстрочникларың кайда? Нигә аларны тәртипкә китереп җибәрмисең? Приём мәсьәләсе ярты юлда тукталып калды бит. Теге вакытта сөйләшенгән буенча ике экземпляр әзерләп җибәрә күр һәм мөмкин кадәр тизрәк. Берсе монда кала, икенчесе Москвага — офомлениегә китә. Шунда, беррәттән, бездән алып киткән подстрочникны да җибәрерсең дип уйлап калам.

Сәлам һәм хөрмәт белән:
Ф.Хөсни
29.05.1956 ел

Дүртенче хат

Рафаэль!

Кайда һәм нишләп болай тынып калдың әле син?

Әлеге теге членлык мәсьәләсен ахырына кадәр җиткерәсе иде бит! Соңгы вакытта кабул ителгән башка иптәшләрнең документларын оформление өчен Москвага җибәреп бетердем. Сез генә торып калдыгыз.

Шуңа күрә кабат исегезгә төшерәм: подстрочникларны рәтләп җибәрегез. Шулай ук Союздан алып киткән «Знакомый гул»ның подстрочнигын җибәрергә дә онытмагыз.

Сәлам һәм хөрмәт белән:
Ф.Хөсни
27.06.1956 ел

Бишенче хат

Хөрмәтле Рафаэль дус!

Сезнең Г.Бәширов исеменә язган хатыгыз нигезендә, без, Татарстан Язучылар союзы правлениесе исеменнән, Тукай райкомы секретаре Хәниф Сафиуллин иптәшкә һәм шулай ук «Кызыл юл» газетасы редакторы Сөнгатуллинга хат язып җибәрдек. Алар, шәт, каршы килмәсләр дип уйлыйбыз.

Сез, бу хат барып җиту вакытын чамалап, үзегез КПСС райкомына тагын мөрәҗәгать итәрсез инде.

Бик ашыгыч язылды бу, вакыты шундый ашыгыч туры килде, гафу итегез инде.

Эшегезгә уңышлык теләп:
Фатих Хөсни
2.02.1957 ел

Хатларны басмага
Р.Төхфәтуллинның улы
Рөстәм Төхфәтуллин *әзерләде.* ■

РӘШИД РӘШИДОВ*

(Кечкенә роман)

АЙДАР ХӘЛИМ,
прозаик, шагыйрь, публицист,
Г.Исхакый исемендәге әдәби премия лауреаты

IV

Казанга ул ун көн барды. Вагон түбәсеннән — вагон түбәсенә, стансадан — стансага. Тимер юл хезмәткәрләре күзенә чалынса, тегендә качты, монда посты, ашказаны йотыкса — хәер сорашты. Әгәр атасы әйткән Сәгыйть абкасы булмаса, юк, дөресрәге, теге ялкынлы, җылы, хәтта ки кайнар, нурлы шигырь чакырмаган булса, ул Казанга бу кадәр тартылмас та иде. Аларның гаилә ядкәрендә Сәгыйть абкасының ак күлмәк, кара күбәләк киеп төшкән купшы сурәте саклана. Гарәпчә һәм русча укый-яза белгән егет авылдан 1923 елда чыгып киткән. Серпухов шәһәрендә урнашып алып, коммунистлар партиясенә кергән. Кыска гына вакыт эчендә җиңел промышленность эшчеләре профсоюзы җитәкчесе булып үрләгән. 1926 елда шәһәргә культура наркомы Луначарский килгән һәм фабрика директорына: «Миңа Казанга укырга җибәрү өчен бер бик тә булдыклы татар егете кирәк», — дип сүз тишкән. Казанга килгәч, абкасы үзенең бер якташына аны укырга Луначарский үзе җибәрде, дип сөйләгән. Теге абкасының мулла баласы булуын тиешле җиргә хәбәр иткән. Абкасын партиядән чыгаралар, университетка укырга керүдән тыялар.

Авыр көннәр кичерсә дә, абкасы аны бик яхшы каршылады. Күпмедер вакыт аның гаиләсендә, Бишбалтадагы бер бүлмәләрендә яшәде. Әмма озакламый аның артык кашык икәнлеген, китәргә кирәклеген сиздерделәр. Шулай итеп, унөч яшьлек Рәшид Казан шәһәренең ата-анасыз «беспризорнигы»на әйләнде.

Каен орысы шикелле каты, туп шикелле түгәрәк, елгыр, мөлаем йөзле, шаян һәм уенчак Рәшидне Яңа һәм Иске Бистәнең үсмер шпаналары үз итеп кабул итте. Моңа малай үзе дә атлыгып әзер иде, ни өчен дигәндә, күп балалы гаиләләрдән чыккан өйсез ятимнәр тирә-юньгә, кешеләргә тиз ияләшә иде. Утызынчы еллар башыннан алып тыелган, әмма төрле оешмалар тарафыннан басып алынган Печән Базары мәчете тирәсе татар беспризорникларының штабына әверелгән иде. Әмма ул үз язмышларына каешланып беткән башка йорт-җирсез малайлар кебек теләсә кемгә ияреп китеп, ниндидер кушылган хезмәт, йомышлар үтәргә курка иде. Ачлык башка җиткән шәһәрдә ятимнәрне урлыйлар, үтереп, итләрен бәлешкә, пилмәнгә кулланалар икән, дигән куркыныч сүзләр йөри иде. Һәм бу хәбәрләр нигезсез дә түгел иде. Мәетләрне җирләргә кеше булмаганлыктан, аларны Казан вокзалы мәйданына өем-өем итеп өйгән заманнарда әлеге хәлләрне булмас дип кем әйтер? Татарның атаклы гармунчысы Фәйзулла Туишевны, ыңгырашуын ишетеп, шушы өемнәрдән суырып чыгаруларын кем генә белми?!

* Дәвамы. Башы журналның 10 нчы санында

Артык ипие-сөте ташып бармаса да, сирәкләп камыр ашы исләре аңкыштырган татар башкаласында үзе кебек ятим-җилпеләр аңа гамәлхезмәтен дә табып бирделәр. Дөресрәге, башкалардан күреп, яңа кәсәбәгә кереште: Печән базары мәйданының Париж Коммунасы һәм Мәскәү урамнары чатындагы сыра балаганнары арасына тал кебек тамыр җибәреп, үткенчеләрнең итек-читекләрен чистарта башлады.

Сәүдәдән яратылган татар баласы кесәсенә кергән акчага «Кызыл йолдыз» дигән нәзек папирос сатып алып, берничә тиен хак өстәп, берәмләп сатарга кереште. Дөнья — кәрмәҗин, син — ак мулла, мин — мәзин!.. Сыра сәүдәсе тәүлек буе туктамаганлыктан, ул сырачыга агылыйга-тагылый дигәндәй, иртәдән төн уртасына кадәр итек чистарта, кирәк кешегә папирос төртә, төн уртасы җитеп, хәлдән тайгач, берничә тиен түләп, «Колхозчылар йорты»на барып ава, шунда үлепләр йоклый, базар тирәсендә әчегән катык һәм ипи катысы белән тамак туклык итеп, тагын да сәүдәсенә керешә. Кайбер кичләрдә шайка башлыклары аның акчасын талыйлар, кайвакыт тапкан малын артык өзешмичә, аларга үзе үк бирә иде. Бермәлне, килүенә урынын икенче бер ят малай биләгән. Нindидер сары чебеш кыяфәттәге шырт ак чәчле, ак йөзле, ак керфекле малай. Кулында шул ук кара итек мае, шул ук шүткәсе. «Кит минем урыннан!» Китми бу, тәре. Үзе татарча да белми. Русчасы да әллә нинди әкәмәт. Сугышып китәләр.Сыра сатучылар аларны: «Кем җиңә? Кем җиңә?» — дип үсендереп тора.

Рәшид аны яхшы гына тәпәләп ыргытты. Малайның танавыннан кан китте. Караса, бер читтә теге кызыкай аңа карап тора. Оят булып китте. Рәшид сугышуыннан туктады. Ул кызгануыннан яңа танышын кочаклап алды һәм, гафу үтенә-үтенә, кесәсеннән кульъяулык урынына йөрткән чиста чүпрәген бирде. Танауларын сөртте, битләрен юдырды. Малай ерак Крәкәүдән килгән Адәм Крачковский дигән Пүльшә татары икән. Шушы тукмаш, Рәшид биргән шушы чиста чүпрәк аларны дуслаштырды да куйды. Алар, Уралдан һәм Пүльшәдән килгән ике татар баласы, Идел Татарстанының Тукай урамында рәттән басып итек чистарта һәм тәмәке сата, төннәрен ночлежкаларга барып куна башлады. Исән микән әле аның Адәм дусты? Үзенең йөзьеллык гомергә якынлашкан язмышыннан чыгып, Рәшид белә: дошманлашып башланган дуслык нык була, төчеләнеп башланган ахирилек тиз юкка чыга. Әйе, тормышы урамда үтүенә карамастан, Рәшид урам гадәтләреннән бозылмады, атна саен мунча керә алмаса да, бетләмәде, корчаңгыламады, үзен пөхтә тотты. Хәзер уйлый-уйлый да аптырап куя: мондый пөхтәлек аңа халыкның кайсы китапларыннан, катламнарыннан, аның тарихының нинди көчләре, кайсы гасырларыннан килгән иде икән? Шунысы кызык: ул үзенең эш «ноктасын» мотлак Тукай урамындагы өчкатлы йорт каршыннанрак биләргә тырыша, ни өчен дигәндә — куанычы ни тора! — йортның икенче катындагы тәрәзәдән аны еш кына үз яшендәгерәк бер кыз бала күзәткәндәй итә. Эш көнен Рәшид шул тәрәзәгә карап башлый һәм шул тәрәзәгә карап тәмамлый. Ул кызчыкны уйлаганда, күңелне нindидер ләззәт биләп ала. Ашаудан да ләззәтлерәк хис. Ул малайга карый, малай аңардан күзен ала, малай аңа карый, кыз аңардан күзен ала. Кайвакыт бу ап-ак йөзле кызкай, кәрҗин тотып, кибеткә дә чыгып кергәли. Күзләре очрашканда, гаепле сыман, карашларын җиргә төшерәләр. Нәрсә булыр икән бу?!

Башкаларга тәмәке сатса да, Рәшид үзе беркайчан да тартмады. Тартып карады каравын. Бәлки өйрәнеп тә киткән булыр иде, бермәлне, кара төндә, өеннән баулары асылынып торган әчке ыштанындагы берәү аның янына: «Туганкай, бер генә фифаруз бир, асылынам!» — дип атылып чыкмасынмы! Тормыш чынбарлыгын тере гамәлләрдә бәяләргә

һәм үтәргә өйрәнгән авыл баласы Рәшид шул мизгелдә кешенең яшел тәмәке-насвайга шулкадәр бәйле булуын яман чир итеп күреп, беркайчан да тартмаска, яшел тәмәке чәйнәмәскә ант итте. Һәм тарта-чәйни башлаган Адәм дустын да туктатты. «Күрдеңме, нинди агу?! — диде ул Адәмгә, ак ыштанлы мескенгә күрсәтеп. — Тәмәке-насвай өчен бу зимагур хәзер ыштанын да сатачак!»

Бәлигъ булмаган килеш бәлигълык мәҗбүриятенә кереп һәм унөч яшендә ата-анасы исән була торып, ата-ана куеныннан чыккан Рәшид иртә, бик иртә өлгерде. Аны теге икенче каттан күзәткән кызга гына түгел, көне буе дистәләгән юан сыйраклы башка кызларга күзе төшә һәм шул ук вакытта аларны тиз генә оныта да иде. Әмма теге якыннан йөзен дә күрмәгән коңгырт кыз гына онытылмый иде.

Унөч яшендә берьялгызы калып, ул шуны аңлады: ятимлек бар, ата-анаң исән булган йорт-җирсезлек бар икән. Бу ике төшенчә берсен-берсе тулыландырмый, киресенчә, ерагайтып, тирәнәйтә, ә вакыт-вакыт, шартына, кичергән мизгеленә карап, берсе икенчесеннән мәгънәлерәк йә мәгънәсезрәк була икән. Ятиме дә, йорт-җирсезе дә ике җире белән уйлый: баш белән һәм җилкә чокыры белән. Баш белән уйлаганга — мәңгелек авырлык һәм бәрәкәтлек юлдаш, җилкә чокыры белән уйлаганга — вакытлы җиңеллек һәм бәрәкәтсезлек. Ятимлектә — синең беркемең дә юк, бары күктәге йолдызлар гына синеке; йорт-җирсезлектә — барысы да синеке, тик кунарга урының гына юк. Ятимлектә син беркем өчен дә җавап бирмисең, ә йорт-җирсезлектә — барысы өчен дә, чөнки син үзең дә, башкалар да әлегә исәннәр. Ятимлекнең дүрт ягы кыйбла, күзәтер җан ияң юк, йорт-җирсезлектә дә дүрт ягың кыйбла, әмма барысы да күзәтәләр...

Ул, йортсызлыкта ятим, ятимлектә йортсыз булып, белемсез-нисез белем иясе, шаһәдәтсез килеш галимлеккә иреште. Чит-ят шәһәрләрнең күпер асларыннан шуышып, эстакадалары аша сикереп үтеп, салкын җилбураннарда ач байрак булып чайкалып, балет хәрәкәтләрен башкарды, моң-музыканың вокал, сольфеджио нечкәлекләрен кан тамырларыннан үткәрде, тормышның киләчәктә кирәк булачак югары математикаларын, тригонометрия-геометрияләрен бүгеннән үк зиһененә бикләп куйды...

И-һи-һи-һи, нәрсәләр генә күрмәде, кичермәде унөч яшьлек Гали-батыр!..

Озак та үтми аларның компаниясе өч Гали-батырга әйләнде. Рәшид Мусин дигән бик яхшы малай аларга иш булып, дуслашты, катык-сөт сатты, белеме булгач, буш вакытында биш тиен хакына башкаларга — төрмәләргә һәм армияләргә хатлар язды. Акыллы хәйләкәр Рәшид хатларының сүзләре бер үк, ул аларны шартлатып ятлаган иде. Яңа Рәшид дусларының ата-аналары бик яхшы кешеләр иде. Озакламый Адәм белән икәү аларның җылы абзарына яшәргә күчте. Өй җылы, абзар җылы, янда гына, бүрәнә аша сыер һәм бозау күши. Мал агы акмаса да, боларга да тамгалый. Яңа дустының күкрәкләре бидрә кебек җимерелеп төшкән тутасы бар иде. Инде җилеге җитлеккән Рәшид бу түткинең күкрәге чынлап та үзенеке микән, ул аңа мамык тутырмый микән, дип үтешләй-сүтешләй, имеш, ялгыш, терсәге белән кагылгалап та ала иде...

1933 елның кышында алар, ике Рәшид һәм Адәм, чак-чак кына төрмәгә эләкми калдылар. Идел бозы аша ун чакрымлап юл үтеп, Югары Ослан авылына бардылар һәм җиз табактай пеләшенең астында бер учма бөдрәсе калган алып-сатардан очсыз хакка 50шәр кап папирос сатып алдылар. Бишмәтләрен эчтән ярып, капларны шунда тутырдылар. Иделнең бирге ягына чыккач, таш келәтләр янында тышка чыгып маташканда сакчы күреп калып, Рәшид Рәшидовны эләктереп алды, теге Рәшид белән Адәм качып котылды. Келәтләр НКВДныкы булып чыкты. Аны махсус конвой белән

Черек Күлгә алып киттеләр. Беренче эш итеп бишмәт әчлеген умырып, папиросларны бушаттылар. Ике тәүлек буе сорау алдылар. Аннан, бергә сату иткән дусларын эләктерү ниятендә, тикшерүчеләр аны ике тәүлек буе Печән Базарына йөртте. Барыбер сатмады Рәшид дусларын. Ул аларны күрсә дә күрмәячәк иде... Каян килгән бу сабырлык? Патша сарайларының кайсы Царское Селоларында тәрбияләнгән мондый кеше хакын хак иткән аксөяк-аристократлык?

Уналты яше белән барган Рәшидкә һәм Адәмгә Казан Рәшиде укырга киңәш итте. Үзе, инде икенче бер урта мәктәптә сигезенчегә җыенган үсмер, малайларга Кабан күле артындагы икекатлы башлангыч татар мәктәбен алып барып та күрсәтте. Уку!.. Белем!.. Рәшиднең куанычының чиге юк иде. Яше ягыннан җиденчедә укырга тиеш булса да, белеме ягыннан өченче сыйныфтан артыкка тартмый иде. Җитмәсә, аның белән үзеннән наданрак Адәм дә укыячак. Ничек кенә булмасын, аларны өченчегә алдылар. Һәм тырыш кыз балалар белән утырттылар. Тере парталар артында тере хәрефләр белән эш итү никадәр куаныч иде. Әмма Рәшид өчен хәрефләр бик тере түгел, ярымүлек иде, чөнки мәктәп гарәптән латинга күчкән, ә егетебез бу яктан туң бүкән иде. Ничек кенә булмасын, тырышты-тырмашты, бер елда икееллык программаны үзләштереп, дүртенчегә күчте. Ә менә Адәмне икенче елга утыртып калдырдылар. Дусты моңа да шат иде. Һич онытмас: уку елының азагында алар Адәм белән Тукайның «Пар ат»ын сыйныфта кычкырып укыйлар иде. Рәшид:

— Әйтә иртәнге намазга бик матур моңлы азан!..

Адәм:

— И Казан! Дәртле Казан! Моңлы Казан! Нурлы Казан!

Рәшид:

— Мондадыр безнең бабайлар түрләре, почмаклары!..

Адәм:

— Мондадыр дәртле күңелнең хурлары, оҗмахлары!..

Әгәр Кабан арты мәктәбенә сабакка килмәсә, ул үзен Казанга китергән шушы «И Казан! Дәртле Казан!» дигән шигырьне бөек татар шагыйре Тукай язганын бәлки белми дә калган булыр иде. Ул моны Тукай исемен йөрткән урамда итек чистартып һәм тәмәке сатып утырганда белә алмады бит. Менә гыйлем дигәнең нишләтә!.. Бер генә юл шигырь, ә шушы бер юлның кеше язмышында тоткан урыны нинди!.. Таңнар калырлык!.. Тагын да берәр халык әдәбиятында бар микән шундый галәми мәгънәгә ия булган шигъри юл?! Бихисап нәрсәләр белде ул мәктәптә!.. Аны Иске Кодаштан бирегә китергән Тукай абзасының үлүенә быел егерме дүрт ел, татарның икенче бөек шагыйре Һади Такташның үлүенә җиде ел булган икән. Ә менә, соңыннан ачыкланунча, өченче — аның язмышында зур әһәмияткә ия булачак, киләчәктә аны яклап органнарга мең хат язачак бөек шагыйрь Муса Җәлил Казанда исән-сау килеш, Рәшидләр белән янәшәдә генә яшәп, эшләп һәм әдәби үрләр яулап яткан икән. Кем уйлаган!..

Рәшиднең яшьтән үк күңеле нечкә иде. Әгәр укыса, бәлки ул да Тукай, Такташ, Җәлил абыйлары кебек шагыйрь булыр иде. Икенче елны ул Нариман урамындагы җидееллык мәктәпкә күчте. Өч ел буена бер тегендә, бер монда кунып, бер ач килеш какланып, бер тук килеш сакланып, җидееллык белем турында шаһәдәтнамә алды. Шушы ятим-беспризорник. Ничек? Кем ярдәме белән? Мөмкинме? Шулай була аламы? Кемнәр сыза бу маңгайдагы язмыш сызыкларын? Җәлилне яклап мең, ташландык Химки бистәсенең күпмилләтле халкын яклап мең, борынгыдан бертуган, игезәк татар һәм башкорт халыкларының тарихи дуслыгын сакларга чакырып язган тагын да мең хатларга нигез шушы чокырлы-чакырлы Казан урамнарының ярымҗимерек мәктәпләрендә салынмаганмы?

Яңа дусты — Казан егете Әхмәт Биккиниев елга техникумында укый иде. Рәшиднең дә аның кебек алтын сыргалы китель киеп, Идел өстендә акчарлактай корабларда очасы килде. Тик анда сигез сыйныфтан соң гына алалар иде. Ул латинча «VII»гә бер таяк өстәп, «VIII»гә төзәтте дә, биш имтиханын уңышлы тапшырып, елга техникумы студенты булып китте. Елмайса, елмая бит бәхет дигәнең!..

Беренче курсны тәмамлагач, немец теленнән тәрҗемәчеләр әзерләү курсларында укыды. Яхшы гына сөйләшә дә башлагач, бәла аяк астыннан килеп чыкты: Татарстан яңалифтән кирилл язмасына күчерелде. Бу русның гарәп имлясына күчүе сыманрак гамәлгә тиң иде. Җөмһүрияттә кирилл әлифбасына каршы чуалышлар да булып алды. Латинга каршы кайчандыр «сиксән ике»*ләр күтәрелгән булса, кириллга каршылыгын барлык халык диярлек сиздерде. Елга техникумында кириллга каршы чыккан рус теле укытучысы Галиевне кыйнату җыелышында Рәшид Рәшидов аны яклап чыгыш ясады һәм Габдулла Тукай, Һади Такташ әсәрләрен беркайчан да кеше башы кисә торган кириллицада укымаячакмын, дип белдерде, ант та итте. Котырган большевикларга бу җитә калды, «пролетар чыгышлы беспризорник»ның яшерен йөзле мулла баласы икәнен шундук искә төшерделәр һәм техникумнан куып та чыгардылар.

Авыр көннәр килде. Бер үк вакытта тормыш әлеге сәясәткә кермәгән саф күңелле авыл баласына мәрхәмәтле дә иде. Язмыш гүя аны, күзен бәйләгән сабыйны, бәлале ишектән кертеп, бәласез ишектән чыгара торган булды. Нинди сыйфатлары өчен ярата һәм кодрәте белән коткара инде аны Ходай Тәгалә? Татар баласында ата-анасы «намус» дигән төшенчәне беренчел сыйфат итеп тәрбияләгәне өченме? Һәр эшне җиренә җиткереп эшләгәне, ярдәмчеллеге, ачыклыгы, күкрәк һәм беләк көченең бердәмлеге өченме? Унөч яшьлек баланы нигә саклап килде? Сынаулар аша үткәреп чыныктырды гына. Еллар аша аңлады: ул кешегә бер авыр сүз әйтмәгән ата-анасыннан, туганнарыннан, авылдашларыннан, табигатеннән һәм халкыннан уңды.

Менә шушы сыйфатлар нәтиҗәсендә, күрәсең, очраклы гына танышып киткән һәм анысын-монысын белеп өлгермәгән Борындыков дигән журналист абзый аны үз җаваплылыгы астында зур гына хезмәт хакы белән Камил Якуб исемендәге китап комбинатына корректор итеп урнаштырды. Кискен киләчәкне сизенеп, аңа әзер булу өчен, ул хисапчылар, аннан каучук чыгара торган СК-4 заводында аппаратчылар курсларын тәмамлады. Скрипка буенча дәресләр алды. Егерме яше тулып, Совет Конституциясе нигезендә, СССР гражданины дигән паспортлы да булды. Эш хакы яхшы иде. Паспорт алу уңаеннан, үзенә бәйрәм ясарга теләп, Югары Осланнан кабартма пешерергә әче камыр алып кайтты. Кайтуына камыры, токчаеннан ташып чыгып, идәнгә төште һәм — һич арттырмыйча әйтә! — көчен кая куярга белмәгәндәй бии башлады. Эчендә җаны булса, кеше генә түгел, тере камыр да бии башлый икән!.. Әмма кара сакалы кая барса да артыннан калмады. Борындыков абзыйны «халык дошманы» буларак этап белән озаттылар. Күп тә үтми Рәшидне китап комбинатының кадрлар бүлегенә чакыртып, эшеннән чыгарылуын хәбәр иттеләр.

Ул, озакламый хәрби хезмәткә чакырылачак егет, берничә айга туган ягына кайтып китте.

V

Репрессияләнгән мулла улы буларак, аны армиянең иң түбән баскычы

* «Сиксән ике»ләр хаты. 1927 елда гарәптән латинга күчүгә каршы 82 татар зыялысы кул куйган бу хат өчен ВКП/б/ Үзәк Комитеты шундый җәзалар куллана: әүвәлдә имзаларыннан баш тартып, хат яздыралар, соңыннан, имзаларыннан баш тартмаганнар белән беррәттән, баш тартканнар да җәзалана.

— стройбатка гына алдылар һәм Ерак Көнчыгышның табигате ягыннан аеруча кырыс «Биробиджан почмагы»на җибәрделәр. Кискен континенталь һава шартлары: кышын, илле биш градуска кадәр төшкән төнге суыкларда колагыңны туңдырсаң, көндезге эсседә аякларыңны пешерүең мөмкин. Кайвакыт мунча пары сыман кайнар һава сине пешендерә, бармак башы кадәр черкиләр талый, тәннең кычытуыннан агач башларына үрмәлисе килә. Күз кабаклары кабара, черки дә танк кебек пәһлеван күренә башлый... Кигән киемең нинди бит әле: бер кат шинель, башыңда ач йолдызлы будёновка, аягыңда бер кат чолгау белән дуңгыз тиресеннән тегелгән «скороход»лар... Рәшидне башкалардан чагыштырмача белемле булуы коткара: агитатор итеп куйдылар. Газета дигәнең җитәрлек. Командирлары күрмәгәндә, аларны тәненә һәм аякларына урап, салкыннан котыла. Шулай да ничәмә-ничә тапкыр аягын-кулын туңдырды.

Амур — кытайчадан «кара аждаһа» елгасы дигән сүз. Чик саклаудан тыш, аларның батальоны японнарның борын төбендә яшерен объектлар төзи иде. Ашатулары ташка үлчим. Ашлары да җамаяк төбен каплар-капламас. Бермәлне кичке ашка дуңгыз каешы чәйнәрлек ачу белән кайтсалар, Саранскидан, ашханәдә кизү торган рядовой Липатов 36 кешелек ашны берүзе ашаган да бетергән.

Хезмәтенең беренче көннәрендә Рәшид ашханәгә ат белән су ташыды. Бер бик тә ачыккан чагында, пешекче булып хезмәт иткән якташыннан ашарга берәр нәрсә хәстәрләвен үтенгән иде. Киләсе килгәнеңдә чан эченә күз ташларсың, дигән иде тегесе. Караса, анда, салкын су эчендә, муенсыз аккош кебек, зур гына май кисәге йөзеп йөри. Үрелеп алам дигәндә, аягы таеп китеп, чан эченә капланды да төште. Шулчак комиссар килеп керде. Рәшидне чаннан тартып чыгардылар. Әгәр комиссар майны күргән булса, урыны бер атналык гауптвахтада иде.

Манчжур төннәре итек мае кебек куе кара, менә хәзер, менә хәзер сугыш башлана дип киеренкелек сакланган чик буенда каян нинди һөҗүм булачагын тәгаен белә алмыйсың. Бу як табигатенә бүре кебек ияләшкән япон самурайлары, көн саен, сәгать саен диярлек чикне бозып, безнең солдатларны песи баласы кебек култыкларына гына кыстырып китәләр. Еш кына корбаннарының танау-колакларын кисеп алып, кире үзебезгә җибәрәләр. Алар бигрәк тә комсомолларга карата кансыз — күкәйләрен кисеп алалар...

1941 елның җәендә Рәшид, хезмәтен тәмамлап, Казанга кайтырга җыенды. Фанер чумадан, очсызлы гына япон фотоаппараты, туган-тумачаларына бүләклек әйбер-сәйбер алды. Әмма нәкъ демобилизация алдыннан, 1941 елның 22 июне таңында Ватан сугышы башланды...

Август аенда аларның полкын тулы маскировка астында Биробиджаннан Амур ярлары буйлап совет-япон чигенә күчерделәр. 15 чакрымга сузылып барып, полк кырык чакрымлык чикне каплады. Ягылмаган землянкаларда катып үләрлек суык. Тирә-якта чикләвек чыбыгыннан башка бернинди төзелеш кирәк-ярагы юк. Әмма авыл кешесенең чыдамлылыгын һәм хәйләкәр акылын үзендә туплаган Рәшид монда да юл тапты. Янәшәдәге авыр артиллерия полкына зур калай канистрларда машина мае китерәләр, артиллеристлар аны ташлыйлар. Рәшид шул канистрлардан барлык полкка тимер мич, америкaн консервалардан төтенне тышка чыгара торган үткәргеч ясарга өйрәтте. Землянкалар май кебек җылынды. Мичтәге утны сүндермәс өчен, һәр землянкада кизү куелды. Рус солдаты балтадан итле аш пешерсә, татар солдаты калай консервадан голланд миче ясады, дип сөйләделәр армиядә аның турында. Ерак Көнчыгыш хәрби округы командующиеның рәхмәт кәгазен тапшырдылар. Мулла баласына үз гомерендә беренче «орден» иде ул. На-

чар ашату аркасына 172 сантиметрлы гәүдәсе нибары 46 килога калды. Кан йөреше сүлпәнәйде, тавык күзе булып, карашы томаланды…

Әмма, ничек кенә авыр булмасын, Амур буйларындагы хезмәт бөек бер романтик чор кебек хәтерендә калды. Аларны ачлыктан авырлыгы утызар килога җитә торган ак балык коткарды. Планктон балыгы. Үләнне үз авырлыгыннан ике-өч тапкыр күбрәк ашый. Әнә ул, төтен белән тулган сигез кешелек землянка, сәвитләрнең калай савытларында шул ак балык. Аны японнар да ашый. Әмма балык ашаганнан соң, сәвитләр — японнарны, японнар сәвитләрне ашый. Балыклар гына бер-берсенә тими. Әнә, барлык Амур, Амурга койган Сунгри ярларын алтын нурларга манып, кояш күтәрелә… Тере табигать шулчакта моң төялгән нота дәфтәренә әверелә. Скрипкаңны ал да Казаныңны, Печән базары тирәләрен искә төшереп сыздырып җибәр. «И Казан!.. Дәртле Казан!.. Нурлы Казан!.. Моңлы Казан!..» Һәм син көтмәгәндә, куанычыңнан пышылдыйсың: мондый матур тел биргәнең өчен Аллаһыма рәхмәт!..

1942 елның көзендә Рәшид белән лейтенант Байковны, Амур ярында окоп казып, бер атна буе японнарны күзәтеп ятарга җибәрделәр. Стереотруба аша дошманның һәр адымын махсус дәфтәргә яза бардылар. Әсирләр, аеруча комсомоллар белән никадәр кансыз кыланганнарын белгән егетләр, саклык күрсәтеп, комсомол билетларын каен астындагы комга күмеп куйдылар. Иртәгә китәбез дигән көнне Ерак Көнчыгышта гына була торган коймя яңгыр яуды. Бар дөнья гү килеп акты. Карасалар, аларның билетлары агып киткән. Көлсәң — көл, еласаң — ела. Хәзер көлке тоелса да, теге заман, аеруча көн-төн Көнбатышка, фронтка китәргә омтылган егетләр өчен кара кайгы иде мондый югалту. Ярый, армия политидарәсе кисәтү белән чикләнде. Сугыштан соң Байков комсомол билетын Ленинградта, Рәшид исә Казанда яңадан алды. Көнбатыш фронтка сорап язган рапортлары командирларның: «Монда да фронттан ким түгел!» дигән ярпач инкарьгә тап булып челпәрәмә килә иде. 1942 елның ноябрендә 44 градус суыкта постта торганда, ул ике аягын да туңдырды. Санинструктор аны кар белән уып кына коткара алмады. Ике ай госпитальдә ятып чыкканнан соң, ниһаять, аларны, Сталинград фронтына ашкынучыларны, аерым часть итеп туплап, юлга алып чыктылар. Тегендәге тупыйкта бер, биредәге тупыйкта ике тәүлек каклап, өшетеп, аякларын яңадан туңдырып бетергәннән соң, барлык тәне гөбе кебек шешкән, чуан баскан Рәшидне Себернең нindидер бер Завитая дигән йолкыш стансасында төшереп калдырдылар. Һәм ул тагын да ике ай ярым чамасы госпитальдә дәваланды.

Японнарны җиңгәннән соң, аларның полкын, япон әсирләрен саклар өчен, Читадан ерак булмаган Антиповка дигән салага күчерделәр. Чита ул чакта япон әсирләре белән тулган булып, монда рус халкы бөтенләй дә яшәмидер дигән фикер уята иде. Рәшид әсирләр «әсире» булып, винтовка күтәреп сакта торуны үзе өчен түбәнлек санаганлыктан, аннан котылырга тырышты. Һәм ул Тын океан флотына кергән яр буе полкына күчүгә иреште. Шуннан хәрби хезмәт белән хушлашты да.

1946 елның 3 июне иде.

Менә, ниһаять, инде егерме беренче гасырга кереп, 2012 елда, ике дә уйламыйча, аны «Бөек Ватан сугышында катнашучы», «Бөек Ватан сугышы ветераны» дип атаганда, эченнән генә елмаеп куя: юк, аны бу сугышта «катнашучы» дип тә, «ветеран» дип тә атарга ашыкмадылар. Хәер, үзләрен сыек шулпада, боз-яңгырда, черки-кигәвеннән талатып, ил чиген саклаганда, көр тавышлы командирлар аларга: «Көнчыгыш та Көнбатыштагы фронттан ким түгел!» — дип акырса да, Брежнев хакимлек иткән чорда фронтовикларны төркемнәргә бүлеп, «Ерак Көнчыгыш» фронтовикла-

рын ул чакта башак җыеп йөргән 1931 елгы малайлар рәтенә куеп кимсеткәннән соң, аңа, һаман да шул үлемсез мулла баласына, бары тик 2000 елда — 55 елдан соң гына «Бөек Ватан сугышында катнашучы» таныклыгын бирделәр.

Һаман да шул бер сорау: кем бирергә тиеш иде мондый шаһәдәтнамәне? Аллаһ үзе түгелме? Маршаллардан калган сукыр кәнсәләрме? Ә бит халык бар, холык бар!.. Ничек яратыла ул халык һәм халык баласындагы холык? Кайдан ул? Җирдәнме, җилдәнме? Уйданмы, суданмы? Каннанмы, җаннанмы? Каян килгән бу кадәр көч мәктәптә юньлерәтле әлифбасын да өйрәнеп өлгермәгән сабыйга? Нинди чыганаклардан чишмә булып бәреп чыгып, җан курайларында өзләгән бу сөекле гамьнәр? Кан тамырларында ничәмә-ничә гасырлар тупланган ком-ташны нинди сихри моңнар эретә һәм, бозларны агызган язгы ташу кебек, агызып алып китә алган?

VI

Менә ул беренче тапкыр унөч яшендә күргән Казан вокзалында басып тора. Биредә аны беркем дә, бернәрсә дә тотмый, ул бирегә, Мәскәүнең Химки бистәсендә яшәп яткан Зәки абыйсына үтеп барышлый, сабыйчак хатирәләрен яңарту нияте белән генә кагылырга булган иде. Ул иртәгә үк Мәскәүгә юл алачак. Әмма... әмма... кем уйлаган!.. Чокырны сикереп чыкмастан «Һоп!» димә икән шул. Ул үзенең тәмәке саткан һәм итек чистарткан урамнар почмагын күрергә баргач, биредә, кеше боткасында, медицина институтының өченче курс студенты Разия Байгильдина дигән кыз белән танышырга насыйп итте. Алар беренче күрүдән үк бер-берсен ошатты. Мәхәббәт язгы ташу кебек күкрәп килде. Гүя алар әллә кайчаннан гашыйклар иде. Разия чын татар йөзле, чын татар күзле, чын татар назиясе иде. Икене генә кунам, дигән егет Казанда бер атнага тоткарланды, Разия туташны көн саен киного чакыра һәм озатып куя. Шунысы гаҗәп: ул кызны электән кайдадыр күргән кебек иде. Тагын да гаҗәбе шул: бу фикер Разияга да килә икән. Сөйләшә, хәтердә актарына торгач, очына барып чыктылар: әйе, моннан унбиш ел элек Тукай урамындагы йортның икенче катыннан аны күзәткән кыз нәкъ менә шушы чибәрләр чибәре Разия, ә менә аларның йортлары каршында аяк киемнәре чистарткан, тәмәке саткан чакта, тәрәзәдән чагылып киткән шушы кызкайга карашын ташлаштырган «беспризорник» малай кичә генә армиядән кайтып төшкән гвардия старшинасы Рәшид Рәшидов үзе булып чыга икән ләбаса!..

Могҗизалар, бер килсә, килә бит ул. Берничә көннән Разияларга дус кызы керде. Аны Рәшид шундук танып алды. Анысы кайчандыр Елга техникумында бер парта артында утырган Хәлимә икән!

Рәшид Казаннан Мәскәүгә кош канатларында очты. Аның сөйгән кызы, бүген-иртәгә табиб булачак Разиясы бар!.. Бу хакта бер ата, икенче анадан булган Зәки агасына да сөйләде. Өч көн синдә булам да Казанга кайтып китәм, диде. Агасы шунда ук:

— Казанда эш табу читенрәк булыр... — дип кодаларга да тотынды. — Кайтып китмә. Өйлән...

— Кызык син, абзый! — дип шып туктатты Рәшид. — Ничек итеп? Өйләнгәнче эш табарга, яшәр почмак табарга кирәк. Синең кечкенә фатирыңа икенче гаилә алып кайтмам бит инде...

— Сугыш планны үзе сызып күрсәтә ул! — диде агасы Наполеон сүзләрен кабатлап. — Яхшы кызны аны вакытында пичәтләп куярга кирәк. Син, туган, Химкида кал, — диде агасы. — Әлегә бездә торып торырсың. Аннан, эшкә урнашып, торыр урын да тапкач, кәләшеңне алып килерсең. Эш әзлик...

Көтмәгәндә, ул Мәскәү халкын дер селкетеп торган оешма — МУРга оперуполномоченный булып урнашты. Аңа таныклыкны рус телле кешеләр һәм, имеш, оператив орган-

нар өчен әйтелеше авыр булган Рәшид Хәлимович Рәшидовтан баш тартып, Евгений Харитонович Рашидов исеме белән бирергә булдылар. Рәшид каршы төште. Бу инде беренче генә очрак түгел иде. Аны кем генә итәргә тырышмадылар: Роман Харламович, Рудольф Хромович һәм башкалар, һәм башкалар...

— Бездә, татарда, ата-ана кушкан исемне алыштыру зур гөнаһ, — диде ул кадровикка. — Сезнең үзегезгә Георгий Николаевич урынына Галимҗан Нигъмәтҗанович дип таныклык бирсәләр, ничек карар идегез?..

— Да, так сказать, вы, пожалуй, правы, однако, это, так сказать... — дип мыгырданды теге томаулы борынын бармагы белән чокып. — Конечно, слава богу, хорошо, посоветуемся...

Рәшид үзе — оператив хезмәткәр Рәшид Хәлим улы Рәшидов булып калды. МУРдагы хезмәт аның өчен сугышның дәвамы иде. Көн белән төн кушылды. Фатир басулар. Ялган документлы сатлыкҗаннар, зиначылар, яшерен фәхешханәләр, караклар, кеше үтерүчеләр, эчке һәм тышкы агентура — нәрсә генә юк!

1949 елда, имеш, «ялгыш ычкындырылган сүз өчен» дигән гаеп табып, аны МУРдан урамга чыгарып ыргыттылар. Төбендә, сизенүенчә, һаман да шул бер сәбәп — мулла улы булуы ята иде. Кадровик «посоветуемся» дигән иде бит. «Киңәшкәннәрдер». Рәхмәт, Химкидагы иң зур предприятие «Энергомаш»ның директор урынбасары Хәлил Еникеев аны йортлар идарәсе мөдире итеп урнаштырды. Аның өчен язмышының иң кызыклы, иң мәгънәле чоры башланды. Ул үз канаты астына кырык мең кеше яшәгән ике йөзгә якын ярымҗимерек баракны кабул итеп алды. Аларны, Азиядә яшәсәләр дә, Европадагыча яктыртырга, җылытырга, юындырырга, хәтта ашатырга һәм киендерергә кирәк иде. Әмма әүвәлдә үзенең шәхси тормышын хәл итәсе бар иде. Разия Химкига килде. Беренче эш итеп Разия белән язылыштылар һәм бер бүлмәле фатир да алдылар. Моңа кадәр кашы җимерелгән бандит кебек күз алдында торган Химки, Разиясы килгәннән соң, оҗмах почмагына әйләнде. Ерак Көнчыгышта юкка гына аякларын туңдыра-туңдыра сакта тормаган!..

Гамәлдә «йортлар идарәсенең» берниндн дә «йортлары» юк, бары тик сасы юынтык суларында антисанитар гөмбәләр чәчкә аткан күлләре белән «Мәскәү-Идел» каналын төзегәндә салынган җимерек бараклары гына бар иде шул. Шунда ук үлеп бетмәгән кечкенә авыллар, анда атлар, сыерлар — әмма көтү чыкмый, алар, җәен иректә йөреп, үлән чемчи, кышын, әзер печәне булса, кибәннән кымтый... Андагы капкорсаклы буаз бияләр — эчләрендә ятып йокларлык!.. Кемдер чирләсә, кемнедер тулгак тота башласа, «ашыгыч ярдәм»гә ышаныч бары шул атка гына; һәр оешманың үз аты, ат абзасы, арбасы, сулы йә сусыз коргаксыган мичкәсе бар; атлар татар кулында, ат караучылар да татарлар; урам себерүчедворникларны, таксист-«барабыз»ларны инде әйтәсе дә юк: гыж безнең кавем; һич онытмас Рәшидов: әнә, җәенкышын, көзен-язын, вакытына карап, сәләмәсен дә аристократларча купшы итеп киенеп, һәр ярыктан саргаеп таң сызылу белән, баракларның подвалларыннан градусник төрепкәсеннән чыккан терекөмеш кебек тәгәрәп, кулларына себерке, фанер көрәк тоткан империя санитарлары — дворник татарлар дөньяны чүп-чардан тазартырга чыга: иң алдан ике эре терекөмеш тамчысы — ата белән ана, артларыннан кечерәк себерке-көрәк күтәргән вак терекөмеш тамчылары — балалары килә. Менә аларга йортлар мөдире Рәшид Рәшидов тә кушыла, кушыла гына түгел, алдан төшеп иртә һәм үзләрен нәҗесләгән кара көчләрнең инде үзләрен нәҗестән тазарта, пакьли, себерә, көри генә түгел, империя пычрагын телләре белән ялый, кершән яга, иннек сөртә һәм иртәгәсе таңга кадәр янә дә шул терекөмеш тамчылары булып подвалларга кереп югала...

Беркөнне шулай «Новострой»ның баш инженеры Некрасов белән тикшерүгә чыктылар. Яңа йортларда батареялар ага, пар чыга, җылы тиешенчә түгел. Линияне эшләтсәләр, бүлмәләр — мунчага, туктатсалар, суыткычка әйләнә. Котельнаялар буйлап киттеләр. Кочегарлар дөм исерек. Кертмиләр:

— Монда чит кешегә керү тыелган.

— Без тикшерүчеләр, — ди Некрасов. — Югары басымлы казаннар янында эчәргә ярамый.

— Ә кайда күрдең син безнең котельнаяларда түбән басым? — ди кочегар. — Бирермен мин сиңа түбән басымны!

Һәм кирпеч күтәреп, Некрасовка ташланды. Алар икесе бетон болгата торган лаканга егылып төште...

Менә шушындый шартларда Иске Химкиның «Шанхай»лары урынында Мир һәм Ленинград проспектлары калкып чыкты. Үзәк базар һәм үзәк шифаханә Мәскәүнең үрнәк төзелешләренә әйләнде. Берәүнең язмышы — башкалар балкышы. Кеше өчен кайгырту, ул чын күңелдән булган хәлдә, күпләргә бәхет өләшә. Бермәлне 301 нче завод директоры Колычёв шалтырата: «Рәшидов, заводка кирәкле белгеч — яшь кыз килде. Берничә көн генә синдә яшәп торсын?» Әгәр син гаиләң белән нибары унбиш квадрат метрлы бүлмәдә яшәп азаплансаң да, бергә сыешып, тыныч яшәү үрнәген оештыра торган кеше бурычын үтисең икән, бу тәкъдимне кире кагып буламы? Юк, керттеләр алар Разиясы белән Вера Смирнованы үз бүлмәләренә яшәргә. Ике айга якын, гомумторакта почмак алганчы яшәде ул аларда. Кайвакыт аларны кунакка чакыралар һәм бөтенләй чит кешеләрнең балалары аңа: «Дядя Рашид, мы знаем, что ты нам родной человек, но не знаем, как?» — дип мөрәҗәгать итә иде...

Бу кадәр хезмәтен югары бәяләп, кала советы аңа өч бүлмәле фатир бирде. Алмады аны Рәшидов. Күпбалалы гаиләгә тапшырды. Үзе Чкалов урамындагы йортның беренче каттагы ике бүлмәле фатирында калды. Бүген дә шунда яшәп ята. Чкалов дигәннән. Ул утызынчы елларда Химкида авиаконструктор Лавочкин җитәкчелек иткән авиация заводлары берләшмәсенең очучы-сынаучысы булып эшли. Мондый очракларда «Көлсәң — көл, еласаң — ела», дигәннәре шулдыр инде. Бер бәйрәм тантанасында шәһәр халкы үзенә тудырган уңайлыклары өчен аның, Рәшидовның, әле тере кешенең, шәһәр бакчасында скульптур сынын кую тәкъдимен күтәрде. Рәшидов үз чиратында миңа Валерий Чкаловтан соң уңайлырак булыр, дип шаяртты һәм әүвәлдә һәйкәлне Чкаловка куярга, дип, һәйкәл темасын куертып җибәрде. Башлангычны бар шәһәр күтәреп алды. Һәм һәйкәлне куйдылар да. Әмма моннан ике ел элек ниндидер вандаллар аны җимерде. Рәшидов һәйкәлне пенсия акчасы хисабына төзәттерде, үзе үк әлүмин тузаны белән буяды, әмма карт булганлыктан, һәйкәлнең баш түбәсенә үк менеп җитә алмады. Аптырагач, ярдәм сорап, Чкаловның улына мөрәҗәгать итте. «Властьларга кирәкмәгән һәйкәл миңа кирәкми, мин әтине болай да яратам, — дип җавап бирде кече Чкалов. — Һәйкәл буяп, буяуга буялып йөрисем килми». Барыбер кеше яллап булса да буятты аны Рәшидов.

Гаилә белән балалар — синең, нәселең, милләтең байлыгы гына түгел, күпмилләтле дәүләтең байлыгы. Гаиләң никадәр нык һәм бәхетле булса, дәүләтең дә нык һәм бәхетле була. Алар сөйгәне Разия белән ике бик яхшы бала — Наил һәм Әнвәрне тәрбияләп үстерде. Наиле — табиб, фән кандидаты, хатыны да табиб, ике бала үстерәләр. Бала үстерүнең никадәр нечкәлекләре бар! Сабырлык кирәк! Наиленең сабый чагында теле тотлыга, ә француз теле укытучысы аның тотлыгуыннан көлә, баланы елатып, гел «икеле» куя иде. Рәшид мәктәпкә китте. Баланы тавышсыз-тынсыз икенче укытучыга күчерде. Сабый гүя канатланып

китте, «бишле»гә укый башлады. Аның төзек француз телен үрнәк итеп куялар иде. Ә менә бәләкәй улы, искиткеч сагышлы һәм сагынычлы кеше, холкы-фигыле белән үзенә охшаган, Иске Кудаш баласы иде, мәрхүм. Ниндидер аларга билгесез сәбәп белән, югары белем алудан баш тартты. Институтыннан кайтты һәм: «Бүтән бармыйм!» — диде. Синең кебек «коммуналь коммунист» булам дип, теплотехникка укыды, үз эшенең остасы булып танылды. Ике баласы калды.

Рәшид тартылып куйды. Нигә, Әнвәре мәрхүм дә булдымыни әле? Әйе, шулай шул. Менә ничек бит. Урыннары оҗмахта булсын улыкаеның. Татар өчен янды ул. Турыдан-туры янды. Хезмәтен дә әтисе юлыннан сайлаган иде. Аның белән нәкъ теге Смоленскиның «Сосновый Бор» ял йортында үзе белән булган хәл кабатланды кебек.

1999 елның декабрендә сиксән яше уңаеннан улы Әнвәр белән «Войков» метро тукталышындагы «Варшава» кинотеатрына эстрада концертына бардылар. Зал шыплап тулган. Менә шунда ул, милләтчелекнең нәрсә икәнен белмәгән, үзе гомере буе һәркемгә саф йөрәген өләшкән Рәшид Хәлим улы Рәшидов, тагын бер тапкыр сырсып чыккан дәүләтчел карагруһлык, бөекмилләтчел шовинизмның иң асыл үрнәкләренең шаһиты булып тетрәнде. Иленең «титул милләте» өчен улыннан оялды. Ул, эченнән янып беткән ветеран, инде бу юлы тышыннан янган булса, улы, яшь кеше, мондый күренеш белән беренче тапкыр очрашкан патриот, эченнән янды. Эш болай булды. Башта артист Сергей Шәкүрев Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәре»ннән өч шигырь укыды. Залның борчылып кыбырсыганы сизелсә дә, урыныннан кузгалмады. Берничә номер аша Гөлсем Хәбибуллина җырлаганда, Рәшид, әсәрләнеп, күзләрен йомып утырды. Залда ниндидер шыбырдау-шапылдау тавышлары яңгырады. Карт игътибар итмәде. Менә татар биюе башланды. Шапылдау тавышлары көчәйде.

— Әти, кара әле! — диде аңа Әнвәр касыгына кагылып.

Рәшид абзый күзен ачса, ышанмый торды: ярты халык залдан чыгып киткән иде.

— Как мероприятие, так диверсия против России! Довели державу! — дип мыгырданып, тагын да байтак кеше урыннарыннан күтәрелде.

Менә кайда ул Холокост!..* Мәскәү интеллигенциясендә Иске Кудаштагы күршеләре Михайла бабай белән Шүрә түтки акыллары да юк иде. Бергә, бер туфракта, бер су эчеп, бер икмәк ашап, гасырлар буе күрше яшәп, бер милләт вәкиленең икенче бер изелгән туганын шулкадәр дә күрә алмавы мөмкин икән бит!..

Кайтканда сөйләшмәделәр. Холкы белән гадел булган, тигезлек сөйгән Әнвәр гарьлегеннән үзен куяр урын таба алмыйча газаплана иде. Аның күзләренең, йөзенең төсе киткән. Ленинград проспектында кайнар су торбасының шартлавын хәбәр иттеләр һәм тизрәк килеп җитүен үтенделәр. Озак та үтми йортлар идарәсенең үзәк пультыннан фаҗигале хәбәр алынды: Мәскәү йортлар хезмәтенең үрнәк белгече, Россия Федерациясенең атказанган коммуналь хезмәткәре Әнвәр Рәшид улы Рәшидов, авария вакытында теплотехник үлчәүләр үткәргәндә, 90 градуслы кайнар суда пешә... Бу фаҗигадә «Варшава» кинотеатрындагы вакыйганың катнашы юк, дип кем әйтер?!

Эш өстендә һәлакәткә очраган белгечне дәвалау өчен, Мәскәү табиблары ярты миллион сорады. Дәвалау алты айга исәпләнгән иде. Палатада бер көн куну гына да алтмыш меңгә барып басмыймы? Тәненең туксан проценты пешкән Әнвәре, җан һәм тән әрнешләрен күтәрә алмыйча, өченче көнне үк тормыш белән хушлашты. Милләтнең бу

* Германия фашизмының яһүдиләргә каршы алып барган геноцид сәясәте.

кадәр фаҗигасен күтәрә алырлык татар киносы кайчан булыр икән?

Озакламый аны авыр кайгыдан рәтләнә алмаган Разиясы да ташлап китте. Аның өчен тормышы ике өлештән торган кебек күренде: беренче өлеше — Разия белән өйләнешергә әзерләнү, икенчесе — Разия белән өйләнешкәннән соң яшәлгән тормыш. Сирәк хатын иде, мәрхүмәкәй. Химкиның һәр яфрагында, һәр гөл таҗында аның өлеше бар иде. Разияга карата булган тойгы мәхәббәт хисе генә түгел, әйтеп тә, сөйләп тә бетерә алмый торган туганлык белән сугарылган илаһи халәт иде. Башка хатыннардан аермалы буларак, аның йөзенең офыклары бар, бу офыклар өлкәнәя, картая барган саен ачыла, нечкәрә, мөлаемләнә барды. Улларының үлеме аның йөз офыкларының чит-читләрен каралтты, әмма ул барыбер кимемәс дәрәҗәдә матур иде…

Менә ул, туксан дүрт яшендәге ветеран, тәрәзәсе каршында үскән Разия гөлләренең хәлен белер өчен, хәзер тышка чыгачак. Аларны инде йортлар идарәсе түгел, Химкиның атаклы табибы Разия Рәшидованың ире — йортлар идарәсенең элеккеге җитәкчесе Рәшид Рәшидов үзе үстерә…

Ул, истәлекләрдән арынып, чәенә карады. Кара шама һаман йөзеп йөри иде. Киләсе кунак килмәде. Килсә, ул кем, нәрсә, үлемнең үземе? Ул үзе ап-ак, чәчләре ап-ак, ә менә Аллаһ шамасы һаман кара, һаман агармаган иде. Шуңа ачуы килгәндәй, дивардагы йөгерек түгәрәк сәгатькә караш ташлады. Истәлекләргә күмелеп, өч сәгать үтеп киткәнен сизми дә калган. Өч сәгать эчендә бер гасыр гомер кичерелде диген, ә? Ничек үткән, башкалар бәя бирер, дип кенә котылып булмый. Син үзеңә үзең бәя бир. Башкаларга калдырма. Үзеңнән башка кем акны — ак, караны — кара, дисен? Бу бит — Аллаһ алдында үзеңә шаһитлык бирү дигән сүз. Мулла баласы буларак, гомере буе гаделсез җәзалар кичерде. Дистәләгән аять-сурәләр, догаларны яттан белде. Аллаһның барлыгына, берлегенә ышанды, әмма туксан дүрт яшенә кадәр намазлыкка басмады. Кем ул, мөртәтме? Юк, түгел. Мөшрикме? Мөшрик тә түгел. Кем ул чакта? Мәйданда — коммунизм кызылында, өйдә ислам яшелендә яшәп яткан икейөзле монафикъмы? Кем кичерергә тиеш моның җәзасын үзеннән башка?

Монафикъ булган булса, 1989 елда партия билетын райком өстәленә китереп салыр идеме? Шул җәзаны тетрәнми күтәрер идеме? Кем соң ул алай булгач?! Телендә дә, гамәлендә дә «иншаллаһ!»тан узмаган сазлык вәгазьчесеме? Түгел! Теге ярдан — Ленин-Сталиннан киткән, бу ярга Мөхәммәд пәйгамбәргә килеп җитмәгән йөзгенче! Менә кем ул!.. Әгәр ул үзен дә, хатынын да, балаларын да, оныкларын да намазлыкка бастырган булса, бәлки, Әнвәр улы да, хатыны Разия да аны болай иртә ташлап китмәгән булырлар иде!.. Бернинди партком, бернинди маршал Жуковлар, бернинди советлардан калган кәнсәләрдә яшәп яткан «Бердәм Россия»ләр яклый алмый бит аны Аллаһ каршында. Кичер, Ходай Тәгаләм! Ата-анадан мөселман булып туып, мәҗүси кыланышларда гомере үткән!..

Һаман да шул берүк сорау: халык бар, холык бар!.. Ничек яратыла ул халык һәм халык баласындагы холык? Кайдан ул? Җирдәнме, җилдәнме? Уйданмы, суданмы? Каннанмы, җаннанмы?

И туган тел, и матур тел, әткәмәнкәмнең теле!..

Кремльнең унике метр биеклектәге, дүрт метр калынлыктагы диварларын җимереп керә бу аваз!..

Гомере урыс-улак арасында үтеп, каян килгән аңа телгә, Казанга карата бу кадәр кайнар мәхәббәт? Кайсы Кол Гали, кайсы Тукайлардан? Алардан гынамы?

Казан, дигәннән. Былтыр ул анда булды. Тукайны зиярәт кылды. Зиратта татарның Оркыя Ибраһимова кебек талантлы балаларының каберләре ташландык ятуына таң калды. Мәчеттә

бер мулланың икенчесенә: «Бүген бәлеш юкмы?» — дигәненә дә, Бауман урамындагы үзе эшләгән атаклы Матбугат йортының җимертелүенә дә, шагыйрьләренең мухомор әчкәндәй исерешеп йөрүләренә дә таң калды.

Ул, үзе дә сизмәстән, түгәрәк сәгать алдында тезләнде. Гүя хәзер гомер сәгате алдында гына җаваплы иде.

Әй-йә, Аллаһым!.. Газап та, ләззәт тә!..

Ничек кенә булмасын, советлар ташгасырында яшәп, туган мәктәбендә юньле-рәтле әлифбасын да өйрәнеп өлгермәгән сабый, милләтнең илаһи чыганакларыннан чишмә булып бәреп чыгып, милләтенә хыянәт итмәде. Польша Президенты генерал Войцех Ярузельский кебек, эшеннән алынганчы кара, эшеннән алынгач, ак күзлектә йөрмәде. Кара таңнарда кешелек алдына терекөмеш булып тәгәрәп чыгып, тузан ялады. Чит-ят китаплар, чит-ят имлялар аша сикерә-сикерә, ул иленә-теленә тугры калды. Ул шуңа инана һәм балаларына, оныкларына васыять итеп калдыра: әгәр татарның бер генә баласы да туган телендә белем алудан мәхрүм калган икән, бу милләт тарафыннан иң зур фаҗига буларак бәяләнергә тиеш. Рәхмәтеңнән ташлама, Аллаһым!.. Татар баласы туган телендә белем алуга кайтмый, намазлыктагы гамәлен гарәп һәм туган телләрендә башкармый торып, ул җирнең чирле баласы булуын дәвам итәчәк. Шуларны берсен икенчесеннән аерган өчен, хәләлне — хәрам, хәрамне хәләл белән алыштырган өчен җәзалар күрә. Тән — җаннан, җан тәннән читләшмәсен, алар бер тукымада гомер кичерсен! Илаһи амин!..

Кинәт телефон шалтырады. Ореховодан һәйкәл ачкан малайлары икән. Бу юлы элемтәдә Мәскәү татарларының Милли Мәҗлесе җитәкчесе Ринат Хафиз иде.

— Рәшид абзыкай, ачтык. Шундый матур!

— Матурлыгын — соңыннан. Биеклеген әйт. Күпме?

— Дүрт метр ярым. Аннан да артык кирәкми.

— Аны син хәл итәсеңмени, энем?! — дип ачуланып ыргыткандай булды Ринатны Рәшид агалары. — Мин әле моннан кырык ел элек Мәскәү кала советы рәисе Промысловка Җәлил һәйкәленең биеклеге, күпме мөмкин, биек булырга тиеш, дип язган идем. Чыңгызхан кебек әллә кайлардан күренеп торсын. Кайсы тирәгәрәк куйганнар? Әби патшаның зина йортыннан еракмы?

— Ерак кына. Муса Җәлил урамы һәм Братеев урамнары почмагында. Сыны горур. Безнең халыкка лаек. Сынчысы — Россиянең атказанган рәссамы Юрий Злобя...

— Берәр кахул йә ябрәйдер инде. Татарны тапмаганнар икән. Барыбер рәхмәт. Рәхмәт әйттегезме?

— Әйттек. Синең исемнән дә, синең үзеңә дә әйттек. Чәчкәңне дә тапшырдык... Һәйкәлне ачканда, халык артисты Сергей Шәкүрев Муса абыйның «Җырларым» шигырен укыды...

— Яхшы булган. Безнең җегет ул. Татарча укыдымы?

— Соңгы дүрт юлын татарча да укыды...

— Монысы да яхшы булган. Муса Җәлил татар халкын дөньяны фашизмнан коткарган иң зур һәм иң күп корбаннар биргән ун халык арасына керткән легендар шәхес. Җир шарының һәр кыйтгасында, һәр илендә Муса Җәлил исемендәге метролардан чыккан халыкны — егетләрне-кызларны, үсмерләрне, сабыйларны Муса Җәлил исемендәге татар мәктәпләре, татар балалар бакчалары, татар театрлары, татар университетлары каршы алырга тиеш. Министр чыгышында бу хакта әйттеме?

— Юк.

— Һи-и, шилма. Аларны мондый сүзләрне әйтергә өйрәтергә кирәк. Халыкны яклап, халык алдына терекөмеш кебек тәгәрәп чыксыннар...

15 май, 2013 ел ■

МАРСЕЛЬ БАКИРОВКА 80 ЯШЬ

ШУНДЫЙ ТАТАР ТЮРКОЛОГЫ БАР...

ӘНВӘР ШӘРИПОВ,
филология фәннәре докторы, профессор

КӘГАЗЬГӘ ЯЗЫЛМАГАН ШУНДЫЙ БЕР КАНУН БАР: ӘГӘР СӘНГАТЬНЕҢ ТӨРЛЕ ӨЛКӘЛӘРЕНДӘ ТАЛАНТЛАР ҮЗЛӘРЕН ЯШЬТӘН ҮК КҮРСӘТӘ АЛСАЛАР, ФӘНДӘ, БИГРӘК ТӘ ФИЛОЛОГИЯ ГЫЙЛЕМЕ ӨЛКӘСЕНДӘ, КЕШЕ ГАДӘТТӘ ЗУР УҢЫШЛАРГА БАРЫ ТИК КҮП ЕЛЛАР БУЕ ТЫНГЫСЫЗ ХЕЗМӘТ НӘТИҖӘСЕНДӘ ГЕНӘ ИРЕШЕРГӘ МӨМКИН. СҮЗЕМ ДИСТӘ ЕЛЛАР БУЕ ТЫРЫШ ХЕЗМӘТЕ БЕЛӘН ЗУР УҢЫШЛАРГА ИРЕШКӘН КҮРЕНЕКЛЕ, ОЛПАТ ТЮРКОЛОГ-ГАЛИМ МАРСЕЛЬ ХӘЕРНАС УЛЫ БАКИРОВ ТУРЫНДА.

М.Бакировның 9 нчы сыйныфта укыган чагы

Булачак галим 1933 елның 10 декабрендә Мөслим авылында (хәзерге район үзәге) укытучы гаиләсендә туган. Аның әтисе Хәернас ага бик укымышлы, тирәякта танылган математика укытучысы була. 1935-1936 елларда ул хәзерге Зәй районының Югары Баграж авылында мәктәп директоры булып эшләгән, мәктәп һәм колхозның берләштерелгән парткомында секретарь вазифасын башкарган. Күп эшләрдә ул үзе башлап йөргән, бик актив булган. Ә әнисе Фатыйма апа башлангыч сыйныфларда укыткан.

«Бала чагым — бал чагым», диләр безнең халыкта. Бу балачакның рәхәтлектә үтүенә, мәңге хәтердә калуына ишарәли шикелле. Ә менә Марсельнең балачагы бик күп кыенлыкларда, авыр шартларда үтә. Иң элек шул: Марсельгә 3-4 яшь вакытта аның

этисе Хәернас абыйны кулга алалар. Ул болай була.

Бервакыт, көз көне урып-җыю вакытында, партком секретаре Хәернас абый, кырдагы колхозчыларның ничек эшләүләрен тикшерергә баргач, аларга әйткән:

— Без дәүләт биргән планны үтәргә тиешбез. Уңыш яхшы күренә, планны үтәвебездә шик юк. Әмма ашлык уңган дип әрәм-шәрәм итмәгез, басуда бер башак та калдырмагыз. Чынлыкта, сез үзегезнең өлешне калдырасыз бит. Үз өлешегез күп булсын дисәгез, башак калдырмагыз.

Менә шул сүз аны гаепләргә җитә калган. Ул елларда НКВД органнарына бер кечкенә генә сигнал килә икән, кешене гаепләү өчен файдаланылган. Хәернас абыйдан көнләшеп йөри торган берәү аны шулчакта «чаккан»: «Ул халыкны хөкүмәткә каршы котырта. Хөкүмәт өлеше — эскертләрдә, сезнең өлешегез — җирдә калган башакларда, дип сөйли. Хөкүмәт интересы белән колхозчылар мәнфәгатен капма-каршы куя, контрагитация алып бара», — дип, югарыга ялган шикаять язып җибәргән. Шул җитә калган. Хәернас абыйны «халык дошманы» дип гаепләп алып

киткәннәр һәм бернинди адвокатсыз-яклаучысыз, тикшерү дә ясап тормыйча, бары «тройка» карары белән генә хәл итеп, ике ай ярым эчендә атканнар.

Ирен алып киткәч, Марсельнең әнисе Фатыйма апаны да тынычлыкта калдырмыйлар, аны өч баласы белән һәм сигез айлык йөкле хәлендә, кыш көне өйләреннән куып чыгаралар. Соңрак Фатыйма апаны, башлангыч класс укытучысы буларак, Мөслим

М.Бакиров – Казан дәүләт университеты студенты – сабакташлары белән, әдәбият түгәрәге утырышында. Сулдан уңга: Мәгъсум Латыйфуллин, Әхсән Баянов, Азат Әхмәдуллин, Хәниф Хәйруллин, Заһидулла Шәфигуллин, Марсель Бакиров, Юныс Әминов, Мөнәвир (?)

Марсель Бакиров (сулдан беренчесе) Пенза өлкәсенең Тархан авылындагы (хәзерге исеме Лермонтов) М.Лермонтов музее алдында студентлар белән

районының тикшерүчеләр күзенә чалынмаган иң ерактагы кечкенә авылларына укытырга җибәрә торган булганнар. Ә Марсель белән абыйсы Марс Мөслимдә икесе генә, бер караучысыз калган, үз көннәрен үзләре күрергә тиеш булган.

Менә шул вакытта татыйлар да инде алар «Нужа бабай шулпасын». Өйдә ике җан — әле буыннары да ныгып җитмәгән ике малай. Өй эче, табагач болгасаң да, бернинди чүпрәк-чапрак кисәге эләкмәслек шыр ялангач. Ярдәм итүче, хәлгә керүче беркем юк. Һәркемнең үз кайгысы. Беркем дә «халык дошманы» балалары белән аралашмый, үзләрен дә алып китәрләр дип куркалар. Бөтен өмет-ярдәм чыганагы — елның елында кысыр кала торган чирләшкә генә кара сыер. Аны карарга, ашатырга-эчертергә азык кирәк. Каян табарга? Җитмәсә, өй артындагы бәрәңге бакчасын да кисеп алып, районның бер түрәсенә биргәннәр. Янәсе, әниләре башка авылда эшләгәч, монда бәрәңге утыртырга хаклары юк. Нишләмәк кирәк, яз көне «халык дошманы»ның ике малае, ишегалдындагы бәләкәй генә чирәм җирне казып, шунда бәрәңге утырта. Аннан күпме генә бәрәңге чыксын инде?! Шул елгы кыш ятимнәргә үзен шактый сиздерә. Малайлар алдына зур гына проблема килеп баса — булган хәтле бәрәңгене кыш буена ничек җиткерергә? Бары бер юл кала: укырга иртән ашамыйча гына йөри башлыйлар. Мәктәптә, балалар арасында көн ничек тә үтә, эчнең «боргалавы» вакыт-вакыт басылып та ала. Ә мәктәптән кайткач, малайлар учак ягып, казанга күп итеп су салалар да, бер-ике бәрәңге әрчеп салып, озак кына кайнаталар. Бәрәңге, изелеп, юка гына әлпә булып, төпкә ята. Шул «баба шулпасы»на сыер биргән бер кружка сөтне өстиләр дә чак кына тоныклана төшкән суны тәлинкә-тәлинкә чөмерә башлыйлар. Корсак тулсын дип, бер утыруда бишәр-алтышар тәлинкә су чөмерәләр болар. Ә соңыннан иң тәмлесен — вакланып-изелеп төпкә яткан бәрәңгене ашыйлар. Әнә шулай көн артыннан көн үтә. «Нужа бабай» малайларны ничек яшәргә өйрәтә. Яз җиткәч,

Сулдан уңга. Беренче рәт: И.Нуруллин, Ф.Ганиева, Х.Госман, кафедра лаборанты, Р.Ганиева; икенче рәт: Н.Юзиев, М.Мәһдиев, Н.Лаисов, М.Бакиров, З.Мәҗитов.

болар икәүләп көрәк белән бер кешенең 25 сутый бакчасын казый. Шуның өчен аларга бер пот он бирәләр. Шул онны, һәр пешергән саен, суга 5-6 кашык кына салып болгаталар да шуны ашыйлар. Ә бакчаны казыганда чыккан черек бәрәңгедән, төеп, кәлҗемә пешерәләр.

Танылган галим Марсель Бакиров үзенең балачагында якты истәлек булып калган бер хатирәне болай сөйли. Аның балачактан ук рәссам буласы килгән. Малайның сәләте бар. Ул үзе моны сизеп яши. Сәләтне үстерергә кирәк тә бит, мөмкинлек кенә юк. Авыр сугыш заманы. Аларның янәшәсендә генә «Культмаг» дигән кибет бар. Марсель анда еш кергәли. Менә бервакыт кибеткә буяу карандашлары кайта. Тышлары да лакланмаган 6-7 төрле төстәге карандашлар. Марсель йөгереп кибеткә килеп керә дә шул карандашларга карап катып кала. Берәм-сәрәм кереп, балаларына яки оныкларына карандаш сатып алучыларга кызыгып, кичкә кадәр басып тора ул. Алыр иде — акчасы юк. Кибет ябылганда гына чыгып китә малай. Өйгә кайткач, әбисенең әйткән сүзен исенә төшерә. (Ә аның әбисе бик укымышлы остазбикә, тирә-якта танылган Тымытык мәдрәсәсе хәзрәтенең кызы була.) Әбисе аңа әйткән була: «Әгәр «Йа, Аллаһ! Йа, Аллаһ!» дип мең тапкыр кабатлап сорасаң, теләсә нинди теләгең кабул була. Аллаһы Тәгалә синең теләгәнеңне бирә». Шуны искә төшереп, Марсель йокларга яткач, төне буе «Йа, Аллаһ!», «Йа, Аллаһ!» дип, Аллаһтан үзенә төсле карандашлар бирүен ялварып сорап чыга. Йокыга китә башласа, үзен чеметеп алып, яңадан «Йа, Аллаһ!» дип кабатлый. Шулай итеп, таң алдыннан гына, иртәнгә төсле карандашларым булыр дип өметләнеп йокыга китә. Иртән, уяну белән (әй, нәүмиз чак, диген!) кулын мендәр астына тыгып, аннары аны әйләндерә-әйләндерә карандашлар эзли... Менә шул вакыйганы галим әле дә сагынып һәм ачынып искә ала.

Бала чагында Марсель үзенең абыйсы Марстан үрнәк алып, аңа сокланып үсә. Ә Марс абыйсы исә — ул чактагы бөтен Мөслим балаларының иң яраткан кумиры. Барлык эштә ул башлап йөри. Бик яхшы спортчы, чаңгычы була. Бөтен балаларны сокландырып, Мөслимнең иң зур Иске авыл тавыннан, аннан да текәрәк Тегермән тавы башларыннан чаңгыда шуып төшә. Ә җәй көннәрендә Ыкта йөзүдә Марска тиңнәр табылмый. Ул, башын суга тыгып, Ыкны башта бер якка, аннан икенче якка таба йөзеп чыга. Су астына чумып, ике-өч минут тора. Шуңа күрә аңардан суга баткан балаларны коткаруын үтенә башлыйлар. Һәм ул, водолаз кебек суга чумып, баткан ба-

ланы табып алып чыга. Марс абыйсы балачактан очучы булырга хыяллана. Урта мәктәпне гел бишлегә генә тәмамлап, ике классташы белән Балашов шәһәрендәге «лётное училище»га укырга керергә китә. Кабул итү имтиханнарының өчесен дә бишлегә тапшыра. Аның ике иптәшен укырга алалар, ә Марсның «халык дошманы» баласы икәнен белгәч, исемлектән сызып ташлыйлар. Шуннан соң Марс, Казанга барып, Казан дәүләт инженер-төзүчеләр институтына укырга керә, фәннәрне яхшы үзләштереп, институтны кызыл дипломга тәмамлый.

Әтиләренең, репрессияләнеп, «халык дошманы» исеме алуы Бакировлар гаиләсенең иң өлкән баласы — Шәркыя апаларының язмышына да кара мөһер булып ягыла. Урта мәктәпне гел бишлегә генә тәмамлап, Шәркыя Казан авиация институтына укырга керә. Бер ел укыгач, аны да, әтисенең кем булуын ачыклап, институттан чыгаралар. Аннан соң ул медицина институтына керә һәм аны тәмамлап, гомерен медицинага багышлый.

Әдәбиятка мәхәббәт Марсель Бакировта балачакта ук туа. Шул мәхәббәте аны 1951 елда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә алып килә.

Казанда аңа бөтенләй яңа бер дөнья ачылып китә. Лекцияләрне татар халкының атаклы галим-профессорлары Хатип Госман, Латыйф Җәләй, Якуб Агишев, Мансур Габдрахманов, Ибраһим Нуруллин, Гаяз Ишмөхәммәтовлар укый, соңрак аларга Мирфатих Зәкиев һәм Диләрә Тумашева килеп кушыла. Рус галимнәре Аркадий Шофман, Григорий Вульфсон, Леонид Тузов, Любовь Савельева һ.б. студентларны фәннәрнең тирән чоңгылларына алып керә. Әдәби кичәләр, диспутлар үткәрелә. Каләм тибрәтергә юл ача торган «Әдәби сүз» стена газетасы чыгарыла.

Казан университетын тәмамлагач, Марсель Бакировны журналист итеп Уфага, Башкортстанның өлкә газетасы «Кызыл таң»га эшкә җибәрәләр. Анда аңа редакциянең мәдәният бүлеге каршындагы әдәбият-сәнгать бүлекчәсен җитәкләү эшен тапшыралар. «Кызыл таң»да ул 1956-1966 елларда, барлыгы ун ел эшли. Соңрак, мөхәррир булып Таһир Ахунҗанов билгеләнгәч, Марсель газетаның сәркатибе вазифаларын да башкара: басманың макеты, бизәлеше һәм материалларның дөрес урнаштырылуы өчен җаваплы була. Бер үк вакытта газетада тормышның актуаль темаларына багышланган күпсанлы мәкаләләре, әдәби әсәрләргә, китапларга рецензияләре, очерклары һәм фельетоннары белән катнашып бара. Шушы елларда ул үзенең шәхси тормышын да җайга сала: фатир ала, Туймазы кызы Кифаягә өйләнә. Аларның бер-бер артлы ике кызлары туа, киләчәктә педиатр һәм гинеколог булып китәчәк балаларына Гөлназ һәм Гүзәл дип исем кушалар.

Бервакытны Уфага, университетта лекцияләр укырга Хатип Госман килә һәм, үзенең элекке талантлы шәкертен очратып, аны Казанга, үзенең җитәкчелегендә аспирантурада укырга чакыра. Редакциядәгеләр Марсельнең иҗади эшчәнлегенә күнегеп, өйрәнеп беткәнлектән, аны бер дә җибәрәселәре килми. Әмма Таһир Ахунҗанов ераккарак карап фикер йөртә, ул Марсельнең киләчәге хакында кайгырта һәм аңа: «Син тагын да үсәргә тиеш. Мин синең үсешеңә каршы килә алмыйм», — дип, үзенең ризалыгын бирә. Менә шуннан соң Марсель, гаиләсен вакытлыча Уфада калдырып, аспирантурада укырга китә.

Марсель Бакиров тормышының шуннан соңгы дәвере инде минем үз күз алдымда узды. Чөнки без аның белән аспирантурада бер үк чорда укыдык. Икебезнең дә (һәм өченчебезнең дә — КФУ профессоры, танылган галим Хатыйп Миңнегуловның да) фәнни

җитәкчебез профессор Хатип ага Госман булды. Без өчебез дә бер үк вакытта бер үк тулай торакта яшәдек.

Аспирантурада уку елларында М.Бакиров фән дөньясына чумып яшәде, ә менә тормышының матди ягын тиз генә көйләп җибәрә алмады. Һәм ул мөмкин дә түгел иде, чөнки Казан кебек зур шәһәрдә беркем дә аспирантка аерым фатир бирергә атлыгып тормый. Шуңа күрә Марсельгә дә өч елга сузылган аспирантура елларында, стипендиясенең ярты өлешен гаиләсенә җибәреп, ачлы-туклы диссертация язу белән шөгыльләнергә туры килде. Ул бары тик укуын тәмамлап, университетта укыта башлагач кына, Уфада калган үз гаиләсен Казанга алып килде.

Үзенең кандидатлык диссертациясен М.Бакиров төрки һәм татар шигыренең эчке ритмик-интонацион хасиятләрен һәм кануннарын эксперименталь юл белән тикшерүгә багышлады. Төрки шигыренең үзенчәлекләрен башка халыкларның шигырь төзелешләре белән чагыштырып өйрәнде. Ә шигырь теориясе турындагы фәнни хезмәтләрнең күпчелеге Европаның классик телләрендә — инглиз, немец һәм француз телләрендә язылган. Фәнгә ныклап аяк басыйм дисәң, шул телләрне яхшылап өйрәнергә, белергә кирәк. Һәм Марсель, мин хәтерлим әле, аспирантураның тоташ бер елын инглиз телен өйрәнүгә багышлады. Төнге сәгать икеләргә кадәр әлеге телне өйрәнеп, шул телдә язылган фәнни текстларны тәрҗемә итеп утыра иде ул.

Шәкерт кеше, әгәр ул талантлы булса, үзенең остазын уздырып та җибәрергә тиеш, дигән караш яши. Һәм бу дөрес тә. М.Бакиров белән дә шулай булды. Аның, фән кешесе буларак, тирәннән инанган бер сыйфаты бар: ул, гыйльми дәрәҗәләр алдында сукырларча баш имичә, теләсә кем һәм теләсә нинди аудитория алдында үз фикерен якларга, расларга ярата. Аның кандидатлык диссертациясе белән дә шундыйрак хәл килеп чыкты. Ул төрки галимнәрнең, шул исәптән фәнни җитәкчесенең итәгенә генә тотынып бармады, ә төрки шигыренең эчке хасиятләре турындагы, дипломында язган фикерләрен тагын да тирәнәйтеп, бу өлкәдә шәхси карашын, үз концепциясен булдырды. Оригиналь хезмәтендә төрки шигыренең үзәк проблемаларыннан булган төрки гаруз турында эксперименталь-фонетика аппаратлары белән тикшеренүләренең ышанычлы нәтиҗәләрен бирде: әгәр моңа кадәр аерым тикшеренүчеләр, мәсәлән, И.В.Стеблёва, М.К.Хамраев кебек галимнәр, төрки-татар шигъриятенә гаруз системасы ясалма рәвештә иңдерелгән һәм төрки телнең табигатенә туры килми, дигән караш үткәргән булса, М.Бакиров исә төрки гаруз ул төрки шигъриятенең үз казанышлары һәм уңай алшартлары белән гарәп-фарсы гарузы йогынтысы үзара кушылган җирлектә барлыкка килә, дигән яңа караш белдерде һәм шуны эксперименталь тикшеренүләре белән исбатлауга иреште; уртак казанышлар җирлегендә барлыкка килгән төрки гарузның да табигый яңгырашлы булуын, тел үзенчәлекләре белән үрелеп гәүдәләнүен исбатлады. Бу тюркология күләмендә яңгыраш алган үзенчәлекле һәм кызыклы ачыш иде.

Марсель Бакировның 1972 елда кандидатлык диссертациясе яклавын мин әле дә яхшы хәтерлим. Бу яклау университетның химия факультеты бинасында, 93 нче аудиториядә узды. Фәнни җәмәгатьчелек күп җыелган иде: Нәкый ага Исәнбәт, Бакый ага Урманче, Мөхәммәд ага Гайнуллин, Гази Кашшаф, Хәсән Туфан кебек татарның олуг әдип һәм галимнәре дә килгән иде. Яклау да югары дәрәҗәдә үтте. Яклау барышында Татарстаннан гына түгел, төрле төрки республикаларның фән үзәкләреннән диссертацияне һәм анда ясалган нәтиҗәләрне хуплаган бик җылы бәяләмәләр, хатлар, теле-

граммалар укылды. Мәсәлән, шул исәптән — тюрколог Александр Щербак, Ленинград университеты профессоры Габдрахман Таһирҗанов, казах шигыре белгече профессор Зәки ага Әхмәтов, уйгур галиме Морат Хамраев, азәрбайҗан галиме Җәгъфәр Әкрәм, үзбәк галиме У.Туйчиев һ.б. Ленинград университеты профессоры, күренекле галим Габдрахман ага Таһирҗанов, мәсәлән: «Хезмәтнең авторефератыннан чыгып фикер йөрткәндә, әлеге диссертация авторы филология фәннәре докторы дигән гыйльми дәрәҗәгә лаек», — дип язып җибәргән иде. Шундый ук фикер диссертациягә тышкы бәяләмә бирүче фән үзәге — Башкортстан Фәннәр академиясенең Тел, тарих һәм әдәбият институты бәяләмәсендә дә бар иде; анда: «М.Бакировның бу хезмәте кандидатлык диссертациясе рамкаларыннан шактый читкә чыга, узып китә», — дигән нәтиҗә ясалган иде. Диссертациянең беренче оппоненты, филология фәннәре докторы Гали Халит исә: «Кандидатлык диссертациясе өчен әлеге хезмәтнең беренче бүлеге дә тулысынча җиткән булыр иде, ләкин әлеге фикер хезмәтнең калган бүлекләре артык, кирәк түгел дигәнне аңлатмый», — дип бәяләгән иде.

Шундый зур бәяләмәләр булу аркасында, табигый рәвештә, бу хезмәтне фәннәр кандидаты дәрәҗәсе урынына докторлык диссертациясе итеп якларга кирәк түгелме икән, дигән мәсьәлә дә кузгатылды. Шул чагында М.Бакировның фәнни җитәкчесе Хатип ага Госман да үзенең әлеге хезмәтне докторлык диссертациясе итеп яклау тәкъдиме белән килешкәнлеген, әмма ул очракта Мәскәүдәге югары оешмадан — ВАКтан аерым рөхсәт алырга туры киләчәген һәм яклау эшенең шактый озакка сузылачагын белдерде. М.Бакиров шул чагында: «Киләчәктә, насыйп булса, мин докторлык диссертациясен дә эшләрмен», — диде. Нәтиҗәдә, 1972 елда татар әдәбият белеме фәне киләчәктә зур перспективасы булган яшь бер галим белән баеды.

Шул көннән алып М.Бакиров Казан дәүләт университетының татар әдәбияты кафедрасында укыта башлады һәм акрынлап кафедраның һәм факультетның әйдәп баручы укытучы-галимнәренең берсенә әверелде. Аның укыткан предметлары да үзенең фәнни-тикшеренү өлкәсе белән тыгыз бәйле. Ул «Төрки-татар шигыре теориясе һәм тарихы» дигән махсус курс укытудан башлый, аннары акрынлап «Әдәбият белеменә кереш», «Әдәбият теориясе» һәм «Татар фольклоры» предметларын тирәнтен үзләштерә, татар филологы өчен аеруча кирәк булган бу фәннәр дә аның иң яраткан предметларына әверелә.

Укыту барышында М.Бакиров, татар фольклоры өлкәсендә дә җитди тикшеренүләр алып барып, 1981 елда Казан университеты нәшриятында ун табаклык «Фольклор жанрларын системалы итеп тикшерү тәҗрибәсе» исемле автордаш хезмәт бастырып чыгарды. Анда бәет жанрының генетик тамырларын, аның эволюцион үсеш-үзгәреш баскычларын ачыклады, аларны тематик төркемнәргә аерды һәм сәнгатьчә эшләнешен, поэтикасын күзәтеп чыкты. Бу хезмәт фәнни җәмәгатьчелек тарафыннан яратып, хуплап каршы алынды.

М.Бакиров, фольклорга бәйләнешле тикшеренүләр белән бергә, шул ук елларда төрки-татар шигыре һәм борынгы төрки поэзиясенә бәйле фәнни-тикшеренү эшләрен дә башкарды. Үзенең остазы профессор Хатип Госманның тикшеренүләрен дәвам итеп һәм үзенчә үстереп, ул гомумтөрки шигыренең һәм поэзиясенең чишмә башын ачыклау һәм иң борынгы поэтик жанрлар системасын реконструкцияләү буенча җитди эзләнүләр алып барды. Шул максаттан чыгып, ул Мәскәү, Санкт-Петербург, Алма-Ата, Баку, Ереван, Бишкек, Ташкент, Уфа кебек

шәһәрләрнең үзәк китапханәләрендә нәтиҗәле тикшеренүләр, үз темасына бәйләнешле материаллар туплау белән шөгыльләнде. Соңыннан инде, әлеге тикшеренү-эзләнүләрнең нәтиҗәсе буларак, гаҗәеп саллы хезмәт — «Шигърият бишеге. Гомумтөрки поэзиянең яралуы һәм иң борынгы формалары» дигән монография барлыкка килде. 24 басма табактан торган бу хезмәт «Мәгариф» нәшриятында аерым китап булып дөнья күрде. М.Бакировның докторлык диссертациясе дә 1999 елда, шушы монографиягә нигезләнеп, югары дәрәҗәдә якланды.

М.Бакировның бу хезмәтенә галимнәр һәм фәнни җәмәгатьчелек лаеклы рәвештә гаять зур бәя бирде. Мәсәлән, Татарстан Фәннәр академиясенең президенты, академик Мансур Хәсәнов аның тикшеренүенә «Мирас» журналының 2002 елдагы 6 нчы санында «Шигърият чоңгылларына юл яручы хезмәт» дигән рецензия белән чыкты һәм, югары бәя биреп, болай дип язды: «Күпьеллык иҗат җимеше булган әлеге эшнең фәнни яңалыгы һәм галимнең кыюлыгы, тикшерү объектының тирән катламнарына үтеп керә белү сәләте бәхәссез. Тюркологиядә һәм татар әдәбият белемендә төрки әдәбиятның үзенчәлекле борынгы нигезләрен тикшергән аерым хезмәтләр элек тә бар иде. Әмма моңарчы букадәр ерак заманнарга һәм тирәнгә, ягъни бабаларыбыз тудырган шигъри-поэтик иҗатның пратөрки дәверенә, яралгы-эмбрион хәлдәге чорына берәүнең дә игътибар иткәне һәм бу кадәр тирән үтеп керә алганы юк иде әле».

Үзенең монографиясендә М.Бакиров төрки поэзиядә әлеге берлек-синкретизм җирлегендә барлыкка килгән иң борынгы жанр төрләрен барлап реконструкцияләде, система итеп күз алдына бастырды. Мәҗүси аллаларга һәм илаһи көчләргә багышланган гимннар, ода-алкышлар, корбан-келәү бәйрәмнәре һәм календарь-хуҗалык йолалары вакытында башкарылган келәүләр, йола әйтешләре, йола-уен җырлары, ырымнар, арбаулар, сыгытсыктаулар, шаман чакырулары, каргышлар, антлар — әнә шундыйлардан. Бу жанрлар төрле төрки халыкларның борынгыдан сакланган иҗатыннан алынган, моңарчы аз билгеле яки бөтенләй билгеле булмаган, беренче башлап автор тарафыннан фәнни кулланышка кертелгән уникаль фактик материалга нигезләнеп тикшерелгән.

Шул ук вакытта М.Бакиров, тюркологиядә беренчеләрдән, һун бабаларыбызда һәм борынгы төрки сүз сәнгатендә матур сөйләү-ораторлык сәнгатенең булганлыгын ачты, Орхон язмаларының да шул ук традициягә нигезләнгәнлеген исбатлап чыкты.

М.Бакировның фәнни эшчәнлеген Казан федераль университетында алып барган укыту-педагогик эшчәнлегеннән аерып карап булмыйдыр. Ул дистә еллар буе шушы уку йортында, алда әйтеп кителгәнчә, «Әдәбият белеменә кереш», «Әдәбият теориясе», «Татар халык тел-авыз иҗаты» буенча лекцияләр укыды. Хәзерге көндә дә ул, бәлүебезчә, фольклор буенча лекцияләр укуын һәм «Төрки-татар шигыре теориясе һәм шигъри әсәрләрне анализлау методикасы» дигән махсус курс алып баруын дәвам итә. Моннан тыш Традицион мәдәниятне үстерү буенча республика үзәгенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре вазифасын да үти. Университетта да әйдәп баручы иң тәҗрибәле педагогларның берсе булып санала, аспирантларга җитәкчелек итә. Аның лекцияләре тирән эчтәлекле, кызыклы булулары белән студентларны үзенә тартып тора. Үзенә 80 яшь тулуга карамастан, ул хәзер дә лекцияләрен яшьләрчә дәртләнеп, кызыклы һәм мәгънәле мисаллар китереп сөйли. Аның сигез дистәне тутыруына күпләрнең ышанасы килми.

М.Бакиров, яше олыгаюга карамас-

тан, гел хәрәкәттә — җәмәгать эшләре алып барудан да читләшми. Ул — Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре яклау советы әгъзасы, КФУда чыга торган «Филология и культура» дигән ВАК журналының редколлегия әгъзасы һ.б. Күпьеллык нәтиҗәле фәнни хезмәтләре өчен дәрәҗәле, мактаулы исемнәре дә бар. Ул — Россия Федерациясе Гуманитар фәннәр академиясенең академигы, Россия Федерациясе югары һөнәри белем бирү өлкәсенең мактаулы хезмәткәре, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Кол Гали исемендәге халыкара премия лауреаты һ.б. Инглиз телендә чыга торган «Who is Who в России» дигән энциклопедик басмада, «Татар энциклопедиясе»ндә, «Татарстан» дигән махсус энциклопедик бертомлыкта М.Бакиров һәм аның хезмәтләре хакында тиешле мәгълүматлар китерелә.

Соңгы елларда М.Бакиров күп еллар буена тупланган материаллары нигезендә яңа хезмәтләр язу һәм бастырып чыгару белән мәшгуль. Әле узган елда гына галим җәмәгатьчелеккә үзенең тагын бер монографиясен бүләк итте, ул — халкыбызның тел-авыз иҗаты хакында рус телендәге «Татарский фольклор» дигән хезмәт («Ихлас» нәшрияты, 2012. — 400 бит). Моңа кадәр татар халкының үткәндәге һәм хәзерге тел-авыз иҗаты әсәрләрен иңләп алып, аның барлык лирик, эпик һәм драматик жанрларын да тәфсилләп тикшергән, аларның типологик һәм милли этник үзенчәлекләрен анализлаган русча монографик хезмәт юк иде. Бу — рус фәнни җәмәгатьчелеген һәм рус телендә тәрбияләнгән милләттәшләребезне татар фольклорының байлыгы белән таныштыра торган беренче капиталь хезмәт.

М.Бакировның төрки-татар шигыре теориясенә һәм тарихына, пратөрки һәм борынгы төрки-татар поэзиясенә, халык иҗатына һәм фольклор культурасына караган фәнни монографияләре җидәү, төрле темаларга язылган фәнни-теоретик мәкаләләре исә 450дән артып китә. Соңгылар арасында этник һәм этнокультура тарихына багышланган концептуаль характердагылары да бар.

Әйтергә кирәк, шундый саллы фәнни хезмәтләр язу белән бергә, М.Бакиров хәзерге җанлы әдәби процесста да катнашып килә. Мәсәлән, шигырь белгече буларак, аның Р.Харис, Зөлфәт, Х.Әюпов, М.Мирза кебек шагыйрьләр иҗатына һәм, гомумән, әдәби тәнкыйтьче буларак, Ф.Садриев, Т.Галиуллин роман-трилогияләренә карата язган һ.б. мәкаләләренең һәркайсы үз вакытында хуплап каршыланды.

М.Бакиров бүген, күп еллар буена төрле китапханәләрдә бөртекләп туплаган гаҗәеп бай һәм күпкырлы материалларга таянып, төрки кавемнәрнең яралуы, этник һәм этнокультура тарихы турында махсус монография язу белән шөгыльләнә. Аның кайбер өлешләре, мәсәлән, борынгы төркиләрнең төрле Евразия халыклары белән бик борынгы культура бәйләнешләре һәм генетик кардәшлеге турында сөйли торган, мифологик һәм мәҗүси аллалар исеменә караган гаҗәеп кызыклы уртаклык-тәңгәллекләр турындагы тикшеренүләре КФУда нәшер ителүче ВАК журналында аерым мәкалә булып басылып та чыкты. Авторның әйтүенә караганда, яңа хезмәттә төрки халыкларның дөнья тарихында тирән эз калдырган цивилизаторлык ролен һәм казанышларын ачуга, киң җәмәгатьчелеккә җиткерүгә аеруча зур әһәмият биреләчәк. Олуг һәм олпат галимебезгә бу тикшеренүләрен киләчәктә уңышлы тәмамлавын, шулай ук аңа ныклы сәламәтлек һәм бәрәкәтле озын гомер теләп калабыз! ■

БЕР ӘСӘРНЕҢ ЯЗЫЛУ ТАРИХЫ

(Аяз Гыйләҗевнең «Кылдан нәзек, кылычтан үткен» романы турында*)

МИЛӘҮШӘ ХӘБЕТДИНОВА,
филология фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университеты доценты

РОМАННЫҢ ЯЗЫЛУ ТАРИХЫ

Соңгы илле ел эчендә татар әдәбияты классигы Аяз Гыйләҗевнең тормыш һәм иҗат юлын өйрәнүгә караган күпсанлы фәнни эзләнүләр дөнья күрде. Ләкин әдипнең иҗат лабораториясен барлау, әсәрләренең язылу тарихын өйрәнү игътибардан читтә кала килде, мирасына шул җәһәттән фәнни бәя җитенкерәмәде кебек. «Кылдан нәзек, кылычтан үткен» (1981-2002) романының язылу тарихы әдипнең тормыш һәм иҗат юлының соңгы егерме елын иңли.

Романның исеме әдип өчен аеруча әһәмиятле булса кирәк, чөнки әсәрне язу барышында исем үзгәрешсез кала. Исемнең Коръәндәге Сират күпере образы белән бәйле булуы көн кебек ачык. Сират сүзе Коръәндә кырыктан артык кабатлана, «туры, хак юл», «якты юл» мәгънәсендә килә. Исламда сират — адәм баласы өчен сынау юлы («Кылдан нәзек, кылычтан үткен»). Җәннәт һәм җәһәннәм турындагы ышануларга караганда, хак мөселманнар бу күперне «яшен тизлеге белән» үтә, гөнаһлылар исә күпердән «җәһәннәмнең кайнап торган сазлыгына»[1] чумалар. Сират күпере образы укучыны яшәеш мәгънәсе турында уйлануларга алып керә. Ислам өйрәтмәләрендә яшәеш фани дөньядан бакыйлыкка күчкәндә сынау юлы гына дип аңлатыла. Татар әдибе романда яшәеш мәгънәсе турында уйлана, үз асылыңа кайту, милли йөзеңне тану мотивын алга куя.

ӘДӘБИ ӨЛГЕ МӘСЬӘЛӘСЕ

Сакланган кулъязмаларда, әдипнең хатларында, көндәлекләрендә романны язу барышында файдаланылган әдәби өлге хакында искәртелми. Романга тирәнтен анализ барышында язучының рус әдәбияты традицияләренә дә мөрәҗәгать итүе тоемлана, бу аңлашыла да, рус классикасына мөкиббән әдип-

*Роман «Чын мирас» журналының 2013 елгы 7-10 нчы саннарында басылды.
[1] Ислам: Энциклопедический словарь. — М.: Наука. Главная редакция восточной литературы, 1991. — С.209-210.

нең әдәби традицияләрне иҗади үзләштерүгә гайре табигый түгел. Безнең фикеребезчә, А.Гыйләҗевнең «Кылдан нәзек, кылычтан үткен» романы — Л.Толстойның «Смерть Ивана Ильича» һәм А.Чеховның «Скучная история» повестьларының кайтавазы. Романның икенче төзәтелгән варианты В.Дудинцевның «Не хлебом единым», А.Бекның «Новое назначение», Д.Гранинның «Картина», Г.Владимовның «Верный Руслан», Ю.Трифоновның «Городские повести» кебек әсәрләр дөнья күргән чорда, шул дулкында языла.

РОМАН ТЕКСТЫНЫҢ ӘДИПНЕҢ БАШЛАНГЫЧ ЧОР ИҖАТЫ БЕЛӘН БӘЙЛӘНЕШЕ

«Кылдан нәзек, кылычтан үткен» романы А.Гыйләҗев иҗатын үтәли сызган төп теманы баета, тулыландыра. Буыннар арасында бәйләнешләр темасы әдип иҗатының башлангыч дәвереннән ахырынача үзәктә тора. «Җиз кыңгырау» (1959-1960), «Киек каз юлы» (1960-1961) пьесаларында һәм «Дүртәү» (1958), «Өч аршын җир» (1961) повестьларында А.Гыйләҗев әледән-әле бу темага мөрәҗәгать итә. Соңрак «Әтәч менгән читәнгә» (1979-1980), «Яра» (1984-1988) повестьларында, «Урамнар артында яшел болын» (1968-1969), «Балта кем кулында?» (1988-1989) романнарында һәм «Җан җылысы» (1970-1972), «Әткәй җылый да, җырлый да...» (1980), «Җанның җиденче тамыры» (1981) кебек пьесаларында буыннар чылбыры өзелү темасы калку гәүдәләндерелә.

1960 еллар урталарында совет әдәбиятында эпистоляр проза үсеш кичерә. В.Каверинның «Перед зеркалом» (1965-1970), А.Алексинның «Коля пишет Оле, Оля пишет Коле...» (1965) әсәрләрен, А.Морозовның «Чужие письма» тетралогиясен (1968), «Общая тетрадь» (1975), «Прежние слова» (1985) әсәрләрен мисалга китерү җитә. Бу дулкынга ияреп, А.Гыйләҗев «Кызлар хатлары» (1970-1971) исемле эпистоляр повесть яза. Эпистоляр жанрдагы табышлар язучыны рухландыра, ул «Кылдан нәзек, кылычтан үткен» романын атаның улына хаты рәвешендә оештыра. Хат исә төп герой һәм автор интенциясен берләштерә.

АТА / УЛ КАРШЫЛЫГЫ: РОМАННЫҢ БЕРЕНЧЕ НӨСХӘСЕНДӘ ҮЗ АСЫЛЫҢА КАЙТУ ПРОБЛЕМАСЫ

Автор уйдырмасы буенча, милли идеал ата шәхесен тану, ата булуның мәгънәсен күңелдән үткәрү ярдәмендә тергезелә: милли мәдәни традицияләрне Мирзанур нәкъ менә Хөснетдиннән мирас итеп ала. Үз асылыңны табу, үзбилгеләнү темасы исемдә чагылыш тапканнан соң, экспозициядә көчәйтелә. Роман Идел өстенә җәелгән томан сурәте белән башланып китә. Беренче карашка, табигать күренеше укучы тойгысын гәүдәләндерә: *«Томан һаман хәрәкәтсез тирбәлеп тора, ара-тирә генә күк ачылып китә, анда кояш нурларының уйнаганы чагылып ала, тик кояшның кайсы якта икәнен һич чамаларлык түгел, нурлар юл күрсәтүдән бигрәк күңелне генә котыртып калалар һәм ныграк адаштыралар».* Икенче яктан, мифопоэтик дискурста томан мотивы кешенең үз асылын табуга килүе белән бәйле мәгънәви катламга алып чыга: *«Томанның төрлесен күргәне бар Идел бүресе Мирзанурның, әллә нинди томаннарда да үзе белгән балыклы урыннарга туп-туры барып җитә торган иде, томалап яңгыр яуганда, көзге хәтәр җилләрдә дә көймәсен туктатып торганы юк иде. Бүген әллә нишләделәр. Әллә томаны гадәттән тыш, күтелмәгәнчә куе, әллә көймә хуҗасының күңеле төшенкеме?..»*

Томан тынычсызлану мотивын үз

эченә ала, яшәешнең камил булмавыннан туган эчке канәгатьсезлекне белдереп килә. *Томан* предметлар арасындагы чикне юкка чыгара, табигать объектларына иҗтимагый укылыш бирә: *«Томан тагын куера төште ахрысы, дымлы көймә төбендә тезен чәнчеп утырган Шәүкәт тә, кара җикән башлы камышлар да тоташ аксыл-соры стена артында шәүләләр кебек шәйләнделәр».* Герой үзе яшәгән тирәлеккә бәйлелектән котыла: *«...ул Шәүкәт белән сөйләшүдән качып, ялгыз гына калудан куркып эшләмәдемени бу эшләрне («дача сезонын» ябу, мари урманнарына гөмбәгә алып бару, балыкка алып чыгу —* ***М.Х.****)?!. Кеше арасында авыл турында, менә сигезенче елын ялгызы гына яшәп яткан әткәсе турында сүз кузгала алмаслыгын белеп, сизенеп, Шәүкәтне гел читләр арасына алып керде түгелме соң ул?»*

Геройның *томанны* үтүе *«юлдан язган ул»*ның *«атасының үз улына»*[2] әверелүе турында хәбәр итә. Елга — ике дөнья арасындагы чикне белдерә торган мәгълүм мифологик символ, томан исә еш кына бер дөньядан икенчесенә күчкәндә юлдаш. *Атаның* ихтыяры-теләге язылган зәңгәр тышлы дәфтәрне тизрәк кулга төшерергә теләве нәсел дәвамчысының хак юлга чыгуы, күңелдәге билгесезлек томанын кичүе, милли яшәеш тәртипләренә кайтуы турында хәбәр итә. Комга терәлгән *көймә* образы да символик укылышка ия, юлсыз калганлыкка ишарә.

Әтисенең үлеме турындагы хәбәр Мирзанурны яшәештә атаның урыны, гаилә-нәсел алдындагы бурычы турындагы уйлануларга этәрә: *«Әтисенең үлеме Мирзанур өчен әнә шундый борылыш минуты булды. Тормышның әтиле чактагы өлеше һәм әтисез өлеше булуын ул беренче мәртәбә шунда аңлады».*

Томан — ихтыяр антитезасы геройның ата вазифасын үз өстенә алырга әзер булуы турында хәбәр итә. Болан белән бәйле эпизод игътибарга лаек. Татарларда, кайбер башка халыклардагы кебек, тотемизмга барып тоташкан йола-ышанулар сакланган. Изге болан тәңре образын тудыруда әһәмиятле роль уйный дип исәпләнгән. Менә ни өчен А.Гыйләҗевтә болан артыннан хәрәкәт итүче көймә метафора вазифасын башкара. Болан образы туры юл белән янәшә куела. Боланның *ышанычлы* эпитеты белән бирелүе бу җан иясенең халык авыз иҗатында ират көче, ихтыяры мәгънәсендә килүен хәтергә төшерә.

Патриархаль мөнәсәбәтләрнең җимерелүе аталар белән балалар арасындагы мөнәсәбәтләргә йогынты ясый дигән фикергә автор аерым игътибар бирә. Милли яшәеш тәртипләре бүгенге чынбарлыкта үз кирәген тапмый: *«үзебезчә» — «заманча»; авыл — шәһәр* антитезасы шул эчтәлеккә корыла.

Ата образы алдан ук берничә мәгънәдә уйланыла. Беренчедән, укучы автор белән берлектә Җамалетдин, Ибраһим, Шәүкәтләрнең чын ата булуларына соклана, Хөснетдин, Мирзанурларның язмышларының сәбәбен эзли. Икенчедән, романда ата образы ярдәмендә патриархаль кыйммәтләрне үз иткән җәмгыять турында күзаллау

[2] Атаның бала өчен никадәр кадерле булуы татарларның эндәшү формаларында сакланган. Мәгълүм булганча, XIX гасырда мишәрләрдә «Хөснетдин улы» дип эндәшү киң таралган була. Хәтта гаиләдә балаларга шулай эндәшү гайре табигый түгел. Хатын үз иренә Мирзанур атасы дип тә мөрәҗәгать иткән. Галимнәр карашынча, татарларда исемнең тылсым көченә ышану элек-электән яшәп килгән. [Татары Среднего Поволжья и Приуралья. — М.: Наука, 1967. — С.350. (537 с.)]. Исламда атаның исем кушу белән бәйле бурычы искәртелә: «Аллаһ каршына сез үз исемнәрегез һәм атагызның исеме белән чакырылырсыз. Балаларыгызга матур исемнәр кушыгыз!»

булдырыла. Димәк, роман текстын ата / ул мифы ярдәмендә бәяләү өчен нигез бар. А.Гыйләҗев, «Өч аршын җир» повестендагыча, *ул / кызның китүе (урлануы) / символик үлеме, кайтуы* мотивларыннан оешкан мифологик сюжетка мөрәҗәгать итә. Төп сюжет сызыгы *юлдан язган ул турындагы мәгълүм дини текстны* тергезә.

Хөснетдин абзый гаиләсе фаҗигасенең сәбәпләрен автор идеологик картина белән бәйләп аңлата. 1930 елларда Иосиф Сталин *халыклар атасы турында миф* тудыра, рухи кыйммәтләр алышына, хакимият «халык дошманы» мөһере сугылган аталардан баш тартырга өнди, *ата* вазифаларын башкаруга алына.

А.Гыйләҗев романда гадәти совет гаиләсен тасвирлый. Хөснетдин абзый гаиләсендәге тынычсызлык аралашу өзелгәннән генә түгел, ди автор. Пенсиядәге мөгаллим, ихтыяримәҗбүри *авылның «ата»сы* — аксакалы булып торучы бу олы җанлы, кайгыртучан, игелекле кешенең йортына *«замана, чор»* авыруы йоккан. А.Гыйләҗев буыннар чылбыры өзелүне генә түгел, балаларның үзара мөнәсәбәтләренең катлаулануын бик төгәл күрсәтүгә ирешкән.

Романдагы мәгънәләрне бер төенгә җыйнаган зәңгәр тышлы дәфтәрдәге хат — Хөснетдиннең яшәеш мәгънәсе, ата бурычы турындагы уйланулары. Улы белән мөнәсәбәтләрне җайлау юлларын эзләп, ата кеше үз тормышындагы иң төп вакыйгаларны искә төшерә, кылган гамәлләрен нигезләп карый. Шуңа күрә хат мемуар характерда килеп чыккан.

Экспозициядә *«заманча»* — *«үзебезчә»* антитезасы ярдәмендә милли йөзеңне тану турындагы сорау проблема төсендә куела. Билгеле, Хөснетдин *«үзебезчә»не татарча, татар мәдәниятенә нисбәтле* булу дип аңлый. Хөснетдин нәсел дәвамчысының — улының дөньяга килүен тормышындагы иң әһәмиятле вакыйга дип искә ала. Исем — кеше шәхесенең бер өлеше ул. А.Гыйләҗев кешенең кемлеге, кайсы милләт баласы булуы исем кушканда ук билгеләнә, дип тәкъбир итә: *«Заман бик кызыклы иде, — дип искә төшерә Хөснетдин. — «Азат хатын» журналында бала исемнәре басыла, әмма татарлар балаларына әллә нинди шыксыз исемнәр ябыштыра башлаган чак иде. Мин андый мода артыннан кумадым, тыйнак кына, гади генә, әмма үзебезнең исемне куштым…»* Заманча да түгел, интернациональ дә түгел, Мирзанур дигән гап-гади татар исеме куша ата кеше. Ана *Өлфәт* дип кушмакчы булса да, карышмый, иренә каршы төшми, килешә. Сабыр-тыйнак, тугры, камил татар хатыны образы потенциаль эчтәлектә әнә шулай тудырыла. Татарлык — динилек тә ул, ди А.Гыйләҗев. Мирзанур — гарәп тамырлы исем, татарларга ислам дине белән керә. А.Гыйләҗев кеше исемен милли мәдәниятнең алыштыргысыз өлеше итеп күтәрә.

Хөснетдин тәрбия кылгандагы ялгышларын эзләп-барлап карый. Бөек Ватан сугышы аны биш елга гаиләдән аера. Ата сугыштан кайтканда, Мирзанур улы яшүсмер малай була. Озак та үтми, Мирзанур ата-ана йортыннан шәһәргә чыгып китә. Хөснетдин шул вакытта улындагы рухи үзгәрешләрне сизеп-тоемлап ала: Мирзанур *«заманча»* яшәргә хыяллана. Үзен «совет кешесе» дип тоеп, егет «татардан да ялкау, аннан да булдыксыз халык юк!» дип, татарлардан көлә, татар булуыннан уңайсызлана башлый. Милли тамырлардан баш тартканда, кеше туган нигезгә юлны суыта. Мирзанур авылга сирәгрәк кайта башлый, авылдашларыннан аерыла. Тиздән, атасының авыл мулласы вазифаларын башкарырга алынуын сәбәп итеп, гаиләдән дә китә. Хөснетдин улының туган нигездән аерылуының тамырлары

тирәнрәк икәнлеген аңлый. Совет кешесен билгели торган төп сыйфатларның берсе — милли тамырлардан баш тарту. Хөснетдин Мирзанурның ихтыяримәҗбүри совет кешесенә әверелә башлавын төшенә. Улы Аллаһка ышанмый, йола-гадәтләрдән читләшә. Гомер йомгагын сүткәндә, Хөснетдин заманында ата буларак тәрбия тәртәсен җәмгыятькә тапшырганга, үз кулына алмаганга үкенә.

Образлар системасында Закиров шәхесенә аерым игътибар бирелә. Бу ялган «совет» идеалы ата тарафыннан бала күңеленнән вакытында алып ташланырга тиеш иде дә бит. *«Заманча»* яшәү Мирзанур өчен — шәһәрдә яшәү, карьера ясау, «кирәк кешеләр» белән аралашу. Ул һәрвакыт «затлы, олы кешеләр» белән якынаю турында хыяллана. Мирзанур райком секретаре, ТАССРның Югары Советы депутаты, президиум әгъзасы Закиров кызына өйләнгән энесе Габделхәй өчен чын күңелдән сөенә. Габделхәй яңа гаилә кануннарын тиз арада үз итә, килеп чыгышыннан уңайсызлана башлый: *«Лира туризмны ярата дип, ул да шуңа иярде, башка гадәтләрендә дә Закиров булды да калды»* (героиняның исеме дә мәгънәгә ия). Ата кеше язмышның бу сынавы белән сабыр гына килешергә мәҗбүр. Ул кызның ата-анасы белән танышкан вакытта ук улының нинди гаиләгә эләгүен төшенә. Роман текстында *Гаффуров — Закиров* каршылыгы ике төрле яшәеш тәртибе, ике чынбарлык каршылыгы кебек укыла. Чәй эчү эпизодында туганлыкны инкарь итү милли яшәеш нигезләреннән баш тарту дип кабул ителә. Закировларда балаларга татар исемнәре кушылмый, милли йолалар үтәлми. Татарларда елмаеп, икекуллап күрешү гадәте сакланган[3]. Хөснетдин кода Закировлар йортында көтелгән кунак түгел. Яңа туганнар күрешкән вакытта ук Хөснетдинне чит итүләрен сиздерәләр. Чәй эчү күренеше метафора булып килә. Гадәт буенча, чәйне хуҗа кеше ясый, автор чәйнең сыек булуына игътибар иттерә. Татарлар элек-электән сөтле яки җимешле куе чәй эчәргә гадәтләнгән. Биредә *«каты»* — *«сыек»* антитезасы метафорик мәгънә ала. Туганнар арасындагы мөнәсәбәтләр ныгымый, сыек чәй кебек кала: Закиров гадәтләргә буйсынмый (кодасын «кунакка чакырмады, хәлен сорашмады, белешмәде»).

Закировларның башка кодасы да шул хәлдә. Мирзанур биредә гаепләрлек берни күрми: ул, үзе дә сизмәстән, «закировларча» яши башлый («аның югары дорфалыгына өйрәнә башлаган Мирзанур...»). Атасына булган ачуны ул, әтисе мулла вазифасына керешкәч, рәхәтләнеп чыгара. Ата белән ул арасында мөнәсәбәтләр 8 елга өзелә. Ата кешегә — 77, ул тиешле кешегә 50 яшь тулгач, *ата улы* белән аңлашусөйләшү кирәклеген аңлый.

Тәүбәгә килү күңелдәге киеренкелектән котылырга ярдәм итә, сират күпере күз алдына килә башлагач, геройлар күңелләрен бушатырга үзләрендә көч таба.

Хөснетдин — совет кешесе дип аталган, үткәннәрдән баш тарткан буынның беренче карлыгачларыннан. Очраклы гына авылдашы Мөхәммәт белән күрешкәннән соң, гомер йомгагын сүтә — милли нигезләргә кайту хакында уйлана башлый. Күмү йолаларында катнашу аның күңелен яктырткандай итә, карт эчке канәгатьләнү хисен тоя, шул рәвешле дингә килә.

Улына күңел дөньясын ачканда, Хөснетдин озак еллар Аллаһтан ерак булганлыгын тәкъбир итә. Гомеренең

[3] Күрешкәндә, кул бирүнең нинди тирән мәгънәгә ия булуы бер хәдистә ачык әйтелә: «Ике мөселман кул биреп исәнләшсә, аларның гөнаһлары куллары аерылганчы ук гафу ителер» (Әхмәд, Әбу Давыт, Ибн Маҗа, Тирмизи).

яртысын ул үз көченә таянып кичә, госпитальдә үлем белән тартышканда, дога укымавын искә төшерә. Мөхәммәтне җирләгән вакытта, бабалар хәтеренә төшенә, кумү йоласының мәгънәсен аңлый: *«Әйе, мин яшьли дин дәресләрен алган булсам да, бер чакта Аллага-Ходайга ышанмадым. Әмма Мөхәммәт абзыйны җир куенына иңдергәндә, мин нинди юлалар белә идем? Нинди сүзләр белән аны соңгы юлына озата ала идем? Әйе, дөньялыкта кылган изге эшләрен аз-маз хәтергә төшердек, авыр туфрагың җиңел булуын, тар каберләренең киң булуын теләдек. Тик болай гына җитә идеме соң?.. Ә монда, туган җир, авызын ачып, тагын бер корбанын үзенә алганда, мин башка юлалар да, сүзләр дә белми идем».*

Мөхәммәтнең үлеме Хөснетдинне туган нигезгә кайтара. Бу хәлне ишетеп белгәч, Мирзанур ачуын көч-хәл белән тыеп тора. Аның карашынча, әти-әнисе караңгы авылда түгел, район үзәгендә яшәп картаерга тиеш. Әтисенең мулла булуын белгәннән соң, аны төрлечә гаепли, битәрли: *«Минем әти мулла! Элек укытучы булган, хәзер мулла! Бәлки Яныкта мәчет тә ачтырырсың әле син!»* Яман-ярсу Мирзанур «фидия козгыны» яшәгән йортка башка аяк атламаячагын белдерә. Хөснетдин, муллаларга мөнәсәбәтне үзе тәрбия кылганга, улының «авыр гаепләвен» сабыр гына кабул итә: «Фидия козгыны» дигән сүзне сиңа мин сеңдергәнмендер, бала чагында Тукайларны, Фатих Әмирханны еш укый торган идем мин. *«Фидия козгын»нары турында байтак мәзәкләр, халыкның тапкыр сүзләрен дә ишеттерми калмаганмындыр!»*

Гауга купкан көнне Хөснетдинне авыру Җамалетдин белән хушлашырга чакыралар. Үлем түшәгендә яткан Җамалетдин янына туганнары, авылдашлары җыелган. Авыруның кулыннан алып, карашын тоеп, Хөснетдин уй-фикерләрен җыярга, аны юатырга тырыша: *«Менә рәхмәт улларыңа, Җамалетдин кордаш, үз өеңдә, үз түреңдә кадер-хөрмәттә ятасың...»* Ләкин җыелган кардәшләр аңардан башка сүз көтә. Җамалетдиннең улы Хөснетдингә Коръән китабын бирә, ясин чыгуын үтенә[4]. Таушалган китапны кулына алгач, Хөснетдин үләр алдыннан кешегә гарәпчә сүрә нигә кирәк, ул аның гомерен озайтамы, дип аптыраштa кала. Кинәт ул Коръәннең бабаларыбыз катына — Идел-йортка никадәр катлаулы һәм озын-озак юллар белән ирешкәнлеген күңеленнән үткәрә.

Хөснетдин ясин чыкканда, карт үлә, җыелган авылдашлар Җамалетдиннең якты кеше булуын, исламча яшәвен искә төшерәләр: *«Изге җан шул, мәрхәмәтле кеше. Иман белән дөньядан китте. Урыны шаять җәннәттә булыр...»* Хөснетдинне бу вакыйга тетрәнергә мәҗбүр итә. Аллаһка үзе ышанмаган килеш, ул башкаларны ышандыра алды бит. «Ясин» Мирзанурның атасына Аллаһ *Сүзенең,* Коръәннең көчен тоярга ярдәм итә.

«Ясин» сүрәсен укыган вакытта, Хөснетдин ата булуның дини бурыч икәнлеген аңлый. Исламда ата булу *әманәт* — Аллаһның бүләге, ул кеше-

[4] Мөхәммәд пәйгамбәр Ясин сүрәсен Коръәннең җаны дип атаган. Сүрә исәннәр укысын һәм уйлансыннар өчен. Бер хәдистә әгәр үләр алдыннан бу сүрә укылса, үлгән кешене юган вакыттан башлап каберенәчә 30 мең фәрештә катнашачагы, аның гөнаһлары өчен гафу сораячаклары әйтелә. Кабере иркенәер, күз карашы киңлеге кадәр булыр, үзе кабер газапларыннан котылыр, каберенә нур иңәр, бу вакытта Аллаһ аның тәнен җирдән күтәрер, фәрештәләр аны сират күпереннән җиңел генә алып чыгар, тәнен Аллаһка якынрак җиргә пәйгамбәрләр һәм фәрештәләр белән янәшә урнаштырыр, җаны тынычлыкта булыр, диелә.

А.Гыйләҗев, Г.Ахунов, М.Мәһдиев. 1993 ел

не олы җаваплылыкка өнди. Мәгълүм булганча, исламда ахырзаман көнне балалар сынаудан коткара, диелә.

Хөснетдин хатында улының *шәфкатьсезлегеннән* куркуын белдерә. Үлем сәгате якынлашкан мизгелдә, ата улында туган җиргә, авылдашларга карата хөрмәт тәрбияли алмаганына үкенә. Татарлар турындагы бәхәсне дәвам иткәндәй, ата Себердә яшәүче халыкларны искә төшерә. Алар яшәү өчен уңайлы шартлар эзләп, туган җирләрен ташлап, Кырымга күчми ләбаса. Хөснетдин нәсел белән бәйле рухи кыйммәтләрне Мирзанурның хәтеренә төшерергә тели. Үләр алдыннан карт улына туган җиргә мәхәббәтне васыять итә: *«Ярый, мин хаксыз да булыйм, ди, ялгыш синең ачуыңны да чыгардым, ди… Монда бит синең илең… Туганнарың… Сиңа яхшы киңәш биргән, яктылыкка өйрәткән, синең бала чагыңны нурландырган бик күп кешеләрең бар иде. Син аларны да оныттыңмы?! Аларның гаебе нидә?»*

Әтисенең хаты Мирзанурны тетрәтә. Шәфкатьсезлектә гаепләвен ул әтисенең ачулы булуына кайтарып калдырырга тели, үзен тынычландырырга ашыга. Ләкин хатынының да вакыт-вакыт: *«Син куркак, куркаклыгыңны яшерер өчен явыз»*, — дип гаепләвен исенә төшерә.

Геройларның язмышларын тасвирлаганда, көзгеле композиция алымын куллану язучыга образларны типиклаштырырга ярдәм итә.

Мөхәммәт карт — Мирзанурның әтисе өчен үзенә күрә «көзге». Хөснетдин фаҗиганең ни дәрәҗәдә тирән булуына аның белән сөйләшкәндә төшенә. Бөек Ватан сугышында татар халкының тулы бер буыны — бүген аксакал булырга, яшьләргә тәрбия бирергә тиешле *«аталар»* буыны башын салган, юк ителгән бит. Нәтиҗәдә, яшь буын бабайлар тәрбиясеннән мәхрүм кала, буыннар чылбыры өзелүнең бер сәбәбе шуннан гыйбарәт. Мирзанурлар үскән чорда буыннар хәтерен идеологик пропаганда алыштыра.

Мирзанур әтисенең үлеменнән соң табынган идеалларының буш, гомеренең төссез икәнлеген аңлый. Л.Толс-

[5] Әйтергә кирәк, А.Гыйләҗев әсәрләрендә бакыйлыкка күчкән җаннар төшләрдә генә искәртелми, кош тавышлары кебек тә («Өч аршын җир»), күбәләк килүе рәвешендә дә («Өч тәгәрмәчле арба», «Җомга көн, кич белән…») тасвир ителә.

тойның Иван Ильичы кебек, бер мизгел эчендә бала чагыннан тыш бөтен гомерен сызып ташлый. Әтисенең үлеме аны шулкадәр тетрәтә ки, Мирзанурда ир-ат сыйфатлары уяна, нәсел алдында җаваплылык тойгысы барлыкка килә. Толстой герое кебек, Мирзанур да Аллаһка йөз белән борыла, тәүбәгә килә, яшәешен башка күзлектән бәяли башлый.

Мирзанур өчен «көзге» булып үз әтисе тора. Романда үз асылына кайту, «ата улына» әверелү аң агышы алымы белән бирелә. А.Гыйләҗев герое үзендә яңа якларны ача, таный.

Мирзанур өчен күршесе Ибраһим да «көзге». Ибраһимның исеме — бераллалыкны тәүге мәртәбә үткәрүче пәйгамбәр исеменнән. *Ата сүзеннән* соң Ибраһимның игелекле, шифалы сүзе йогынтысында Мирзанур үз асылына кайтуга, милли йөзен тануга таба борыла.

Ашка чакырылу эпизодында Мирзанур өчен беренче тапкыр милли хәтер кайтавазы булып торган *ата сүзе* замана йогынтысыннан өстен чыга. *Куркак Мирзанур Гаффуров — Хөснетдин улы* антитезасы герой күңелендәге үзгәрешләрнең ни дәрәҗәдә тирән булуын күрсәтә. *Куркак Мирзанур* ашка барырга уйламыйчарак ризалык белдерүенә үкенә. Ләкин әтисенең үлеменнән соң туган тетрәнү аны, олы улының төрткеле шаяруына игътибар итмичә, ашка барырга мәҗбүр итә.

Рас төш эпизоды исәннәрнең бакыйлыкка күчкәннәр белән бәйләнешенең какшамас булуы турында хәбәр итә[5].

А.Гыйләҗев мәрхүмнең ашын үткәрү йоласын үз иҗатында беренче тапкыр тәфсилләп тасвирлый. Аның максаты — хак мөселман күзлегеннән түгел, ә замана чирен йоктырып, үз асылын югалткан, милли хәтерен җуйган кеше күзлегеннән «Тәбәрәк» сүрәсен бергәләп укуны, нәселнең бакыйлыкка күчкән һәр улына һәм кызына аерым-аерым дога багышлауны «күзәтү». А.Гыйләҗев өчен бу — аеруча әһәмияткә ия өлеш.

Аштан кайткач, Мирзанур улының бабасын ни дәрәҗәдә хәтерләвен белешә. Олы улы җавап урынына әтисенә: *«Па, ә син нигә мине берчакта да мәчеткә алып бармадың?»; «Ә син, па? Үзең бабаңны хәтерлисеңме?»* кебек сораулар яудыра башлый. Мирзанур заманча улының мәчеткә йөрүче кәләпүшле картлар белән ихластан кызыксынуын белгәч, аптырашта кала, уйлары чуалгандай итә.

Бу вакыйгадан соң Мирзанур улы белән мөнәсәбәтләрне барлый башлый. Улының бабасы турында сораштыруы, әтисенең зәңгәр тышлы дәфтәре Мирзанурны үткәннәр турында уйланырга этәрә. Әтисенең зимагур бабасы турында 1928-1930 елларда кайдадыр туган җирдән читтә җан тәслим кылганын сөйләгәннәрен авырлык белән булса да исенә төшерә: *«Җирән сакаллы, озынча, какча карт иде» — дип сөйләгән иде әтисе»*. Ихтыярсыздан бабасын искә алмаганы өчен Мирзанур үзен улы алдында гаепле сизә башлый. Мирзанурның дөньяга күзе ачылгандай итә, заманага ияреп яшәүнең мәгънәсезлегенә төшенә. Күңеленә тынычлык, рухына таяныч эзләп, ул Ибраһим катына килә. Оялып кына булса да, тол хатынга сәдака бирә, дога тыңлаганда, күзләре яшьләнә. Өенә кайтып, хәтерен яңарта, әтисен, бабасын, мәчеттәге картларны күз алдына китерә, Коръән турында уйлана һәм туган нигезенә кайтырга карар кыла.

Авылга кайтуга, балачак дусты аны атасы йортына озата. Шәүкәтнең кызы: *«Сез фәлән абыйның улымы инде?»* — дип сораганга сискәнеп, Мирзанур ата булуның, ата улы булуның мәгънәсенә төшенергә теләп уйлана башлый. Ни кызганыч, рухындагы үзгәрешләрне төзәтү мөмкинлеге юк инде. Авыл йортындагы һәммә нәрсә

мизгел эчендә кыйммәтле, җанга якын мираска әверелә дә кала. Кайтуының беренче көнендә Мирзанур яфрак коелуын күзәтеп моңсулана, икенче көнне күкне җир белән тоташ иткән яңгырга соклана. Тиз арада карлы яңгыр ява башлый. Дүртенче көнне җир туңа, бишенчесендә кара җирне ак кар каплый. Ниһаять, Мирзанур каберләрне зиярат итәргә карар кыла.

Шәһәрдә дустын җирләгән вакытта, ул кабер ташларына, үлеләрнең ничә яшьтә дөньялыктан китүләренә игътибар итә. Туган авылындагы зиратта исә аны башка нәрсәләр уйландыра: *«Зират... Әйе, монда аның нәсел-нәсәбе, ул белмәгән, белсә дә онытып бетергән ерак туганнары күмелгән... Монда аның авылдашлары... Монда бик яшьли үлгән аның яшьтәшләре...»* Кабер ташларында «Сабир кызы Фәүзия», «Мөхәммәт улы Сабир» кебек язуларга, фамилияләр язылмауга игътибар итә. Ул үлгәннән соң аның исеме янында күп еллар буе аралашмаган әтисенең исеме уелачагы беркадәр сискәндерә. Биш каен белән янәшә торган калку урынга җитүгә, Мирзанур: *«Ата... Әти... Әткәй...»* — дип әрнеп-сызланып елый. Бу эпизод А.С.Пушкинның «Станционный смотритель» әсәрендәге шундый ук эпизодны хәтерләтә.

Зиратта Мирзанур үзенең атасына ихтирамсызлыгын, өметләрен акламавын, чын ул була алмавын, гаебен таный. Үз улы белән дә киеренке мөнәсәбәтләрне үзгәртә алмаячагын танырга мәҗбүр була. Мирзанур улын авылга кайтару, Шәүкәтнең кызы Ганҗә (исеме «чәчәкнең таҗы», «ачылмаган чәчәк» мәгънәсендә) кебек тыйнак татар кызына өйләндерү, туган нигезне тергезү турында хыяллана. Җил тавышын тыңлый-тыңлый, янган учак янында Мирзанур балачагы һәм яшьлегенең гаҗәеп матур кешеләр белән янәшә үтүен уйлап сагына. Аны да улы шулай дип искә алырмы, хәтереннән җуймасмы? Мирзанур шул хакта да хәсрәтләнә. Романның беренче нөсхәсендә финал ачык кала. Укучы үз ялгышларын таныган, үзгәрергә теләп сызланган Мирзанур белән хушлаша.

1988 елның язында әдип, романның тәүге уйдырмасын саклаган хәлдә, сюжет сызыгына, геройның тормыш юлына шактый үзгәрешләр кертә. Бу нөсхә әдипнең вафатыннан соң 2004 елда «Казан утлары» журналында дөнья күрә[6]. Күренә ки, А.Гыйләҗев автобиографик жанр чикләрен үтәргә омтыла. Төзәтүләр кертелгәннән соң, әсәр идеологик роман булып үзгәрә.

---

[6] Бу нөсхәгә анализ безнең түбәндәге хезмәтләрдә тәкъдим ителде:

Хабутдинова М.М. Символика советских праздников в произведениях татарского писателя А.Гилязова // Языки России и стран ближнего зарубежья как иностранные: преподавание и изучение: материалы Международной научно-практической конференции (10-11 ноября 2011 г.). — Казань: К(П)ФУ, 2011. — С.265-268;

Хабутдинова М.М. Религиозный поиск Аяза Гилязова в контексте творческой эволюции // Фаизхановские чтения: материалы VII Всероссийской научно-практической конференции «Комплексные исследования мусульман Волго-Окского региона: история, археология, филология, языкознание, этнография». — М.-Н.Новгород: Медина, 2011. — С.77-84;

Хабутдинова М.М. Духовный мир татар-кряшен в романе Аяза Гилязова «Тоньше струны, острее меча» // Материалы международной научно-практической конференции «Славянская культура: истоки, традиции, взаимодействие. XIII Кирилло-Мефодиевские чтения» (15 мая 2012 г., Москва) — С.128-132;

Хабутдинова М.М. Топос Казани в творчестве Аяза Гилязова // Филология и культура / Philology and Culture. — 2012. — №1. — С.136-141;

Хабутдинова М.М. Вопросы религиозной самоидентификации в творчестве татарского писателя Аяза Гилязова (1928-2002) // «Медина аль-Ислам». — №137. — 19 февраля 2013 г. // http://islamrf.ru/news/culture/history/26339/. ■

МӘКТӘП ЯШЕНДӘГЕ БАЛАЛАРГА

ОЛУГ ШӘҺӘРДӘ КУНАКТА

(1235 елның җәе)

РУХИЯ АХУНҖАНОВА,
шагыйрә, Ш.Маннур исемендәге әдәби премия лауреаты

ТӨЗҮЧЕ АСЛАН

Биләр авыл да кебек, шәһәр дә кебек. Божра сыман төзелгән пайтәхеттә кирпеч йортлар гына түгел, агачтан салынганнары да күп икән. Әнә ерак түгел генә ашлык саклау келәтләре тезелеп киткән. Күр әле, һәрбер йортның каршына агачлар утыртылган. Алар кешеләргә күләгә биреп торалар. Юлның як-ягында хәтфә үләннәр үсеп утыра. Ара-тирә чәчәк түтәлләре очрый. Урамда кешеләр нигәдер әз күренә.

Тынлыкны энем Айтимер бозды.

— Бу кадәрле күп йортны ничек төзеп бетергәннәр?! — диде ул, гаҗәпләнеп.

Теләй абзый һәрвакыттагыча сөйли-аңлата башлады:

— Төзүчеләр күп ич Биләрдә. Чит мәмләкәтләргә барып эшләп кайтырга да өлгерәләр әле. Мәсәлән, узган гасырда яшәгән төзүче Асланны бөтен дөнья белгән. Менә шул мәшһүр төзүче таш өстенә язулар һәм бизәкләр уярга, сырлар ясарга, төрле сын-сурәтләр төшерергә маһир булган. Мондаен нечкә-нәфис эшкә тотыну өчен, тумыштан ук нәкыш остасы булырга кирәк...

Теләй абзый тәмләп сөйләвен белде. Без дә колакларыбыз белән аның һәр сүзен «тота» бардык.

— Аслан таш чыгару һәм аны эшкәртү буенча үзенең хуҗалыгын да булдырган. Өйрәнчекләренә үзе белгән серләрне төшендергән. Аларга остазлык иткән. Остарган ярдәмчеләрен үзе белән алып, шәһәрләрдә хан сарайлары һәм зур-зур корылмалар төзеп йөргән. Ул иҗат иткән могҗизалар башка халыкларны да таң калдырган. Зур акчалар тәкъдим итеп, урыс кенәзләре аны үзләренә эшкә чакыра башлаганнар. Асланның ташка уеп ясаган рәсемнәре бик күп чиркәүләрне дә бизәгән...

Тын да алмыйча, аны тыңлап баруыбызны ошатты Теләй абзый. Сүзен дәвам итте:

Божра — әйләнә, түгәрәк.
Пайтәхет — башкала.
Хәтфә — бәрхет.
Мәмләкәт — дәүләт, ил.
Мәшһүр — танылган, атаклы.
Маһир — оста, сәләтле.
Нәкыш — агач, сөяк, таш кебек нәрсәләргә кисеп, уеп, сырлап яки чокып ясалган бизәк; орнамент.
Остаз — һөнәргә өйрәтүче кеше.
Могҗиза — акыл җитми торган күренеш.
Кордаш — кем белән дә булса яшь ягыннан бер чамада яки бер елгы булып, бергә үскән, бер чорда яшәгән кеше.
Хикәят — нинди дә булса вакыйга турында телдән сөйләү.
Болгар иле — Урта Идел, шул исәптән хәзерге Татарстан территориясендә

* Ахыры. Башы журналның 10, 11 нче саннарында.

— Асланның Яхам атлы углы да оста төзүче-бизәүче булып танылган. Атасы кебек, ул да бик күп урыс шәһәрләрендә булган. Анда чиркәүләрне матур итеп, бизәкләп эшләгән. Димәк, атасы нинди, углы шундый. Ерак китәсе юк. Менә Шәмсираван да, әтисенә охшап, белем иясе булып үсеп килә. Шәехби кордаш кебек, углы Шәмсираван да «Мөхәммәд Бакирия» исемле гыйлем йортында шәкертләргә югары белем бирер…

Ак канатлы тулпар атыбыз җиңел генә җилдерә, әйтерсең лә йомшак һава агымына ияреп бара. Тояк тавышы безне гүя бишектә тирбәтә.

Арба-бишектә тирбәлеп, күңелле хикәят тыңлап баруы рәхәт. Барыбыз да аның дәвамын көтәбез. Әмма Теләй абзый тәмамлады шикелле инде. Әнә нәтиҗәсен дә чыгарып куйды ич. «Атасы нинди, углы шундый», — диде.

Юк, хикәят бетмәгән икән.

— Болгар иле төзүчеләргә элек-электән бай булган. Алмыш хан да, аның углы Хәсән дә мигъмари-төзүчелек эшләрен һәрчак күз уңында тотканнар. Шуңа күрә бер-бер артлы шәһәрләр барлыкка килә торган. Шәһре Биләр дә шул чорда үсеп чыккан…

Теләй абзый сөйли. Без, бишебез бер булып, йотлыгып тыңлыйбыз. Пайтәхет турында күбрәк беләсебез килә.

— Шушы шәһәр төзеләсе урын элек тип-тигез киң ялан булган. Аулак урын дип, өч би киңәш-табышка һәрвакыт шунда җыелганнар. Халык бу яланны «Биләр» дип йөртә башлаган. Алмыш хан шушында яңа шәһәр төзеткән, кәрвансарай һәм мәсҗид салып куйган. Хан үтенече буенча Багдад хәлифәсе җибәргән төзүчеләр тырышып эшләгәннәр. Әкияти гүзәл шәһәр шулай пәйда булган. Шәһәрне, әлбәттә, «Биләр» дип атаганнар. Чүти, Әбрак, Хум һәм Үбар кебек данлыклы төзүчеләр дә Алмыш һәм Хәсән ханнар заманында зур уңышка ирешкәннәр. Әмма Аслан — ташны «йөгәнләп», үзенә буйсындырган оста. Үз илендә генә түгел, чит җирләрдә дә шөһрәт казанган бөек төзүче ул! — диде Теләй абзый, хикәятен төгәлләп.

Тар урам буйлап җилдереп барган Ак кашка, пошкырып, Көнчыгыш капка янына килеп туктады. Без эчке шәһәрдән чыгып җиттек.

X гасыр башларында төзелеп, XIII гасыр урталарына кадәр яшәгән дәүләт.
Алмыш — X йөзнең беренче чирегендә идарә иткән хан.
Күз уңында тоту — игътибар үзәгендә тоту.
Би — түрә, хуҗа.
Хәлифә — Пәйгамбәр урынына калган рухани башлык (патша).
Пәйда булу — барлыкка килү.
Шөһрәт — дан.

ГАДЕЛ КАЗЫЙ

Безнең «Дәү Шир»гә сокланып карап торуыбызны күреп, Теләй абзый:

— Тышкы шәһәрдәге кәрвансарайны бигрәк яраттыгыз, ахры, — диде.

— Әйе шул…

— Эчке шәһәрдәгесе халык телендә «Таш йорт» дип йөртелә. Элек аның урынында агач кәрвансарай торган. Соңрак таштан яңасын төзегәннәр. Ул гүзәл йортны икенче килүегездә карарсыз. Бүген өлгермәдек. Олуг шәһәрнең кунакларга күрсәтерлек урыннары җитәрлек шул, шөкер…

Теләй абзый дөрес әйтә.

Ярар, «Таш йорт» дигән кәрвансарай белән башка вакытта танышырбыз. Бүгенгә «Дәү Шир»не күрүебез дә җитеп торыр.

Сугару — су эчертү.
Казый — хөкем итүче, судья.
Бәян итү — аңлату, сөйләпязып бирү.
Думбра — чирттереп уйнала торган ике кыллы, өчпочмак яки ярымтүгәрәк формасындагы корпуслы халык уен коралы.
Яран — ярдәмче, булышчы.
Әхлаксыз —

Безгә таныш, без яратып өлгергән мәһабәт кәрвансарайның гөмбәзсыман түбәсендә кояш нурлары җемелди. Озак карап торсаң, күзләр чагыла. Бина шундый биек, хәтта башыбызны югары чөеп карыйбыз.

Теләй абзый безне кәрвансарайга дәште.

Барыбыз да вак таш түшәлгән юлдан ишегалдына үттек. Кое янындагы улактан су алып, Ак кашканы сугардык. Үзебез дә тамак ялгап алдык. Аннары, яшел чирәмгә утырып, Теләй абзыйга текәлдек. Аның хикәятләрен тыңлау бик рәхәт.

— Элек Биләрдә Ягъкуб бине Ногман дигән бик гадел казый яшәгән…

Шунда Шәмсираван:

— Аның турында мин дә беләм, — диде.

— Ә-ә-ә, шулаймыни? Әйдә соң, алайса, бергәләп бәян итик. Ярыймы?

— Ярар, Теләй абзый…

— Менә шул Ягъкуб башта ерак Нишапур шәһәренә китеп, югары белем алган. Укуын тәмамлагач, туган иленә әйләнеп кайткан.

— Аннан Ягъкуб абыйны казый итеп куйганнар…

— Зирәк хан Ягъкубның акыллы киңәшләренә һәрвакыт колак салган.

— Әткәй әйтә, гыйлем йортын казыйның тәкъдиме белән ачканнар, ди.

— Әйе, Шәмсираван. Ягъкуб анда тарих фәнен укыткан. Атаклы «Болгар тарихы»н ул язган ич. Бу китапны «Казый китабы» дип йөртәләр. Халык Ягъкубны «гадел казый» дип хөрмәт иткән. Гарәп сәяхәтчесе әл-Гарнатины беренче килүендә шәһәр буйлап гадел казый үзе озатып йөргән, диләр.

— Әл-Гарнати казый йортында яшәп торганмы?

Сорауны энем бирде.

— Юк, Айтимер. Ягъкуб аны Әбүбәкер атлы сәүдәгәр йортына урнаштырган. Аның берничә йорты булган.

— Казый белән сәяхәтче ни турында сөйләштеләр икән?

— Дингә кагылышлы мәсьәләләр турында сөйләшкәннәрдер. Икесе дә дин белгече булган ич. Әл-Гарнати казыйдан бик күп мәгълүматлар да алган, диләр.

Монысын сөйләргәме-юкмы дигән шикелле, Теләй абзый тамак кырып алды. Бер сәбәпсез Ак кашкага чөңгерде. Теләй абзый нидер әйтергә теләде, ләкин әйтмәде. Шулай да, бераз торгач:

— Гомеренең соңгы көннәрендә Ягъкуб казый базарда думбра чиртеп тамак туйдырырга мәҗбүр булган бит, — диде.

— Нигә?!

— Ханга каршы чыкканы өчен гадел казыйның күзләрен сукырайтканнар, телен кискәннәр…

— Ничек?!

— Ауга йөрүне, күңел ачу мәҗлесләрен яраткан Хисам Анбал хан ил белән идарә итәргә вакыт тапмаган. «Дилбегә»не үзенең яраннарына тапшырган. Шул эре җирбиләүчеләр игенчеләрне җәберли башлаганнар. Мөселманнар әхлаксыз ханга каршы ризасызлык белдергәннәр. Гадел казый Болгар иленең рухание һәм атаклы мөгаллиме буларак чыгышлар ясаган. Үзенең канәгатьсезлеген

тәртипсез, әдәпсез.
Рухани — дин башлыгы.
Мөгаллим — укытучы.
Оҗмах — җәннәт; рәхәт, күңелле яши торган урын; рәхәтлек патшалыгы.
Хөкемдар — патша, хан, ил башлыгы.
Вәхши — явыз.
Фаҗига — зур кайгы, бәхетсезлек.
Вазифа — үтәлергә тиешле эш, өскә йөкләтелгән бурыч.
Әһел — нинди дә булса оешма, эшчәнлек өлкәсенә караган кешеләр төркеменең берсе, вәкиле.
Җәбер-золым — изү.
Чыгырдан чыгару — бик нык ачуландыру; ярсытып, үз-үзен тота алмый торган хәлгә китерү.
Сәед — хөкемдар, аксөяк; Мөхәммәд пәйгамбәр нәселеннән булган кеше.
Мәгънә — әһәмият.
Изге — гаделлек, азатлык өчен алып барыла торган; гадел.

ханга язмача да белдергән, телдән дә әйткән... Бу — ханга ошамаган.

Теләй абзый авыз эченнән генә дога укыды. Ахырдан:

— Гадел казыйның урыны оҗмахта булсын, — диде һәм дымланган күзләрен кул аркасы белән сөртеп алды.

Без барыбыз беравыздан:

— Амин! — дидек.

— Әйе, балалар, ил башында утырырга гадел хөкемдарлар кирәк шул, Хисам Анбал кебек вәхшиләр түгел, — дип, Теләй абзый әл-Гарнатиның икенче тапкыр килүендә булган фаҗигане сөйләде.

Әл-Гарнати Болгар иленә унҗиде елдан соң тагын килгән икән. «Мөхәммәд Бакирия»дә укырга калган Идрис атлы углы бу вакытта, укуын тәмамлап, туганлык оешмасында җитәкче вазифасын башкарган. Оешманың эшен Ягъкуб казыйның оныгы Давыт башлап җибәргән булган. Оешма әһелләре яуга, байлыкка табынуга, җәбер-золымга, ялганга каршы өндәмәләр белән чыкканнар. Бу хәл ханны чыгырыннан чыгарган. Аның иярченнәре Идрисне тотып алып, башта җәзалаганнар, аннары үтергәннәр.

— Тарих кабатлана-а-а, — диде Теләй абзый, көрсенеп. — Гадел казый белән булган фаҗига кабатланган...

— Әтисе ул вакытта Биләрдә булганмы? — дип сорады энем.

— Бу фаҗига әл-Гарнати килер алдыннан булган. Болгар иленә юлы төшкән сәяхәтче монысында шәһре Болгарда туктап калган. Ягъкуб казый урынындагы Сөләйман атлы сәед аны кечкенә генә бер агач өйгә урнаштырган.

— Нигә Биләрнең үзенә килмәгән?!

— Чөнки бу вакытта сәүдәгәр Әбүбәкер дә Биләрдә яшәмәгән инде, Ягъкуб казый да исән булмаган. Хан иярченнәре тарафыннан сәяхәтченең тормышына да куркыныч янаган. Биләргә килүдән мәгънә булмаган.

— Углы турында ничек белгән соң?! — дип сорады Белемчәк.

— Идриснең үле гәүдәсен әтисе тукталган теге өйгә китергәннәр. Җыелган халык менә сәяхәтче егълый-үкси башлар дип көткән. Әл-Гарнати бары тик: «Ул бу тормышта изге эш артыннан йөреп, Аллаһы Тәгалә теләге белән китеп барды», — дигән...

Шушы вакыйгалардан соң Болгар иленең пайтәхете булган шәһре Биләр гарәп сәяхәтчесенең йөрәгенә төзәлмәслек яра булып кереп калган.

ШАГЫЙРЬ КОЛГАЛИ

— Шәхесләр халык хәтеренә төрлечә кереп калалар. Ягъкуб казый гаделлеге һәм фаҗигале язмышы белән мәңге онытылмас. Колгали мәшһүр шагыйрь булып истә калыр. Кемдә нинди язмыш... — диде Теләй абзый.

— Колгали абый Биләрдә яши ич, — дип сүзгә кушылды Шәмсираван. — Ул — хан оныгы икән. Бездә аның нәсел агачы да бар. Үзебезнең шәҗәрәне дә яттан өйрәнә башладым.

Күрче бу Шәмсираванны! Белмәгәне юк — «теле ачылды». Шагыйрь абыйның нәселен тасвирлый да башлады.

— Карт бабасының атасы — Илһам хан. Карт бабасы Габдулла

Колгали (1183-1236) — болгар-татар шагыйре, татар язма әдәбиятына нигез салучы, мәшһүр «Кыйсса-и-Йосыф» лиро-эпик поэмасының авторы.
Шәҗәрә — нәсел-ыруның кемнән башланып, ничек тармакланып китүен

хан Биләрдә кырык җиде ел хан булып торган. Галимбәк бабасы шәһре Кашанда имам вә мөдәррис булган. Колгали абыйның атасы Мирхаҗи Кашаннан Зәй тамагына күчеп киткән. Бараҗ ханда имам булып торган. Колгали абый Харәземгә барып белем алган. Шунда шәкертләр укыткан. Аннары атасы йортына кайткан. Шуннан соң Биләргә килеп төпләнгәннәр...

— Афәрин, афәрин! — диде Теләй абзый, Шәмсираванны мактап.

Шәмсираван сүзен дәвам итте:

— Колгали абыйның углы Миргали дә, әтисе кебек, Харәземдә укыган. Шунда мөдәррис булып калган. Шагыйрь абыйның онығы Мирсәет тә галим буласы икән. Әткәй шулай, ди.

— Бабасына охшаса, галим дә булыр, шагыйрь дә булыр, — диде Теләй абзый, аның сүзенә мөһер баскандай. — Әмма укып кына шигырь язып булмый. Ул сәләт Аллаһы Тәгаләдән бирелә. Шәкертләргә дә шигырь төзелешен фәннең төрле тармакларын, гарәп һәм фарсы телләрен камил үзләштергәннән соң гына өйрәтәләр. Чөнки каләм иясе тирән гыйлемле булырга тиеш. Ныклы белем фикерләүне киңәйтә, кеше дөньяны киңрәк күрә башлый...

Гыйлем алу турысында нәкъ безнең әткәй сүзләрен сөйли бу Теләй абзый. Әткәй дә, белемле булу — мөселманның төп бурычы, ди. Дин белеме дә, дөньяви белем дә кирәк, ди.

— Миңа әткәй Йосыф пәйгамбәр турында да сөйләде. Аның нәселендә дүрт пәйгамбәр булган. Әткәй әйтте, пәйгамбәрләр — Аллаһы Тәгаләнең илчеләре, диде. Кешеләргә дини белемнәр өйрәтү өчен җибәреләләр, диде.

— Әйе, Шәмсираван. Йосыфның карт бабасы Ибраһим пәйгамбәр бер Аллаһка иманга беренче булып өндәгән. Йосыфның бабасы Исхак пәйгамбәр дөм сукыр булган, ә атасы Ягъкуб пәйгамбәр озын буйлы, көчле-куәтле, күркәм холыклы булуы белән аерылып торган.

— Әткәй әйтте, Колгали абыең, Йосыф пәйгамбәргә багышлап, бөек әсәр иҗат иткән, диде. Агалары, хөсетләнеп, Йосыфны коега салганнар. Углын югалту кайгысыннан егълап, Ягъкубның күзләре сукырайган. Әткәй шуларны сөйләгәндә, мин дә егъладым. Соңыннан Йосыф гадел падишаһ дәрәҗәсенә күтәрелгән, әтисенең дә күзләре ачылган. Нинди шатлык! — диде Шәмсираван.

күрсәткән схема, нәсел агачы.
Нәсел — бер бабадан килә торган кешеләр буыны, ыру.
Кашан — болгар шәһәре.
Мөдәррис — югары уку йортларында дәрес бирүче; мәдрәсәдә өлкән укытучы.
Мөһер — печать, штамп.
Пәйгамбәр — Аллаһы Тәгаләнең илчесе; Аның теләген, ихтыярын кешеләргә алдан хәбәр итүче һәм төшендерүче изге зат.
Хөсетләнү — көнләшү.
Егълау — елау.
Падишаһ — патша.

ПАЙТӘХЕТ

Тышкы шәһәрдән чыгып җиттек. Теләй абзыйның ат арбасына без шушы урында утырган идек. Инде арбадан төшәр вакыт җитте. Ат хуҗасыннан риза булуыбызны белдереп, Сусылу апаның күчтәнәчләре төрелгән ике төенчекне кулыбызга тоттык та җәяүләп кенә атламакчы булдык.

Теләй абзый, юлын үзгәртеп, үзләре яшәгән Салкын Чишмә авылына, бераз урау булса да, безнең авыл аркылы кайтырга уйлаган булып чыкты. Без кабат ат арбасына менеп чүмәштек.

— Әйдә-ә, малкай!

— Әйдә-ә, бахбай!

Ак кашка кузгалып китте.

Чүмәшү — тезләрне бөгеп, аяк очларына басып утыру, чүгәләү.
Җор — сүзгә оста.
Шатранҗбаз — шахматчы.
Кыбырсу — тынычсызлану.
Тугра — герб.
Барыс — мәчесыманнар семьялыгыннан урта зурлыктагы

— Исән-сау гына кайтып җитик, балакайлар. Кайткач, барыбыз да ял итәрбез. Иртәгесен малайлар арасында шатранҗ ярышын башлап җибәрәсебез бар. Бу уен фарсыча «шаһ үлде» дигән мәгънәне белдерә. Менә шушы уенны безнең күрше малайлары бик оста уйныйлар. Тәмәйнең башы әйбәт эшли. Өстәвенә үзе җор телле. Булдыклы бала икәне әллә каян күренеп тора. Иң күп җиңүчесе — Чук. Аның уңышлары бик мул. Аңа тиңләшүче әлегә күренми. Күз тимәсен үзенә. Мәмил белән Канакның уйнаулары бер чама. Әмма ләкин уенның тәмен белеп уйныйлар. Углым Белемчәк тә бу уенның серенә төшенергә омтыла. Әйе, һәр эштә тырышлык кирәк, углым. Кунак җегете Шәмсираванны әйтәсе дә юк. Сөяктән эшләнгән матур сыннарны кирәкле шакмаклар буенча күчереп, гаҗәеп акыллы йөрешләр ясый. Ул — иң шәп шатранҗбаз! Үзен бу уенда минем урынга казый итеп куярлык. Чөнки казый белемле һәм гадел булырга тиеш.

Теләй абзый уенчы малайларның һәрберсенә шулай гадел бәя биреп чыкты. Энемнең күңеленә «корт» керде, ахры. Уенны өйрәнергә теләген белдереп кыбырсый башлады. Теләй абзый, аны тынычландырып, «Кунакка килерсез, уйнарга өйрәтербез», — диде. Сусылу апаның углы Айдаш та энемнең алдына уен сыннары тезеп куйган иде ич. Димәк, Айдаш та уйный белгән…

Келтер-келтер… Келтер-келтер… Арба тәгәрмәче келтерәвен белде.

Менә Ак кашка авыл урамына килеп керде. Кинәт кенә бүген тамаша күрсәткән малайлар исемә төште.

Теләй абзый да ишетерлек итеп:

— Күңел ачу мәйданында Албарс малайларга уен уйнатты, — дидем.

Мин Теләй абзый «Афәрин!» дип мактый башлар дигән идем.

Ул, көтмәгәндә:

— Олан бик мәгънәле исемгә ия икән, — дип куйды. Аннары бу исемнең «алып барыс» һәм «баһадир барыс» дигәнне белдерүен аңлатты. Сүзен дәвам итеп:

— Безнең туградагы барыс рәсеме — муллык, дәрәҗә, көч билгесе. Барыс елында уңыш та мул була. Күзәтүләрдән чыгып әйтәм, — диде.

— Мин «барс»лы малайларны беләм, — диде энем Айтимер.

— Әйдә, әйтеп багыйк, — дип, аны Шәмсираван ярышка чакырды.

— Ярар. Мин туктасам, үзең санап бетерерсең, — диде энем.

— Ярар.

— Башлыйм, алайса. Акбарс, Айбарс, Бибарс, Барсби, Барсхан, Барсбуга, Барсбай, Бикбарс, Лачынбарс, Яубарс, Албарс…

Энем үзе белгән малайларны әйтеп чыкты да туктап калды.

Аннан Шәмсираван санарга кереште:

— Байбарс, Янбарс, Колбарс, Ханбарс, Алыпбарс, Ишбарс, Килбарс, Котлыбарс, Юлбарс, Ямьбарс, Туйбарс…

Шәмсираван да төртелеп калды.

Шатлыгы йөзенә чыккан энем:

— Икебезнеке дә бертигез! — дип кулларын чәбәкләде.

— Чанбарс, Илбарс… Болары — бик борынгы бабаларыбыз. Барыс елында туган ир балаларга «Барс» атын кушалар, — дип,

ерткыч хайван; чуар юлбарс.
Багу — карау.
Сөйкемле — ягымлы, мөлаем; яратып караттыра торган.
Сөрмә — чәч, каш, керфек каралта торган буяу.
Тамга — имза ролендә йөри торган һәм берәр шәхес, ыру, кабиләнеке дип танылган шартлы билге.
Ал (тамга) — патшаныкы.
Кабилә — үзара кардәшлек мөнәсәбәте, уртак тел һәм гореф-гадәт белән бәйләнгән, бер үк җирдә яшәүче кешеләр төркеме.
Болгар — урта гасыр Идел буе Болгар дәүләтендәге шәһәр.
Хәзинә — дәүләтнең акча, җир, азык продуктлары яки башка байлыклары җыелмасы; дәүләт милке, байлык.
Кургавыл — ханның шәхси сакчылары.
Артыл — хан гаиләсен саклый торган гаскәр.
Ибраһим — XI гасырның беренче чирегендә һәм XII гасырның икенче яртысында хакимлек иткән болгар ханнарының исеме.
Сәлим һәм Илһам ханнар — сәргаскәрләр; Габдулла ханнан соң Биләрдә яшәп хакимлек

Теләй абзый ярышны төгәлләде һәм: — Афәрин, Айтимер! — дип өстәде. Шул ук вакытта, яратып, Шәмсиравага карап алды. Шәмсираван — сөйкемле малай — матур итеп елмайды. Аның бит алмасы алсуланып китте.

Әле генә игътибар иттем. Шәмсираванның озын керфекле кара күзләре нәкъ сөрмә тарткан кебек икән. Аның күз карашыннан җылылык бөркелеп тора. Айдынбикә әбием өйрәткәнчә, «СубхәнАллаһ» дип куйдым. Гаҗәпләнгәндә яисә сокланганда, әбием шулай әйтергә кушты.

— «Барс»лы малайлар күп икә-ә-ән, — дип сузды энем.

— «Барс» — бик тылсымлы ул. Шуңа күрә безнең туграда да мөгезле алмачуар барыс сурәте тора бит. Чыгып килүче кояш җирлегендә бөҗра буенча атлаучы барыс.

— Әткәй, барысның мөгезе буламыни?!

— Углым, болгардагы барыс гади генә түгел, ә мөгезле. Мөгезгә ия булу бәхет, дәрәҗә һәм хакимлеккә ишарәли. Бу — аерылып тору билгесе. Гадәти түгеллекне аңлата. Мондый ышану борынгы заманнардан ук килгән. Болгарларның тугралары һәм ал тамгалары борынгы халык әкиятләрендәге батырлар белән тарихи бәйләнештә булган.

— Әткәй, нигә барысны сайлаганнар?

— Кызым, моның тагын бер сәбәбе бар. Болгар кабиләләре арасында барсиллар аерылып торган. «Барсил» сүзе «барыс иле», «барыс кешеләре» дигәнне аңлаткан. Барсилларга әйдәүче һәм җитәкче булу сәләте өстән бирелгән. Пайтәхеткә дә шулар нигез салган. Болгар ханнары, билгеле инде, шул кабиләдән чыккан. Шуңа күрә дәүләт туграсына ханнар барысны сайлап алганнар. «Болгар», «барсил» атамалары, Болгар һәм Биләр кебек, һәрчак янәшә йөргән. Бу ике шәһәрнең дә әле берсе, әле икенчесе пайтәхет булган ич. Пайтәхеттәге ханнар да бер-бер артлы алмашынып торганнар...

Теләй абзыйның: «Менә син дә, зур кеше булгач, шушында яшәрсең!» — дигән сүзе энемә көне буе канатланып йөрергә җитә калды. Әле хәзер дә, пайтәхет һәм ханнар тормышын беләсе килеп, сорау арты сорау бирә башлады.

— Теләй абзый, нигә дип капкаларны бикләп куялар?!

— Чөнки эчке шәһәрдә дәүләт хәзинәсе, бик күп байлыклар саклана.

— Ханны кем саклый?

— Аның сакчылары бар. Кургавыл — ханның, ә артыл хан гаиләсенең иминлеген кайгырта. Әмма һәркемне, иң беренче чиратта, Аллаһы Тәгалә саклый бит. «Сакланганны саклармын» дигән сүзен дә онытырга ярамый.

— Биләрдә ничә хан яшәгән соң?

— Ханнар турында «Болгар тарихы»нда язылган. Әткәй әйтте.

— Дөрес, Шәмсираван. Биләр Алмыш хан вакытында ук пайтәхет булган.

— Аңардан соң килгән ханнар?

— Ибраһим ханнар вакытында, мәсәлән, Биләр чәчәк атып яшәгән. Колгали абыегызның ярсу холыклы карт бабасы Биләрдәге болгар тәхетендә ярты гасырга якын утырган. Сәлим һәм Илһам ханнар аның заманында атаклы сәргаскәрләр булган ич. Беркем җиңә алмаган мон-

иткәннәр.
Һуннар — төрки кабиләләр берләшмәсе.
Нәфес — нәрсәне дә булса булдырырга көчле омтылыш; күпне өмет итү, комсызлык.
Күз кызу — кызыгу.
Җаек — Урал.
Сәйран — күңел ачып йөрү: гизеп, тамаша итеп йөрү.
Чат — ике яки берничә урам кисешкән урын; ике яки берничә юл кушылган яисә кисешкән урын.

голларны шулар тар-мар иткәннәр. Борынгы бабаларыбыз һуннарның һөҗүм ысулын кулланып, хәзерге Илһам хан шул чакта зур җиңүгә ирешкән. Өч өлешкә бүленгән гаскәрнең беренчесе, чигенгән кыяфәт ясап, монголларны җәлеп иткән. Калган ике өлештәге гаскәриләр, көтмәгәндә арттан һөҗүм итеп, дошманны чолгап алган. Исән калган монголлар, кайтып, Чыңгыз ханга беренче тапкыр хурлыклы рәвештә җиңелүләрен хәбәр иткәннәр.

— Әткәй, монголлар нигә монда килгәннәр соң?

— Нәфесләре зур. Безнең байлыкка күзләре кыза.

— Алар бүтән килмәсләрме соң?!

— Юк, углым, килмәсләр. Икенче килүләрендә болгар гаскәре аларны Җаек елгасында каршы алган. Аяусыз бәрелештә безнекеләр җиңелгәннәр. Ләкин монголлар Идел буйлап Болгар иленә күтәрелмәгәннәр, ә үзләренә кайтып киткәннәр. Өч ел элек исә монголлар Биләрнең үзенә үк килеп җиткәннәр. Агач дивар белән әйләндереп алынган, ике рәт биек туфрак өеме белән ныгытылган, алар алдында тирән итеп казылган киң чокырларны күреп, кире чигенгәннәр. «Без боларны барыбыр җиңә алмабыз», — дигәннәрдер.

Белемчәкнең йөзе яктырып китте. Без бер-беребезгә карап елмаештык.

Теләй абзый энем белән миннән:

— Апалы-энеле мосафирларның бүгенге сәйраннан күңелләре булдымы соң? — дип сорады.

— Бик күңелле булды, Теләй абзый. Сезгә Аллаһның рәхмәте булсын.

— Амин, шулай булсын, — диде Теләй абзый канәгать тавыш белән.

Барыбызга да күңелле булып китте.

Ак кашка да, мәхәллә мәсҗиден узып, чатка борылды. Аннары безнең урамга барып керде. Без өйгә кайтып җиттек.

Әдәбият

1. Әхмәтьянов Р. Татар терминологиясенең тарихи чыганаклары. — Казан: Татар.кит. нәшр., 2003.
2. Давлетшин Г.М., Хузин Ф.Ш. Булгарская цивилизация на Волге. — Казань: Татар. кн.изд-во, 2011.
3. Дәүләтшин Г. Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1999.
4. Измайлова С., Измайлов И. Булгарское вооружение X-XIII вв. Буклет.
5. Ислам (белешмә-сүзлек). — Казан: Татар. кит.нәшр., 1993.
6. Мифтахов З.З. Курс лекций по истории татарского народа. — Казань: Издательство «Дом печати», 1998.
7. Мөхәммәтшин Җ., Вәлиев Р. Бөек Болгар — болгар-татар цивилизациясенең һәйкәле. — Анкара, 2000.
8. Саттаров Г.Ф. Татар исемнәре сүзлеге. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1981.
9. Хәмзин К.З., Мәхмүтов М.И., Сәйфуллин Г.Ш. Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1965.
10. Хуҗин Ф. Биләр — Олуг шәһәр. — Казан: «Печатный Двор» типографиясе, 1997.
11. Хуҗин Ф. Җир астында серләр бар. — Казан: «Мәгариф» нәшрияты, 2008.
12. Хузин Ф. Биляр — Великий город. — Казань: Татар.кн.изд-во, 2007.
13. Хузин Р., Измайлов И. Волжская Булгария глазами живописца и историка. — Казань: Заман, 2011.
14. Яхин Ф. Пәйгамбәрләр тарихы. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1992.

Консультантлар — ***Солтан Шәмси,*** *язучы, Фатих Хөсни Һәм Абдулла Алиш премияләре лауреаты;* ***Фаяз Хуҗин,*** *тарих фәннәре докторы, профессор.* ■

ҖИРСУ

ФӘРИДӘ ХӘСӘНОВА,
филология фәннәре кандидаты, доцент,
Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының
татар әдәбияты белеме бүлеге мөдире

ШАГЫЙРЬЛӘР НЕЧКӘ КҮҢЕЛЛЕ БУЛА. Ә «НЕЧКӘ КҮҢЕЛ» ДИГӘН ТӨШЕНЧӘ, БАШЛЫЧА, ТУГАН ТЕЛ ЭЧЕНДӘ ЯШИ. ТУГАН ТЕЛ МИЛЛӘТ САКЛАНГАНДА ГЫНА ҮСӘ, КАМИЛЛӘШӘ, ТАРАЛА, НЫГЫЙ, МОҢЛАНА ҺӘМ, ШИГЫРЬГӘ ӘВЕРЕЛЕП, ТУГАН ҖИРДӘ ТАМЫР ҖӘЯ.

Менә шул шартлар «70 нче елгылар буыны» шагыйрьләренең «тыныч лириклар» (Т.Галиуллин билгеләмәсе) булып формалашуына китергәндер дә. Шундый «тыныч лириклар» арасыннан берсенең яңа гына басылып чыккан китабына бүген үзебезнең мөнәсәбәтебезне белдерик.

Роберт Миңнуллинның «И газиз якташларым!» [1] исемле саллы гына китабы, 5 бүлеккә бүленеп, 500дән артык битле булып чыккан. Китапның тышкы бизәлеше үк ярты эчтәлекне «сөйли» булса кирәк. Иксез-чиксез табигать фонынннан, «И газиз якташларым!» эндәшенә төбәлеп, ныклы адымнары белән, укучысына таба Шагыйрь килә. Аның алдында тигез юл, ә карашы тауларга төбәлгән. Ул яши торган өенә, эшли торган җиренә кайтып килә булса кирәк. Авторның әйтер сүзе төгәл: китап тулысы белән Башкортстанга һәм анда туып үскән шәхесләргә багышлана. Химаяче дә күрсәтелгән: ул Бакалы егете — Наил Баһаутдинов, «Уралтранснефтепродукты» җәмгыятенең генераль директоры. Бу затлы китап Мөдәррис Вәлиев җитәкчелек иткән хосусый «Мәгариф-Вакыт» нәшриятында чыккан.

Китапны «Кызыл таң» газетасының баш мөхәррире Фаил Фәтхетдинов ачып җибәрә. Әлеге кереш сүзнең китаптагы бар материалны иңләп алырлык тыгыз эчтәлекле, максатчан, дәлилле язылган булуын әйтергә кирәктер. Ике халык өчен уртак булган 60лап шәхес исеме аталу үзе генә дә язманың мәгълүмати чикләрен киңәйтеп җибәрә.

Шагыйрь үзе сүзен Судан башлый, дөресрәге, Сөн елгасыннан. Сөн елгасы аның өчен символик мәгънәгә ия. «Сөн кошы мин», дип белдерә ул. «Әнкәй безне Сөннән алып кайткан» җырының ике республика халкында популяр булу сәбәпләрен дә елганың уртадан агып ятуына кайтарып калдыра. Китапта авторның Сөнне яклап «көрәшүе» дә күренә. «Әнкәй безне Сөннән алып кайткан» дигән сүзләр өчен радио художество советының: «Сине Сөннән алып кайтмаганнар, тузга язмаган сүзләрне

без эфирга бирә алмыйбыз», — дип, җырның баштагы юлларын үзгәртергә тәкъдим итүе бүген көлеп кенә кабул ителсә дә, күңелдә юшкынын калдыра. Язмада Р.Миңнуллин ике халык өчен уртак моң, җыр, әдәбият-сәнгать төшенчәләренә басым ясый, бердәй якын булган күренекле шәхесләребезне барлый. «Сәлам, Башкортстан!» исемле язманың укучы өчен күп мәгълүмат бирә алырлык, ике милләтнең дә горурлык хисен арттыра торган материал икәнен күрсәтү дөрес булыр.

Һәр татарның җиде буын бабасын белергә тиешлеге беркемдә дә шик тудырмый. Безнең автор да укучыга үзенең нәсел агачын тәкъдим итә. Шулай да игътибарлы укучы бу «агач»та заман җилләре тәэсирен дә тоймый калмас. XVIII-XIX гасырларда куе булып үсеп киткән ботакларның XX гасыр ахырына шактый сирәгәюе күренә. Биредә тагын бер символ — «Илеш» сүзе килеп керә. Илеш — шагыйрь өчен «өлешенә тигән көмеш» кенә түгел, ул — илһам чыганагы булу белән бергә, җиде буынлы нәселнең башлангычы да икән. Шул рәвешле, шагыйрь үзенә исеме мәгълүм бабасының исеме Илеш булуын раслый.

Китапның кереш өлеше укучыга шундый кызыклы мәгълүмат бирә. Бай табигать кочагында үскән кешенең рухы көчле булачагына ышанып, беренче бүлекне укуга кучәсең...

Р.Миңнуллин үзенең бу җыентыгына башка китапларыннан да өзекләр керткән. Әнкәй турындагы язмалары — шундыйлардан. Биредә автор алдагы язмаларына бәя дә биреп китә, үзбәясе дә күренә, тәнкыйтьчеләрне дә игътибарсыз калдырмый. Ул үзенең әсәрләрен аерып куймый, бәлки башка шагыйрьләрнең Ана образы белән бәйле әсәрләре исемнәрен атый, аларга үзенчә соклана, бәя бирә. Шул рәвешле, үз әсәрен гомумтөрки әдәбият эчендә күрә, остазларын барлый, теманың дәвамчанлыгын күрсәтә, әсәрне тормыш вакыйгалары белән бәйлелектә күзәтеп бара. Ана образын Әмирхан Еникинең



«Матурлык» хикәясеннән башка күз алдына китермәвен яшерми. Р.Миңнуллин язмаларында шундый бер үзенчәлек сизелә: ул үз әсәрен шул дәрәҗәдә оста итеп тәкъдим итә ки, теге яки бу язучының әсәре турында сөйләгәндәй булып, сиздермичә генә, укучыны үз язмасы эченә «кертә дә куя». Әни турындагы язмалары укучының күңел төпкелендә яшеренеп яткан хисләрне актарып чыгара да күздән яшьләр китерә. Бу бит «Ана музее!» дип сокланырга гына кала — шул рәвешле авторның сентиментальлеге аклана.

Табигый, әнкәй турындагы язмалар шигырьләр белән көчәйтелә. Хисләр авторның бүгенге халәте икәнлеге исбатлана, шигырьләрнең язылу даталары 2010-2011 еллар икәнлеге күрсәтелә. Аларга татарның башка шагыйрьләре дә «кереп китә», шул рәвешле Шәүкәт Галиев, Рәдиф Гаташ, Нурмөхәммәт Хисамов, Ирек Киньябулатов, Нәҗип Асанбай исемнәре белән тулыланып, гомуми Ана образы килеп чыга. Ә бала образына килсәк, *«Кайтып керсәм, бер сабыйга әйләнәм дә куям мин. Үземне нәкъ алты яшьлек малай итеп тоям мин»*, дигән сүзләр — моның ачык мисалы.

Чираттагы «Без биш бала үстек...» исемле истәлекләр бик җанлы итеп языл-

ган. Аларны укып, зур шагыйрьлеккә юлның сикәлтәле булуын да, кырыс совет чынбарлыгын, балачак юләрлеген дә белергә була. Материаль җитешмәүчәнлек хөкем сөргән елларда, сабыйлык шуклыгы белән абзар кадәр абзар яндырган малайга «талчыбык төшмәве» ышандырмый да кебек. Ә Ананың «мәрхүм Совет дәүләте» метафорасы, бердән, үткен сатираны белдерсә, икенчедән, шагыйрьнең чишмә башына ишарә ясый. Шагыйрь анадан шагыйрь бала туган. Мәкальдәгечә: алмагачның алмасы...

Ишле гаиләнең һәрбер кешесе шигырьләрдә урын алган: ата да, энекәшләр, сеңел дә. Китаптагы язмалар баланың үсү тәртибендә бара. Шул рәвешле, мәхәббәткә дә килеп җителә. «Мәхәббәт публицистикасы» юмор катыш язылган. Уйнап кына әйтелгән юллар җиңел укыла, гомер буена сузылган бер мәхәббәт тарихы гаҗәпләндерә. Аны немец композиторы Роберт Шуман һәм аның хатыны Клара белән дә бәйләгәч, киләчәктә кем тарафыннандыр язылу ихтималы булган классик сюжет шәйләнә башлый. Китапта, алдан билгеләнгән тәртип буенча, гомерлек яр булган Кларага атап язылган өч шигырь дә урын алган.

Р.Миңнуллинның мәхәббәт лирикасы — һәрвакыттагыча тыныч, бер дә ярсулы түгел, интим хисләр тышка ташып чыкмый, әрсезлекнең мыскалы да булмаган үзгә шагыйрь мәхәббәте. Ул үзе дә «бер тамчы да үзгәрмәдек», дип юкка гына язмыйдыр. 46 ел буена бит!

Китапны һәрдаим гаилә фотолары тулыландырып бара. Аларда, туганүскән өйдән алып, халык шагыйренә кадәр үткән юл, шәхесләр, вакыйгалар урын ала. Әмма Ана янында һәрвакыт Р.Миңнуллин басып тора, югыйсә, берәр фотода калган өч улның берәрсе дә була ала бит. Юк, күрәсең, бу урын аңа тәгаенләнгән. Китапны укучы күп кенә фотоларда Рәдиф Гаташны күреп тә җанланып китәр. Башкортстан җирен ул да Р.Миңнуллиннан ким яратмый дип беләбез. Аның исеме текстларда да еш очрый һәм бу табигый дә.

Китапның икенче бүлеге «Мостайлык. Осталык. Остазлык» дип исемләнгән. Бу зур булмаган язмада башкорт язучысы Мостай Кәримнән тыш төрки әдәбиятның башка күренекле вәкилләре дә урын алган. Биредә дагстанлы Рәсүл Гамзатов, кыргыз Чыңгыз Айтматов, рус әдәбиятының Евгений Евтушенкосы, Андрей Вознесенские да күренеп китә. Билгеле, татарның Муса Җәлиле, Сибгат Хәкиме, Аяз Гыйләҗевы, Гариф Ахуновы, Равил Фәйзуллины, Ренат Харисы, Мөдәррис Әгъләме дә бар. Шагыйрь остазы Мостай Кәримгә өч язма багышлый. Р.Миңнуллин мондый истәлекләрендә остазларын төрле яклап ачарга омтыла: әдәби, мәдәни һәм кеше факторы буларак. Шулай ук өч шигырь тәкъдим ителә. Аларның берсе мәдхия характерында булса, икенче шигырь дә панегирик жанрда язылып, Мостай Кәримне Чагыл тавы янәшәлегендә тасвирлауга нигезләнә, ә өченче шигырьдә язучы Урал бөркетенә тиңләнә, әйтелгән фикерләр аның Татарстандагы шәкертләре янәшәсендә төшкән фотолары белән ныгытылып барыла. Чагыл тавы — Башкортстан ландшафтының аерылгысыз атрибутыдыр, күрәсең, ул китаптагы текстларда еш кабатлана.

Нәҗәр Нәҗми шәхесенә шулай ук зур урын бирелгән. Автор аны, «Казанны алган Нәҗәр!» дип атап, Тукайның «Туган тел»еннән соң, татар җанына шифалы дәва булырлык «Татар теле» шигыре иясе дип саный. Биргән олы бәясен күпсанлы мисаллар белән ныгыта. «Юкка түгел, юкка түгелдер», «Син — гомер агышларым!», «Сиңа тагын мин бер киләм әле», «Уфа юкәләре»нең татар халкының да популяр җырларыннан икәнен билгеләп үтә. Р.Миңнуллин җыр текстлары янәшәсендә композитор һәм башкаручыларны да атап бара. Шул рәвешле, китапта Фәридә Кудашева, Рим Хәсәнов, Фидан Гаффаров, Резеда Әхияровалар исеме дә урын ала. Авторның икенче язмасында «Нәҗәр

Нәҗми — башкорт әдәбиятының бәхете» дигән фикер куәтләнә. Олы исемле шагыйрьләрнең озын-озак тормыш юлы үтүен дә игътибарсыз калдырмый. Наҗар Нәҗминең татар әдәбиятында тере легендага әйләнүен әйтә.

Шул үзенчәлекне игътибарсыз калдырып булмый: Р.Миңнуллин шәхесләр турында язганда, башта истәлек характерындагы материал бирә, икенчесе исә проза белән язылган мәдхия була. Аның мәдхияләре аерым бер шәхескә генә кагылмый, башкорт һәм татар әдәбиятларын да иңли, исеме аталган шәхеснең каләмдәшләрен барлый, рус әдәбиятына да «кереп чыга», шул чорның сәясәтен дә өсти, билгеле исемне бүгенге вазгыятькә «утыртып та куя». Автор, шәхесләрне сайлаган вакытта, һәр ике халык вәкилләрен тигез рәвештә алып бара.

Фәридә Кудашевага багышланган язмалар да үзләренең шигърилеге, ихласлыгы белән җәлеп итә. Ә менә Әмирхан Еникигә килеп җиткәч, язмаларны бирү формасына үзгәреш керә. «Әйтелгән васыять» ике кешенең әңгәмәсе итеп эшләнгән. Автор үзе дә биредә бик җитди, сораулары уйланылган, язучыны шәхес буларак ачуга юнәлтелгән, шул ук вакытта авторның бу әңгәмәгә зур гына әзерлек белән килүе дә сизелә, озын гомерле кешеләргә хөрмәте дә чагыла. Шунда ук Әмирхан Еникигә мәдхия һәм мәрсиясе дә урнаштырылган.

Ә Р.Миңнуллинның «Әмирхан ага Еникигә» шигыре, багышлама характерында язылып, күтәренке рухлы, чагыштырмача купшы стильдәге мәдхияне хәтерләтә. Шигырьдән авторның Ә.Еникигә булган хөрмәте, соклануы, ихтирамы ачык чагыла. Р.Миңнуллинга хас юмор да читтә калмаган. Шагыйрьнең юморы язучыга «иптәш морза» дип дәшүдә, «морзалыгың йокмасмы, дим, синең янда торсам...» дип шаяртуында күренә. Автор Еникине «данлы», «затлы», «асыл», «олпат», «галиҗәнап» эпитетлары аша сурәтли. Р.Миңнуллин шигырьдә морзалык тарихына да басым ясый: *«Булган татар тарихында / Күпме алыш-биреш. / Морзалар киткән урыска... / Дәрәҗәле килеш»*. Шигырьдә татар халкының югары катламы рус халкы белән кушылу нәтиҗәсендә югалтылган рухи һәм матди байлыкларга ишарәләр дә сизелә.

Ә.Еники исеме Р.Миңнуллинның тагын өч шигыренә килеп керә. Аларның берсе «Уфадагы дусларым» шигыре булса, икенчесе — «Халык язучысы Әмирхан Еникигә» дип исемләнгән эпиграмма. Соңгысында шагыйрь, Еники әсәрләренең теленә мөрәҗәгать итеп, аларны «саф татарча милли көй» дип атый. Ә өченчесе — Ә.Еникине озатып кайткач язылган, сентименталь пафос белән сугарылган «Еникине дә озаттык» исемле мәрсия. Биредә шагыйрьнең бик моңсу халәте сурәтләнгән. Еники киткәч, кояшлы көн дә төнгә охшап калды, күңелләр кителгән кебек булды, — дип юксына автор. Моңсу хиснең сәбәбен шагыйрь «көтелмәгән югалту» буларак билгели. Әлеге шигырь сыктау жанрының бар сыйфатларын үзенә туплый алуы белән дә үзенчәлекле килеп чыккан.

Китапның эченә керә барган саен, күңелне шундый уй биләп ала: татар әдәбиятының иң күренекле вәкилләре Башкортстан җиреннән чыккан ләбаса. Күрәсең, аларга туганда ук илһам чишмәсенең суын эчәргә насыйп булгандыр. Бу кадәр гади, сыгылмалы тел белән моңны алар түкми-чәчми генә Татарстан җирлегенә ташый булса кирәк. Бу рухи байлыкның зурлыгына хәйран калырлык: үлчәү тәлинкәләре тигез, татар күпсенми генә ала тора, башкорт санамый гына җибәрә.

Нәкый Исәнбәтне автор «Баһадир!» дип атый. Аны ул өч гасырны бергә тоташтыручы дип, күптөрле эшчәнлеген саный, 90 яшенә соклана, «соңгы мамонт», «соңгы могикан», «биек тау» дип атый. Авторның 80 яшьне узып киткән язма геройларына ихтирамы чиксез икәнлеге һәрдаим күренә.

Әнгам Атнабай шигырьләре турында язганда, Р.Миңнуллин сыйфат-

ларны кызганып тормый. Шунысы гаҗәп: әлеге фикерләр шагыйрьнең үз шигырьләрен дә характерлый. «Атнабай шигъриятенең серләрен эзлим. Беренче карашка, бер сере дә юк шикелле. Барысы да гап-гади, үтәли күренеп тора, бөтен сүзләре дә таныш. Шигъри бизәкләргә, метафораларга, чагыштыру-мазарларга исе дә китми, фикерне образларга төреп булашмый, табигать күренешләрен нечкәләп тасвирлауны да күрмәссең. Ахылдауга-ухылдауга корылган пафос та хас түгел аңа, мәхәббәт лирикасына хас төчеләнү дә, сентиментальлек тә күзгә ташланып тормый. Аның шигырьләре бөек көчкә — сүз көченә корылган. Дөресрәге, хис-эмоция көче, тапкырлык, җорлык көче ул. Халыкчанлык, тормышчанлык та шуннан киләдер, күрәсең», — дип яза автор. Нәкъ менә шул сүзләр белән аның үз шигырьләре дә характерлана. Язмадан бу ике шагыйрьне күп нәрсә берләштергәне дә күренә. Баксаң, әдәби очрашуларга гел бергә йөргәннәр икән. Гомумән, бу китапның буеннан-буена Ә.Атнабай исеме югалып тормый, башка шәхесләр белән бәйле рәвештә гел калкып чыга. Барый Ямалов Ә.Атнабай авылында рәис булган, Госман Садә башлангыч иҗатында Атнабайга охшатып язарга тырышкан һ.б.

Китапта Мирсәй Әмир дә үз урынын тапкан. Автор язма геройлары белән үз вакытында фотога төшәргә өлгергән. Шундый рәсемнәрнең берсеннән ак чәчле М.Әмир белән яшь Р.Миңнуллин карап тора. Автор соңгы елларда Башкортстанда туып үскән зыялылар белән күбрәк аралашкан булса кирәк. Шулардан берсе Нәҗип Асанбай турында 2011 елда мәдхия язылган булса, 2013 елда ук мәрсиягә чират җитә.

Олы иҗатлы татар шагыйре Илдар Юзеев турында күләмле генә язма урын алган. Р.Миңнуллин, шәхес турында язганда, һәрвакыт аның туган җиреннән башлый, шул рәвешле уңышның серен туган җиргә бәйләп аңлата. И.Юзеев белән янәшәдә остаз исемендә Гариф Ахунов, Шәүкәт Галиев тә атала. Тагын бер искитәрлек нәрсә: ул да булса, Башкортстан туфрагына баскан һәр кешене Р.Миңнуллин исәпкә алып барган кебек тоела. Югыйсә, Г.Ахунов — Арчада, Ш.Галиев Апаста туган бит.

«Туган тел җанлы» Хәсән Сарьян турында бик тәфсилле итеп язылган. «Нокталы өтер» повестеның дөнья күрү тарихы ачыкланган. Шәхесләр профессиональ сыйфатлары белән бергә, кеше буларак та күрсәтелеп барыла. Әхсән Баян «әдәбиятның курку белмәс рыцаре» исеме астында килеп керә. Автор Ә.Баянның «Заман сурәтләре» китабына рецензия һәм «Сиксән яшьлек шагыйрь була» исемле мәдхиясен урнаштыра, «Яшьлеген эзләүче шагыйрь» исемен дә бирә.

Бу икенче бүлек шактый күләмле, исемнәргә бай, ике халыкның әдәбиятсәнгатен иңли торган булып чыккан. Биредә шагыйрь, язучы, җырчы һәм драма артистлары, журналист, зур җитәкчеләр дә урын алган. Әлеге җәһәттән, китап шәп кенә белешмәлек ролен дә үти булып чыга. Һәрхәлдә, Туган як музееен төзер алдыннан, эшне башлап җибәрү өчен, менә дигән материал килеп чыккан. Хәзер төрле якташлык җәмгыятьләре туган якларына багышланган китаплар чыгара, тарихны барлый, шәхесләрне, төрле һәйкәлләрне тарихка кертеп калдыра. Бу җәһәттән Р.Миңнуллинның зур бер коллектив эшли торган эшне берүзе башкарып чыкканлыгын танырга гына кала. Китапка исеме кергән һәрбер шәхеснең автор белән теге яки бу бәйләнештә торганлыгы күренә. Димәк, истәлекләр каяндыр алып язылмаган, кичерелгән, күрелгән, баштан үткән. Шуңадыр, алар бик җылы кабул ителә, истә кала, ышандыра. Шагыйрь иҗатын белмәгән кеше, хәер, андыйлар булмас та: «Бу Р.Миңнуллин гел Башкортстан белән Татарстан арасында йөреп кенә торган, кешеләр белән очрашып, аларны өйрәнеп, күпме гомер уздырган, ә шигырь язарга кайчан вакыт тапты икән?» — дип гаҗәпләнер иде. Дәүләт

Советындагы эше турында әйтәсе дә юк инде! Бер үк вакытта каләмдәшләре иҗатына Р.Миңнуллин дәрәҗәсендә игътибарлы тагын кайсы язучы бар икән? Т.Галиуллин белән Р.Гаташтан башка кешене мин белмим. Ул әле шигырьне укып кына да калмый бит, мәсәлән, Госман Садәгә конкрет киңәшләрен дә бирә, фактик хаталарны билгели, сөйләм-стиль кимчелекләрен төзәтә.

Өченче бүлекне «Җирсү» дип исемләү дөрес булыр иде. Ул шагыйрь туган ягының чит ил курортларына биргесез икәнлеген раслый торган шигырь белән башланып китә («Бармыйм әле Фороска»), инде безгә таныш булган Сөн елгасы, Чагыл, Хан таулары белән исәнләшеп дәвам иттерелә, «Туган җир» исемле шигырьгә килеп җителә. Нәкъ менә шушы шигырендә Р.Миңнуллин әлеге китапны чыгару максатын белдерә булса кирәк. Безнеңчә, менә бу юллар әлеге фикерне раслый да: *«Һәммәбезнең туган җире / Изге җиргә тиң бит ул! / Әнкәм кебек берәү бит ул, / Әткәм кебек бер бит ул... / Мин кайтасы туфрак бит ул, / Мин ятасы җир бит ул!»*

Шагыйрь бу бүлектә ике халык арасындагы дусларын барлый. Олы шәхесләрдән Нил Юзиев, Нурихан Фәттах, Марат Кәримов кебекләргә мәдхия-мәрсияләрен багышлый. Галимҗан Гыйльманның әнкәсенә соклана. Янгантау, Каратау каеннарына, Юрүзән үзәненә шигырьләр багышлый, картиналар, музейлар турында яза. Соңгы елларда Германия күгендә һәлакәткә очраган самолёт язмышын да искә ала. «Башкортстан татарлары» исемле билгеле шигырен урнаштыра. Биредә «Илеш» һәм «кайтам» сүзләре еш кабатлана, игенчеләр, башка һөнәр ияләре булган авылдашлары — бар да шигырьгә кереп бетә. Әлеге бүлек «Курай булып кайтырмын» шигыре белән тәмамлана. Бу факт үзе үк символик мәгънәгә ия кебек. *«Курай күрсәгез, тыңларсыз! / — Ул курай мин булырмын»,* — дип, мәңгегә, яшәгән түгел, ә туган җиренә күбрәк тартылуын сиздерә кебек. Нишлисең, юкка гына халык мәкале «Чит җирдә мал да җирси», дип әйтми торгандыр. Шулай да, «Татарстан туфрагы шулкадәр үк чит микәнни?» дигән фикер дә туып куя. Өченче бүлеккә автор «Җирсү» исемле шигырен дә урнаштырган.

Дүртенче бүлекне без «Сәясәт һәм шагыйрь», дип атар идек. Бүлек, ике республика балалар газеталарының баш мөхәррирләре әңгәмәсеннән башланып, туган җир турындагы интервьюда дәвам иттерелә. Ул бик эчтәлекле килеп чыккан. Биредә тарих та, сәясәт тә, әдәбият-сәнгать тә урын алган, милли матбугат мәсьәләләре күтәрелгән, шагыйрьнең юбилейлары уңае белән үткәрелгән чараларга да әйләнеп кайтылган, җыр текстларына булган таләпләр ачыкланган, ике республика арасындагы әдәби мохит чагыштырылган. «Сәясәтче», «шагыйрь-сәясәтче» төшенчәләренә аңлатма бирелгән. Автор үзен «иң элек — шагыйрь, аннан соң гына — сәясәт белән шөгыльләнүче шагыйрь» дип тәкъдим иткән. Биредә аңа бирелгән мәртәбәле исемнәр, бүләкләр, шул уңайдан җәмәгатьчелектә туган фикер, вакытлы матбугатта әлеге вакыйгаларны яктырту максатыннан ясалган махсус репортажлар китерелгән.

Китапның бишенче бүлегендә материал күп түгел. Ул, нигездә, төрле мөнбәрләрдән ясалган чыгышлардан тора. Материалны бер идея берләштерә: башкорт белән татар арасы бик нык бәйләнештә, бу бергәлек һәр ике халык өчен дә файдага гына. Ул 2011 елда язылган «Уфа Тукайлы булырга тиеш!» дигән җөмлә белән тәмамлана. Әмма һәйкәл әле дә куелмаган...

Менә шундый китап тәкъдим ителә. Аның кыйммәте еллар уза барган саен арта барыр, җирсү хисенең тирәнлеген аңларга теләгән кеше китапка еш мөрәҗәгать итәр. Гомумән, яши торган, укыла торган китап бу.

Әдәбият

Миңнуллин Р.М. И газиз якташларым! — Казан: Мәгариф-Вакыт, 2013. — 504 б. ■

ТУКАЙ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕНӘ

Сәхифәне филология фәннәре докторы ЗӨФӘР РӘМИЕВ алып бара.

«Килер заман, һәр язучының үзен, сүзен вә шәхси тормышын инәсеннән җебенә кадәр тикшереп чыгарлар әле».

Габдулла Тукай, «Уянгач беренче эшем», 1913 ел, 14 март

КАЗАН АРТЫ, Татарстан Республикасының төньяк-көнчыгышындагы төбәк. Аңа Биектау, Дөбьяз, Әтнә, Кенәр, Арча, Балтач тирәсендәге авыллар керә. Тукайның туган авылы Кушлавыч та Казан арты төбәгенә карый. Җире аз һәм уңдырышсыз булганга, бу як авыллары Казан губернасының башка тарафларындагы татар авылларыннан фәкыйрьлек белән аерылып торган. Этнографик яктан әлеге төбәк чуар: монда марилар, удмуртлар, руслар, татарлар белән аралашып, дус яшәгәннәр һәм бу күренеш аларның яшәү рәвешендә дә эзсез калмаган. Әмма өч яктан да урманнар белән кысылган, җире аз татарлар һөнәрле булган, иген иккән, урман кискән, йорт-җир салу, каралты-кура торгызу, аучылык, умартачылык, сәүдә эшенә керешкәннәр, ил-җир күреп йөргәннәр. Булачак шагыйрьнең балачагы шушы төбәктә узган. Сабый чагында алган тәэсирләрен ул, еллар узгач, «Исемдә калганнар» (1909) автобиографик әсәрендә яктырта. Казан арты төшенчәсен Тукай бик яратып һәм шактый еш файдаланган. Мәкалә, очерк, хатларында ул аны ниндидер бер җылылык, сагыш белән, шигырьләрендә сызлану, сыкрану, ә кайчакта сатирик юнәлештә кулланган. «Шүрәле» (1907) әкият-поэмасының ахырында шагыйрь бу «Шүрәле» хикәясен Пушкин һәм Лермонтовларның шундый авыл җирендә сөйләгән хыялый хикәяләренә таянып яздым, дисә дә, чынлыкта ул кечкенә Габдулланың Кырлайда Сәгъди абзыйларда яшәгәндә күреп хәтеренә сеңдергән авыл табигате, аулак өйдә, кичке уеннарда, тула басу өмәләрендә ишеткән җырлар, такмаклар, иптәшләре сөйләгән тылсымлы әкиятләр тәэсирендә тудырылган. «Туган җиремә» (1907) шигырендә дә Тукай Казан артына мәдхия укый. Синдә мине фәкыйрьлекләр, ятимлекләр кысса да, ул заманнар төш кебек үтте инде, синдәге һәрнәрсә җанга якын, изге, ди. 1907 елның 30 декабрендә Казаннан Уральскига дусты Габдулла Кариевка юллаган хатында: *«Казанны вә туган җирем булган Казан арты авылларын күреп, күп гыйбрәтләр вә хиссиятләр алдым»*, — дип яза. 1912 елның 1 гыйнварында Өчиледән Казанга Әхмәт Урманчиевка язган хатында туганы Кәбир муллага кунакка кайтуыннан бик канәгать булса да, Казан арты авылларының артталыгына борчылып: *«Казанның арты бигрәк кара. Берничә авылга кереп күрдем. Бу якта һәркайда мәхәллә халкы мулланы авызлыклаган»*, — дип, укытуның түбән дәрәҗәдә алып барылуын хәбәр итә. «Казан вә Казан арты» (1912) шигыре дә шушы темага багышланган. Шагыйрь, Казан артының мәдәният-мәгърифәт ягыннан бик нык артта калуына җаны әрнеп, болай ди: *«Бер борыл да, и Казан, син бу Казан артын кара: / Нур чәчәсең бар өязгә, үз өязең кап-кара»*. 1910 елның 9 ноябрендә Казаннан С.Сүнчәләйгә җибәргән хатында, шигырьләрегездә төп халык телендә булмаган сүзләр очрый, аларны катыштырмасагыз икән, дип үтенә, Казанны «тәхте пай» (монда: татарларның үзәк каласы) итеп санаган хәлдә, милли әдәбиятыбызның

теле фәкать Казан арты татарларының телендә булуын телим, дип белдерә һәм: *«Казан арты татарларын шушы көнгә кадәр милләтен югалтмаган вә киләчәктә дә югалтмаячак төп халык»*, — дип саный.

Чыганак

Тукай Г. Биштомлык. Т.I. — Б.168, 171, 183, 359; Т.II. — Б.245, 380; Т.V. — Б.9-27, 81, 95, 112.

Әдәбият

Нуруллин И.З. Габдулла Тукай. — Казан, 1979. — Б.8-39, 123-127, 186-188, 244-250; Мәһдиев М. Шагыйрьнең бишеге // Казан, 1995. — №9-10. — Б.50-72.

МӘККӘ, Согуд Гарәбстанында Кызыл диңгездән 70 км ераклыкта урнашкан шәһәр, Хиҗаз провинциясенең үзәге, мөселманнарның изге хаҗ кылу урыны. Мәдрәсәләрдә дини тәрбия алган Тукай, әлбәттә, Коръән, хәдисләр, дини риваятьләр белән яхшы таныш булган. Мәккә шәһәрен ул әсәрләрендә изге урын буларак та, тормыштагы ниндидер күренешләрне юмор яки сатирик планда сурәтләгәндә дә, образлы охшату, чагыштырулар ясау өчен дә кулланган. «Уральский дневник» газетасында басылган «Хаджи» хикәясен Тукай татарчага «Хаҗи» дип (1906) тәрҗемә итә. Әсәрдәге Исмәгыйль Габидин дигән кеше, яше 30га җиткәч, җир йөзенең иң кадерле җире булган Мәккәи мөхәррәмә шәһәренә хаҗ кылырга китә. «Әдәбият ахшамы, яки литературно-музыкальный вечер» (1906) мәкаләсендә шагыйрь яхшы ниятле эшне Мәккәи мөхәррәмәдә генә түгел, бәлки башка урында да башкарып була, дигән фикер әйтә. Уральскида яшәгәндә, Тукай «Уклар» сатирик журналында бик актив эш алып бара, мәкаләләрне дә күпчелек очракта үзе яза, рәсем-карикатура астына кирәкле текстны да үзе төзи. Мәсәлән, «Уклар»ның 1906 елгы 2 нче (июль) санында басылган рәсемдә еракта диңгез артында Мәккә, Мәдинә манаралары күренә. Кәләпүшле, фәсле, кырпу бүрекле, чалмалы агайлар яр буендагы пароходка ашыгалар; аркаларында «500 р.», «1 000 р.», «4 000 р.», «25 000 р.», «100 000 р.» дип язылган капчыклар. Карикатурага «Мөселманнарның малы Мәккә, Мәдинә шәһәрләренә агуы» дип исем бирелгән. «Безне урынсыз яманлыйлар» (1907) шигырендә шагыйрь, безнең дә рәссамнарыбыз бар, дип, Мәккә, Мәдинә шәһәренә охшатып ясалган рәсемнәрне изге сурәт итеп сатып йөрүче эшкуарлардан көлә. «Гыйшык уты» (1910) юмористик шаяруында ул кызларның сагыз чәйнәвен Мәккәи мөхәррәмә вә Мәдинәи мөнәвәрә дөяләренең зәгъфран чәйнәүләренә охшата. «Бәйрәм вә сабыйлык вакыты» (1908), «...гә (ядкәр)» (1909), «Мигъраҗ» (1910), «Мәҗрух указ» (1910), «Тәфсирме? Тәрҗемәме?» (1913) шигырьләрендә Хиҗаз, Мәккә белән бәйле әйберләр турында сүз бара. Тукай. «Мәкаләи махсуса» (1912) сәяхәтнамәсендә Самарга килеп җиткәч извозчик белән шәһәрнең мулласы Фатыйх әфәнде Мортазинга барып килүен «муллалар дәвере», дип искә ала. Ягъни, хаҗга барган муллаларның Кәгъбә-Мәккә шәһәрендәге төп мәчет тирәли әйләнеп йөрү йоласы «дәвер әйләнү» дип аталганга, извозчикның аны бер яктан алып барып, икенче яктан әйләндереп алып кайтуын шуңа охшата.

Әдәбият

Тукай Г. Биштомлык. Т.I. — Б.185, 364, 365, 369, 381, 389; Т.II. — Б.114, 273, 356, 358, 360, 387; Т.III. — Б.198, 201, 202, 226, 348, 351, 356, 377; Т.IV. — Б.122, 302, 318; Т.V. — Б.271, 278.

Заһир Шәйхелисламов,
филология фәннәре кандидаты ■

2013 ЕЛГА «ЧЫН МИРАС» ЖУРНАЛЫНЫҢ БИБЛИОГРАФИЯСЕ

МӨРӘҖӘГАТЬЛӘР, РӘСМИ ДОКУМЕНТЛАР

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнехановның Әлмәт шәһәре төзелүнең 60 еллыгын һәм Татарстан Республикасында нефть ятмаларын эшкәртә башлауның 70 еллыгын бәйрәм итү турындагы Указы. — №9. — 2 т.б.

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнехановның Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасыннан. — №8. — 2 т.б.

Ибраһимов И. Баш мөхәррир сүзе. — №1. — Б.3.

Ибраһимов И. Безгә бер яшь! — №6. — Б.2-3.

ТАРИХ

Арслан Ф. Кырым һәм Идел-Урал татарлары арасындагы багланышлар. — №11. — Б.36-43; №12. — Б.48-53.

Арсланов А. Алтын Урда дәүләтендә (Җучи олысында) сәүдә итүне оештыру үзенчәлекләре. — №3. — Б.4-13.

Архивларда — халык хәтере мирасы. — Данил Ибраһимов белән Илдус Заһидуллин әңгәмәсе. — №6. — Б.40-45.

Ахунов А. Татарларның Шәрекътәге күчемсез милкенең язмышы нихәлдә? — №11. — Б.30-35.

Әлмәт шәһәрендә иҗтимагый-мәдәни тормыш һәм мәгариф үсешенең кыскача елъязмасы. — №9. — Б.37-39.

Әмиров Р. Башкортстан төбәге иҗтимагый-тарихи һәм мәдәни тормышында абызлар (XVIII гасыр). — №12. — Б.10-15.

«Биегәя Болгар күге...» — №7. — Б.4-5.

«Ватанпәрвәрлек хисе кече Ватаннан башлана» (Түгәрәк өстәл). — №11. — Б.18-28.

Ваһапов Н. Порт-Артур кайтавазы. — №5. — Б.44-47.

Вәлиди Ә. Казан ханлыгында төрки ислам мәдәнияте. — №1. — Б.18-33.

Вәлиев Р. Кәшшаф Мохтаров — беренче суверенитет «атасы». — №7. — Б.36-39; №10. — Б.36-42.

Гайнетдин М. «Без бишенче елны бер көнне уяндык таң белән...» — №7. — Б.40.

Галиева Г. Гаилә — милләтнең нигезе яки татар гаиләсендә бала тууга мөнәсәбәт. — №3. — Б.46-56.

Галиуллина Д. XIX гасыр ахыры — XX йөз башы «яңа» татар әлифбаларының үзенчәлекләре. — №8. — Б.30-37.

Галиуллина Д. Газиз Гобәйдуллин хезмәтләрендә татар халкы тарихы. — №1. — Б.34-41.

Галләмова Ә. Әлмәт районында төбәкчелек гыйлеменең үсеше. — №9. — Б.52-57.

Гобәйдуллин Л. «Әй, газизә бикәләр!» [Маһруй Мозаффария. Нәсыйхәтнамә лиәһли заманиһи]. — №3. — Б.65-68.

Гобәйдуллин Л. Милли мәгариф һәм заман. — №8. — Б.12-25.

Гобәйдуллин Л. Милли мирасыбыз сагында. — №5. — Б.55-65.

Гобәйдуллин Л. Сөенеп көтелгән бәйрәм (100 ел элек Казан Сабан туйлары). — №6. — Б.54-61.

Гобәйдуллин Л. Тылсымлы төбәк музее. («Бәкер» шифаханәсенә — 80 ел). — №11. — Б.44-53.

Гобәйдуллин Л. Үзенә тарта серле Болгар җире... — №10. — Б.4-8.

Гобәйдуллин Л. Хәтер сагында (Әлмәт туган якны өйрәнү музее). — №9. — Б.48-51.

Гыйбатдинов М., Мортазина Л. Гасырлардан килгән хәзинә. — №3. — Б.57.

Заһидуллин И., Гобәйдуллин Л. Гаилә һәм җәмгыять тоткасы. — №3. — Б.38-45.

Заһидуллин И. Татарстанда исламның бүгенге халәте: XIX гасырдан караш. — №6. — Б.64-69.

Заһидуллин И. Татарларның Финляндия Бөек кенәзлегенә күченү сәбәпләре һәм биредәге тормышларының кайбер сәхифәләре. — №11. — Б.10-17.

Зәкиев М. Кайту. — №6. — Б.24-31.

Исламов Р. Фотолар ачыклана. — №4. — Б.36-40.

Исмәгыйлев С. 1860 елда Байгилде авылына күчеп килүчеләр турында X ревизия кенәгәсендәге мәгълүматлар. — №5. — Б.38-43.

Кәбирова А. Әлмәт районы Бөек Ватан сугышы елларында. — №9. — Б.28-32.

Кәбирова А. Бөек Ватан сугышы елларында ТАССР саннарда һәм фактларда. — №5. — Б.15-18.

Киләчәккә йөз тотып. — Энгель Фәттахов белән Илдус Заһидуллин әңгәмәсе. — №8. — Б.4-11.

Курат Ә. Китаплар арасында. — №10. — Б.46-47.

«Кызыл» сүзендә бернинди сәясәт юк...». — Фаил Фәтхетдинов белән Илдус Заһидуллин әңгәмәсе. — №3. — Б.30-33.

Лотфуллин М. Россия шартларында милли мәгарифнең үсеш юнәлешләре. — №8. — Б.26-29.

Мәрданов Р. Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасы кулъязмалары. — №6. — Б.32-39.

Мәрданов Р. Татарларга юл күрсәтүче. — №5. — Б.48-50.

Мәрданов Р., Һадиев И. «...Мөселманлардин дога өмид өчен». — №7. — Б.26-35.

Мәхмүтова А. Бабаларым мирасы. — №1. — Б.42-52.

Мәхмүтова А. «...Ирекләнер чаклар җитте, ирекләник». — №3. — Б.59-64; №4. — Б.41-49.

Мәхмүтова А. Мәгърифәтче Шаһбазгәрәй Әхмәров. — №12. — Б.16-26.

Милләтем дип җан атып... — Илдар Гыйльметдинов белән Илдус Заһидуллин әңгәмәсе. — №5. — Б.23-26.

Минкин М. 1950-1960 елларда ТАССРда нефть сәнәгате өчен мәгариф инфраструктурасының формалашуы. — №9. — Б.33-36.

Миңнегулов Х. Без — «бер Ана-йортның балалары». — №10. — Б.48-53.

Миргалиев И. Әкъдәс Нигъмәт Курат хезмәтләрендә Алтын Урда тарихы. — №10. — Б.54-57.

Моисеев М. Казан аксөякләре сәяси көрәшенең историографиядә һәм рус чыганакларында чагылышы. — №10. — Б.20-34.

Мортазина Л. Габдрахман Рафиков гаиләсе һәм татар зыялылары. — №2. — Б.46-54.

Мөслихова Ч. «Әй, кыйммәтле ана!» («Сөембикә» журналында мәгърифәтче Фатыймаи-Фәридә турында мәкаләләр). — №12. — Б.43-47.

Мөслихова Ч. «Ханым вә туташлар дикъкатенә...» («Сөембикә» журналына 100 ел). — №12. — Б.37-42.

Мөхәммәдиев А. Идел буе болгарларында ислам хокукы үсеше. — №11. — Б.4-9.

Мөхәммәдьяров Ш. Хөррият таңында (Искә төшерү). — №7. — Б.41-43.

Мөхәммәтшин Җ. Болгар җыены. — №7. — Б.8-18.

Мөхәммәтшин З. Метрикә дәфтәрләре — хәтер сагында (Җаек шәһәре татарлары). — №5. — Б.28-37.

Низаметдинов И. 1930-1945 елларда Арча педагогика училищесы. — №7. — Б.38-51.

Ногманов А. XVIII гасырда Әлмәт төбәге һәм Әлмәт авылы тарихыннан. — №9. — Б.18-27.

Петров Н. Керәшен Сәрдәсе авылы тарихыннан (XV-XIX гасырлар). — №2. — Б.38-45.

Рәхим Г. Болгар хәрабәләрендә. — №10. — Б.14-19.

Сабитов Ж. «Урда» кинофильмы һәм тарихи чынбарлык. — №7. — Б.44-49.

Салехова З. Чит туфракның җылысы. — №5. — Б.19-22.

Салихов М. Әлмәт — Татарстанның ныклы терәге (Әлмәт шәһәренә 60 ел). — №9. — Б.4-13.

Саначин С. Казан йорты башкаласының соңгы көннәрдәге ныгытмалары (фортификациясе) турында гипотеза. — №6. — Б.6-22.

Сәмигулов Г. Көньяк Урал арты төбәге татарлары тарихыннан (XVII-XVIII гасырлар). — №12. — Б.4-9.

Сәфәров М. Юкка түгелдер («Ватаным Татарстан» газетасына 95 ел). — №5. — Б.51-54.

«Татнефть»нең кыскача елъязмасы — №9. — Б.40-42.

Ташлар сере. («Түгәрәк өстәл»). — №2. — Б.20-33.

Тәхаветдинов Ш. Татарстанда нефть чыгара башлауга 70 ел. — №9. — Б.14-15.

«Тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып...» [20 мартта Яр Чаллы каласында булган Татарстан Дәүләт Советы Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитетының күчмә утырышы]. — №4. — Б.7-29.

Төркуглы И. XIX гасыр ахыры — XX йөз башы татар-төрек багланышлары. — №1. — Б.7-17; №2. — Б.5-19; №3. — Б.14-29.

Уразманова Р. XIX гасыр — XX йөз башы авыл Сабан туйлары. — №6. — Б.46-51.

Үзиәтгин М. Мөхәммәт Шәрифинең 1550 елда язган «Зафәрнамә»се. — №5. — Б.4-13.

Фән юлында тәүге адым. — №8. — Б.52-63.

Фәхреддин Р. Тарихыбызга гаид. — №10. — Б.9-13.

Ханнанов Р.Татарстанның көньяк-көнчыгыш шәһәрләрен төзүдә Чупай таш карьерының роле. — №9. — Б.44-47.

Һадиев И. Бертуган Хөсәеневләр каберләренә куелган ташъязма истәлекләр. — №2. — Б.34-37.

Цвиклински С. Габдерәшит Ибраһимның «Әл-җиһад» газетасында басылган мәкаләләре. — №12. — Б.28-36.

Шаһаби Д. Суфый буларак Шиһабетдин Мәрҗани. — №7. — Б.19-25; №9. — Б.58-63.

Шәмсетдинов Г. Без тарихта эзлебез. («Мәгариф» журналына 100 ел) — №3. — Б.34-37.

Шәрәфетдинев Ф. Әкъдәс Нигъмәт Куратның тәрҗемәи хәле һәм фәнни-педагогик эшчәнлеге. — №10. — Б.43-45.

ӘДӘБИЯТ

Алда безне ни көтә? (Рәфикъ Юныска 70 яшь). — Рәфикъ Юныс белән Илфак Ибраһимов әңгәмәсе. — №3. — Б.107-111.

Әхмәдиев Н. Татарстан нефтьчеләре гимны. — №9. — Б.43.

Ахунҗанова Р. Олуг шәһәрдә кунакта. — №10. — Б.102-109; №11. — Б.88-95; №12. — Б. 100-107.

Баласагуни Й. Кутадгу билик. — №10. — Б.65-73; №11. — Б.56-65; №12. — Б.56-64.

Баткаева Р. Каһарманнар хәтере мәңгелек. — №6. — Б.109-110.

Бәдретдин К. Финляндиядә татар әдәбиятының үсеше. — №11. — Б.102-107.

Бәйрәмова Ф. Батырша. — №1. — Б.94-101; №2. — Б.92-98; №3. — Б.112-119.

Булатова К. Күларты посёлогы. — №9. — Б.82-83.

Ваһапова Л. Башкортстандагы хәзерге татар әдәбияты. — №5. — Б.103-110.

Вәлиев М. Тукайга кайту юлында. — №4. — Б.96-98.

Гадел Кутуй шигырьләре. — №7. — Б.84-85.

Гайнанова Л. «...уйнадың син ник бик аз...» — №4. — Б.74.

Гайнанова Л. Гаяз Исхакый хатлары. — №8. — Б.66-71; №9. — Б.84-88; №11. — Б.66-79.

Гайнанова Л. Сүнә белми торган бер ялкын. — №7. — Б.72-74.

Гайнетдин А. Австрия зинданнарында туган шигъри хатлар. — №6. — Б.94-99.

Гайнетдин Х. Шигырьләр. — №1. — Б.109-111.

Гаитов М. Яралы язмышлы шагыйрә (Гөлшат Зәйнашеваның тууына 85 ел). — №11. — Б.80-85.

Галиев Ш. «...Тик гармуннар гына уйчан калган, бәхилләшеп киткән егетләр...» — №11. — Б.86-87.

Галимҗанова Э., Хөснетдинова Г.Тукайга багышланган хатирәләр. — №4. — Б.90-95.

Галимҗанова Э., Хөснетдинова Г. Тукай энциклопедиясенә. — №11. — Б.108-109.

Галиуллин Т. «Толстой да белгән Мулла илен...» — №10. — Б.98-99.

Ганиева Р. Шәрекъ Ренессансы. — №1. — Б.86-91.

Ганиева Р. Тукай энциклопедиясенә. — №1. — Б.91-93; №2. — Б.99; №4. — Б.99-100; №6. — Б.111-115; №7. — Б.107-108; №8. — Б.110-111.

Гаташ Р. Безгә дә кадерле Магҗан ул. — №6. — Б.72-78.

Гаташ Р. «Мин беренче чәчәкләрне эзлим...» (Газизә Сәмитованың тууына 150 ел). — №1. — Б.102-105.

Гаташ Р. «Мәхәббәттән башка берни белмисең син...» — №3. — Б.83.

Гыйззәтуллина Ф. Уйлар Ватаны. — №9. — Б.89.

Гыйләҗев А. Кылдан нәзек, кылычтан үткен (Роман). — №7. — Б.91-102; №8. — Б.86-94; №9. — Б.90-95; №10. — Б.74-80.

Гыйләҗева Н. Дин, әхлак, милли тәрбия — рухи байлык... — №7. — Б.89-90.

Гәрәева С. Шигърият. — №11. — Б.29.

Әхмәтҗанов Р. Йосыф Баласагуниның «Котайткыч белек» әсәре — татар телендә. — №10. — Б.60-64.

Әхмәтҗанова С. Сүнмәс балкыш (Поэма). — №7. — Б.109-113.

Әюпов Х. «Бер-бер артлы замандашлар китә, өлгералмыйсыңдыр кул болгарга...» — №9. — Б.96-98.

Дәүли Н. Автопортрет. — №6. — Б.23.

Җошкун Б. Тугандаш халыкларның уртак язмышы. — №11. — Б.96-101.

Зарипова Р. Әхмәт Фәйзи иҗатында Тукай. (Әхмәт Фәйзинең тууына 100 ел). — №4. — Б.104-108.

Заһидуллина Д. Караш җитмәсне колачлаган әдип (Рабит Батуллага 75 яшь). — №3. — Б.86-99.

Заһидуллина Д. Милли әдәбиятыбыз тарихыннан. — №7. — Б.80-84.

Йолдыз. Балалар өчен шигырьләр. — №8. — Б.106-107.

Исхакый Г. Татарстанда «Фәнни истыйляхлар» ясау. Мәскәүнең яңа һөҗүме. — №2. — Б.73-75.

Исхакый Г. Милли юлыбызның нигезләре. — №7. — Б.75-78.

Исхакый Г. Шагыйрь Габдулла Тукай. — №4. — Б.76-81.

Мансуров З. Балкыш, яки Хәйретдин Мөҗәйнең сугыш язмаларыннан юллар. — №2. — Б.83-91.

Мансуров З. Габдулла Тукай: «Һәр хыялдан татлыдыр милләт хыялы». — №4. — Б.101-103.

Мансуров З. Иң кыены... — №7. — Б.79.

Мәһдиев М. Арча ягы авыллары. — №4. — Б.68-73.

Миңнегулов Х. Әби-бабаларыбызның гыйбрәтле сабаклары. — №8. — Б.95-105.

Мозаффария М. Мәшһүр хатыннар. — №3. — Б.58.

Мозаффария М. Ханымнар. — №3. — Б.69.

Мостафин Ш. Каһарманнар хәтере мәңгелек. — №8. — Б.108-109.

Мөэминова Э. Буровойлар гөрелтесе. — №9. — Б.99.

Нәбиуллина И. Рухи дөнья җәүһәрләре. (Әлмәт язучылар оешмасына 50 ел). — №9. — Б.66-73.

Нәҗмиев Т. Күпне күргән, күпне кичергән. — №6. — Б.100-108.

Низами Р. Мәһди йолдызлыгы ни сөйли? — №3. — Б.100-106.

Нургатина Г. «Типсен йөрәк зурлык белән» (Нәҗип Думавиның тууына 130 ел). — №5. — Б.111-119.

Петров Н. Бер тәрҗемәнең «тәрҗемәи хәле». — №4. — Б.109-111.

Поварисов С. Төнге фәрештәләр. — №5. — Б.84-95; №6. — Б.79-86.

Рахман Р. Юл бирегез, шәһәр урамнары! (Мөдәррис Вәлиевкә 60 яшь) — №6. — Б.87-93.

Рәмиев З. Тукай энциклопедиясенә. — №9. — Б.100-101.

Садыйкова А. Тукай энциклопедиясенә. — №10. — Б.110-111.

Сафин Ф. Акыл алтын, йөрәк салкын... — №4. — Б.30-33.

Сәйфетдинов Р. Мине игелекле мөселман дип санавыгызны үтенәм. — №10. — Б.100-101.

Сөләйманова С. Кеше. — №10. — Б.35.

Төхфәтуллин Р. Хатлар булып калган хатирәләр. — №9. — Б.74-81; №10. — Б.81-85; №12. — Б.65-68.

Тукай Г. Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы? — №4. — Б.5-6.

Тукай Г. Шагыйрь. — №4. — Б.4.

«Төрки халыклардан мин берүзем...» Ренат Харис белән Илдус Заһидуллин әңгәмәсе. — №1. — Б.78-81.

Фәйзуллин Р. Сәйдәш. — №8. — Б.72-85.

Фәйзуллина Ф. Гаяз Исхакый хатларында әдәби проблемаларның чагылышы. — №4. — Б.82-89.

Харис Р. Бәкер сазы. — №1. — Б.82-85.

Харис Р. «Һәрбер чорда шундый чаклар була...» — №5. — Б.27.

Хәбетдинова М. Бер әсәрнең язылу тарихы. — №12. — Б.91-99.

Хәким С. Тукта, бер үткән гомерне... —№12. — Б.27.

Хәбетдинова М. Романның язылу тарихы (Аяз Гыйләҗевнең «Кылдан нәзек, кылычтан үткен» романы турында). — №7. — Б.86-88.

Хәкимова С. Балалар күңеленә ачкыч тапкан әдип. — №2. — Б.76-82.

Хәлим А. Рәшид Рәшидов (кечкенә роман). — №10. — Б.86-97; №12. — Б.69-81.

Хәлим А. Шигърияттә шәхес һәм милли дәүләтчелек (Булат Сөләйманның тууына 75 ел). — №5. — Б.96-102.

Хәсәнова Ф. Җирсү. — №12. — Б.108-113.

Хөснетдинова Г. Телебез сафлыгы сагында. — №2. — Б.72.

Шәрипов Ә. Шундый татар тюркологы бар... (Марсель Бакировка 80 яшь). — №12. — Б.82-90.

Юзеев И.Сагышлы мирас. — №1. — Б.53.

Юсупова Н. «Лаеклы булыйк без бу якты заманга...» (Хәйдәр Гайнетдин иҗатына күзәтү). — №1. — Б.106-109.

Юсупова Н. Фидакарь хезмәт юлында (Тәлгат Галиуллинга 75 яшь). — №7. — Б.103-107.

Яруллин Ф. Урманчы кызы. — №1. — Б.112-115.

Яруллин Ф. Җыр калдырыйк. — №2. — Б.55.

СӘНГАТЬ

Арслан Ф. Дөньяны гизгән моң (Ренат Еникеевкә 75 яшь) — №5. — Б.75-81.

Гарифуллин Д. «Сарман» җыры ничек туган. — №7. — Б.63-69.

Гыйлмранова Д. Әлмәт төбәгендә татар театры: 1940-1970 еллар. — №9. — Б.104-111.

Зарипов Ә. «Бас, кызым Өммегөлсем...» (Гөлсем Исәнгуловага 75 яшь). — №7. — Б.52-62.

Зарипов Ә. Альтернатив... яки кинәсез кино. — №1. — Б.61-67; №2. — Б.65-69; №3. — Б.78-82; №4. — Б.61-65.

Кайбицкая Г. Беренче адымнар... — №4. — Б.52-55.

Кайбицкая Г. Опера сәнгатенә килү юлларым. — №5. — Б.68-73.

Шагыйрьҗан Л. Без кайчандыр Ләйлә белән Мәҗнүн идек... (Айдар Хафизга 70 яшь). — №11. — Б.113-119.

Шакирҗан Л. Кем ул Равил Шәрәфи? (Равил Шәрәфиев белән әңгәмә). — №4. — Б.57-60.

Шакирҗан Л. Үги кыздан — Мәйсәрәгә (Рауза Хәйретдиновага 85 яшь). — №2. — Б.59-64.

Шакирҗан Л. Уйнап узган гомер. (Нәҗибә Ихсановага 75 яшь). — №3. — Б.72-77.

Шакиров Ә. Нинди иде безнең яшьлек! (Ринат Таҗетдиновка 75 яшь). — №1. — Б.56-60.

Шаһиева Р. Үткәнне сагыну һәм киләчәккә өметләр («Туран» фондына 20 ел). — №1. — Б.68-75.

БӘЙРӘМНӘРЕБЕЗ

«Аксакал». Мишәрстанда Мәүлид. — №2. — Б.107-109.

Миңнегалиев Р. Мәүлид бәйрәме һәм аның тарихы. — №2. — Б.102-106.

Сабиров Н. Корбан гаете. — №10. — Б.114-119.

Сабиров Н. Ураза бәйрәме. — №8. — Б.114-117.

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР

Нәбиуллина Г., Гыйләҗева Л. Акыл — тузмас кием, гыйлем — корымас кое. — №9. — Б.116-120.

Нәбиуллина Г., Гыйләҗева Л. Иле барның теле бар. — №1. — Б.118-119; №2. — Б.112-115.

Нәбиуллина Г., Гыйләҗева Л. Үткән гомер — аккан су. — №7. — Б.116-119.

Нәбиуллина Г. Тукаев сүзләре. — №4. — Б.114-118.

СПОРТ

Гафиятов А. Барлык юллар да Казанга илтә. — №6. — Б.116-118.

Гафиятов А. Каршыладык. Күрдек. Җиңдек. — №8. — Б.118-119.

Гафиятов А. «Универсиада!» дип тибә йөрәкләр. — №2. — Б.119-120.

ЯҢА КИТАПЛАР

Абдуллина Д. Тукай иҗатында Коръән мотивлары. — **Алия Мөбарәкшина** рецензиясе. — №12. — Б.120.

Аллен Франк. Бохара һәм Россия мөселманнары. Суфичылык һәм мәгърифәт. Ислам абруеның парадокслары. — **Әлфрид Бостанов** рецензиясе. — №6. — Б.119-120.

XVIII йөз татар әдәбияты: проза. — **Ләйсән Бәдретдинова** рецензиясе. — №1. — 3 т.б.

Габдулла Тукай әсәрләре: сүзлек-белешмәлек / [төз. һәм кереш сүз авт. З.Рәмиев]. — **Алия Мөбарәкшина** рецензиясе. — №4. — Б.119.

Галиәсгар Гафуров-Чыгътай. Сайланма әсәрләр. «Тутам», «Исабәт» һәм истәлекләр. / [төз. Рәмиев З., Газизуллина Г.]. — **Алия Мөбарәкшина** рецензиясе. — №10. — Б.120. — 3 т.б.

Галимҗан Ибраһимов: «Тәрҗемәи хәле, истәлекләр, әсәрләр, анализ үрнәкләре, дәрес эшкәртмәләре, сценарийлар» / [төз. Шакирова Т.Р.]. — **Илдус Заһидуллин** рецензиясе. — №3. — 3 т.б.

Гаяз Исхакый. Әсәрләр. Т.XIV. — **Гөлнара Зәйниева** рецензиясе. — №8. — Б.120.

История татар. Т.6. — **Илдус Заһидуллин** рецензиясе. — №7. — Б.120. — 3 т.б.

«Кызыл таң». Кыскача энциклопедия, «Кызыл таң» фотоальбомы. — **Ленар Гобәйдуллин** рецензиясе. — №5. — 3 т.б.

Ризаэддин Фәхреддин. Дини вә иҗтимагый мәсьәләләр; Ризаэддин Фәхреддин. Мәшһүр адәмнәр. — **Ленар Гобәйдуллин** рецензиясе. — №9. — Б.112-113.

Түркilik тәрбие. Антология. — **Хатыйп Миңнегулов** рецензиясе. — №11. — Б.120.

Яхин А. Системы татарского фольклора. — **Дания Заһидуллина** рецензиясе. — №2. — Б.116-117. ■



АБДУЛЛИНА Д.М.
ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИҖАТЫНДА КОРЪӘН МОТИВЛАРЫ. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2013. — 191 б. 1000 данә.

Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әйдәп баручы хезмәткәре Диләрия Абдуллинаның «Габдулла Тукай иҗатында Коръән мотивлары» дигән бай мәгълүматлы монографиясе дөнья күрде. Бу хезмәтнең басылып чыгуы әдәбият сөючеләр, Тукай иҗаты белән кызыксынучылар тарафыннан күптән көтелә иде. Чөнки ул әдәбият фәненең әлеге юнәлешендә 2005 елда ук инде кандидатлык диссертациясе рәвешендә (фәнни җитәкчесе — профессор Р.К.Ганиева) якланган иде. Заманыбызга хас акча кытлыгы аркасында, хезмәт нәшриятта да шактый вакыт басылмый ятты. Шуңа да карамастан, интернет челтәре аша курс, диплом, магистрлык эшләре язучылар аннан иркен файдаланды.

XX гасыр башы — татар әдәбиятының Яңарыш кичергән, Гареб һәм Шәрекъ традицияләре аерылгысыз бербөтен булып кушылган, синтез хәленә кергән дәвере. Әдәби барышыбыз зур сыйфат үзгәрешләренә бай булган бу чорда бөек шагыйребез Г.Тукай әдәбият мәйданына аяк баса. Дөньяны танып белүнең беренче адымнарыннан ук, кечкенә, ятим калган мулла баласы Габдулла мөселман тәрбиясе ала, ә инде Кырлайдан Җаекка күчеп киткәч тә, атаклы Мотыйгулла хәзрәт җитәкләгән «Мотыйгыя» мәдрәсәсендә укыганда, дини эчтәлектәге әдәбият һәм Коръән тәгълиматы белән таныша. Кыскасы, шагыйрь тулысы белән диярлек Шәрекъ мәдәнияте традицияләрендә тәрбияләнә. Шуңа күрә дә татар һәм төрек әдәбиятчылары (Җ.Вәлиди, Г.Ибраһимов, Ф.Көпрелезадә) аның иҗатындагы беренче адымнарын «Мөхәммәдия» чоры дип атый. Шагыйрьнең башлангыч чор шигырьләре генә түгел, гомумән, бөтен иҗаты Коръән мотивлары белән үрелгән.

Д.М.Абдуллина хезмәтендә Тукай иҗатындагы дини карашлар, әдәби барышка бәйле рәвештә, 1905-1917 еллар, тоталитар (1917-1956), посттоталитар (1956-1985) дәвер һәм XX йөз ахыры чорларына бүлеп өйрәнелә. Октябрь инкыйлабына кадәр Тукай шигърияте әле дин белән тыгыз мөнәсәбәттә тикшерелә, советлар чорында исә ул тулысы белән диннән читләштерелә. Шул сәбәпле социалистик реализм әдәбияты принципларына яраклаштырылып, Тукай үзе дә «атеист-революционер»га әйләнеп китә. Үзгәртеп кору еллары килгәч кенә, Тукай иҗатындагы дини карашларга мөнәсәбәт уңай якка үзгәрә, шагыйрь турындагы фәндә объективлык урнаша.

Д.М.Абдуллина хезмәтендә шагыйрьнең әдәби мирасындагы Аллаһы Тәгаләнең әз-Зат һәм әс-сыйфатларын, Коръән өйрәтмәләре белән бәйле әхлакый-этик карашларын, дога мотивларын тикшерүгә зур урын бирелә. Тукай поэзиясендәге дини мотивларның Коръән сүрәләренә һәм аятьләренә таянып, аларның ничек нәзыйрәләр, иярүләр рәвешендә иҗат ителүен ячтыртуга, шул ук вакытта дини темаларга язылган шигырьләрнең Көнбатыштан һәм рус әдәбияты белеменнән үтеп кергән ысул белән, ягъни интертекстлар — аллюзия, цитата, реминисценцияләр ярдәмендә чагылышына аеруча басым ясала. Хезмәттә дини-әхлакый лириканың матур үрнәкләре булган «Мигъраҗ», «Пәйгамбәр», «Кадер кич», «Тәфсирме? Тәрҗемәме?», «Тәрбиятел әтфаль», «Оҗмахтагы бала» һ.б. шигырьләргә этрафлы анализ ясала.

Әлеге хезмәт мәктәп һәм югары уку йортлары укытучылары, студент, аспирантлар, гомумән, Тукай иҗаты белән кызыксынучылар өчен файдалы китап булыр дип уйлыйбыз.

Алия Мөбарәкшина,
Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты аспиранты

2013 ЕЛНЫҢ 17 НОЯБРЕНДӘ «Казан» халыкара аэропортында «Боинг 737» самолёты һәлакәткә очрап, берьюлы 50 кешенең гомере өзелде. Җир-Ана туфрагына аяк басарга санаулы минутлар калгач кына, җанөзгеч бу хәбәр бөтен ил өстенә таралды. Гаиләләргә килгән кара кайгы илебезнең зур фаҗигасенә әйләнде. Россия Президенты Владимир Путин, Россия Премьер-министры Дмитирий Медведев һ.б. һәлакәттә улын югалткан Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнехановның һәм фаҗига корбаннары туганнарының тирән кайгыларын уртаклашты. Республикабыз өстенә төшкән авыр фаҗигагә бер генә ил дә битараф калмады, Азәрбайҗан, Таҗикстан, Казахстан, Әрмәнстан һ.б. илләрдән хатлар һаман килә тора.

Безнең редакциягә дә читтә яшәүче авторларыбыз – Мигъмар Синан Нәфис сәнгать университеты профессоры Арзу Кылынч (Төркия, Истанбул), Хельсинки университеты гуманитар фәннәр факультетының дөнья мәдәнияте, Азия һәм Африка тикшеренүләр кафедрасы докторанты Кадрия Бәдретдин (Финляндия, Хельсинки) һ.б. кайгынамәләр юллады.

«Кай урында булсагыз да, сезгә үлем ирешер, әгәр күккә терәлгән, бик таза төзелгән кыл эчендә булсагыз да», – диелә Коръәндә. Бу – табигать кануны... Кешеләргә әлеге хакыйкатьне таныган хәлдә, фаҗигаләр, казалардан саклану чараларын күрү үтә дә фарыз!

«Чын мирас» журналы редакциясе һава һәлакәтендә якыннарын югалтканнарның тирән кайгысын уртаклаша, аларга язмышның ачы сынавын үтүдә зур сабырлык, түземлек тели.

Индекс 54132
70275



Халкыбыз тарихы, әдәби, мәдәни мирасыбыз, тәнкыйди фикер һәм заманча караш – барысы да «ЧЫН МИРАС» *журналында*

ИНДЕКС

ТАТАРСТАНДА – 54132

ЧИТ ТӨБӘКЛӘРДӘ – 70275

БЕЗ МИРАСЛЫ ХАЛЫК. «ЧЫН МИРАС» БЕЛӘН БЕРГӘ БУЛЫГЫЗ!